

Шәүкәт Әхмәдиев



# ЯЗМЫШ

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 820/89–93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ә86

*Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен*

Төзүчесе *Фатыйма Ибраһимова*
*Юлия Щетинкина* рәсемнәре

**Әхмәдиев Шәһит**

Ә86 Язмыш: хикәяләр, әкиятләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 160 б.

Бу китапка Шәһит Әхмәдиевнең балаларга багышланган иң яхшы хикәяләре һәм әкиятләре сайлап алынды.

ISBN 5-298-01299–X
© Татарстан китап нәшрияты, 2003

# Төзүчедән

Кадерле балалар! Язучыларыбыз гасырлар дәвамында сезнең өчен матур-матур әсәрләр иҗат итеп киләләр. Әдәби хәзинәбез бай. Аның бүгенгесен сез үзегез дә алып укый аласыз. Ә менә үткәне белән алай түгелдер. Чөнки элекке күп кенә әсәрләр дөньяга чыга алмыйча китапханәләрдә, иске журналларда хәрәкәтсез яталар әле. Шуны истә тотып Татарстан китап нәшрияты балалар әдәбияты редакциясе элекке әдәби әсәрләрдән җыентыклар төзеп чыгаруны гамәлгә кертте. Бу җыентыкларга язучыларның иң яхшы әсәрләре туплана. Инде алып укыгансыздыр, Ф.Агиевның «Мәрхәмәт», Г.Рәхимнең «Битлек», Ф.Әмирханның «Халык кызлары» исемле китаплары дөнья күргән иде. Менә хәзер кулыгызда Шәһит Әхмәдиевнең «Язмыш» исемле китабы.

Ш.Әхмәдиев — иҗтимагый һәм әдәби тормышыбызда үз эзен калдырган билгеле шәхес. Тарихчылар аны дәүләт эшлеклесе итеп искә алалар. Ул Казан губерна мөселманнарының беренче Мәгариф Халык Комиссары, башка зур урыннарда эшләгән кеше. Әдәбиятчылар өчен Шәһит Әхмәдиев — язучы, кыю фикерле журналист, әдәби тәнкыйтьче, дәреслекләр авторы. Аның ике мәртәбә — 1930 һәм 1959 елларда «Сайланма әсәрләр»е дә басылган.

Кайбер хикәяләре 1918 елларда гамәлгә кергән беренче баскыч эш мәктәпләрендә класстан тыш уку өчен чыгарылган «Балалар күңеле» серияләрендә урын алган. Ләкин сез аларны хәзер китап кибетләреннән таба алмассыз, фәкать фәнни китапханәләрдә сирәк очрый торган басмалар рәтендә генә күрерсез.

Ш.Әхмәдиев мондый югарылыкка ничек күтәрелгән соң?

Ул моңа бай тормышта үсеп, зур-зур уку йортлары тәмамлап ирешмәгән. Шәһит гади авыл малае, үзенең бәхетен үзлегеннән укып, үз тырышлыгы белән тапкан.

Ул 1888 елның 29 декабрендә Чистай өязе Татар Ялтаны авылында ярлы Гыймадетдин гаиләсендә дөньяга килә. Ярлы булуы бер хәл, унбер яшендә әти-әнисе үлеп китеп, тома ятим кала. «Оренбургтагы Вәли хәзрәт мәдрәсәсенә, бер тиен акчасы булмаган хәлдә, яланаяк килеп кергән иде»,— дип искә ала аны сабакташы, якын дусты һәм фикердәше Галимҗан Ибраһимов.

Авырлыклар күреп үскән кеше күбрәк кече күңелле була. Кече күңеллелек Ш.Әхмәдиевне гомере буе ташламый, аңа тәкәбберлек авыруы йокмый. Зур урыннарда эшләгәндә дә, мин хөкүмәт кешесе, дип үзенә махсус кабул итү сәгатьләре билгеләп куймый. Ш.Әхмәдиевкә теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итәргә мөмкин була, киеме дә урта кулдан әллә ни ары узмый — туганнары аны шулай сыйфатлыйлар. Фоторәсеменә карасаң да, аның гади халык вәкиле булуын абайлыйсың.

Иҗатына килгәндә, Шәһит Әхмәдиев 1912 елларда яза башлый. Балаларга багышланган әсәрләре исә 1913—1917 елларны эченә ала.

1913—1916 елларда Казанда балалар өчен «Ак юл» журналы чыга. Ш.Әхмәдиев — бу журналның актив язышучысы. Соңрак «Балалар дөньясы» (1917 елның мартыннан алып 1918 елның январена кадәр Казанда чыга) журналында языша. Балаларга багышланган экиятләре, хикәяләре беренче мәртәбә әлеге ике журналда басыла, экиятләре күпчелекне тәшкил итә. Ул экиятләр «борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, бүре урәтник...» дип башлана тор-

ган традицион экиятләргә охшамаган. Алар экият белән хикәя уртасындарак, чынбарлыкка якынрак торалар, тарихи документлар булмасалар да, үзләреннән берникадәр тарихилык төсмере сизелә. Күз алдыннан Болгар, Кечек Азия, Иран җирләре үтә сыман. Авторның халык риваятьләрен, ерактан килә торган рухи тамырларыбызны яхшы белүенә дә сокланасың.

Без Совет чорында Ш.Әхмәдиев шикелле дәүләт эшлеклесе коммунистларны атеист итеп бәяләргә күнеккәнбез. Алай гына булмаган икән.

Башта Оренбургта Вәли хәзрәт, аннары Уфада «Галия» мәдрәсәсендә дини белем алган, исламның иң көчле вакытында үскән әдипнең күңеленә ислам дине бала чакта урнашып калганлыгы да әсәрләрендә чагыла.

Билгеле хакыйкать, безнең ерак бабаларыбызга ислам динен гарәп илчеләре алып килгән. Бу турыда экиятләр, риваятьләр таралган. Ш.Әхмәдиев шундый риваятьләрнең берсен, үз иҗат фантазиясе аша үткәреп, «Хан кызы» исеме белән үз вариантын тудырган.

Инде килеп «Коръән тәэсире». Экияттә мәҗүси гарәпләргә ислам диненең авырлык белән керүе турында сүз бара. Бу да бит үз вакытында булган хәл. Экияттә Аллаһы Тәгаләнең безгә билгеләнгән илчесе Мөхәммәт пәйгамбәрнең рухи куәте җылы сүзләр белән яратып сурәтләнә. Ш.Әхмәдиевнең мәкаләләрендә дә дини фикерләр очрый.

Һәрхәлдә, сабый чакта күңелгә сеңеп калган нәрсә гомерең буе онытылмый ул.

Урта гасырларда Көнбатыш Европада баш әйләндергеч батырлыклар турында сөйләгән «Рыцарь романнары» дигән жанр киң тарала. Моның мисаллары «Каһарман хикәяләре» («Пәһлеван хикәяләре» дип тә йөрткәннәр) исеме белән татар әдәбиятында

да барлыкка килә. «Каһарман катил» дигән китап та бар. Традицион экиятләрдә экият герое үзенең максатына тылсым ярдәмендә ирешсә, бу төр экиятләрдә герой кыенлыкларны үз көче белән җиңеп чыга.

Ш.Әхмәдиев «Каһарман хикәяләре» иҗат итүгә дә омтылыш ясый. «Үткен кылыч» экиятенең ахырына «Каһарман хикәяләре»ннән дип куйган.

Әдип тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнгән. Л.Толстойның, Көнбатышның танылган язучылары О.Уайльд һәм В.Гауфның кечкенәләргә багышланган экиятләрен тәрҗемә итеп, «Ак юл»да бастырган.

Ш.Әхмәдиевнең бу китабы урта яшьтәге мәктәп балаларына адреслап чыгарыла. Китаптагы әсәрләр зурлар өчен дә кызыклы. Автор һәркемне кызыксындыра торган кабатланмаган сюжетлар, гыйбрәтле язмышлар таба белгән.

Шәһит Әхмәдиев шактый әдәби мирас калдырса да, иҗади гомере әллә ни зур түгел. Октябрьдән соң ул бөтен көчен дәүләт эшенә бирә.

Аңа бу өлкәдә дә озак эшләргә насыйп булмый. Туганнарының әйтүенә караганда, ул 1926 елдан нервы өянәге белән авырый башлый. Озак авырудан соң, 1930 елның 12 августында Казанда, Комиссариатская урамы, 4 нче йортта (хәзерге Мөштәри урамы, 20 нче йорт) вафат була. Казанда Туганнар каберлегенә җирләнә.



# Ай алдады

Июньнең 20 нче көне. Җәйге сука өсте. Мин бер абзый белән иртә үк сукага китәм. Көн бик җылы, һава бик саф. Җилнең барлыгы да безгә сизелми. Мин йокым туймаганга, авылдан чыкканда иснәп-иснәп барсам да, кырга чыгып җиткәч, мең төрле көй белән чур-чур итеп сайраган тургай тавышлары мине йокымнан бөтенләй уяталар. Минем йокым күккә оча, бер дә иснәми башлыйм. Җир өстеннән сайрый-сайрый, чорылдый-чорылдый гел бер төштән күккә күтәрелгән тургайларны караудан бер дә бушамыйм. Аларның бик моңлы, күңелле, матур тавышларын ишетеп, мин рәхәтләнәм. Бер тургай нәкъ минем өстемнән генә сайрап, күз күрми торган җиргә, югары күтәрелде. Мин аны карый-карый атымнан егылып төшә яздым. Бөтен күк тургай белән шыгрым тулган. Бөтен җирдә чор, чор, чоррр...

Сукага баручы без генә түгел, артыбыз да, алдыбыз да сабан, сукалар белән тулы. Алардан да мең

төрле тавыш күккә хәтле күтәрелә, алардан чыккан тавыш та үзенә бер төрле кызык сыман һәм матур булып тоела. Шул арада сабанчыларның кайсыберләре агылган көйгә моңланып кына җырлап та җибәрәләр. Минем абзый да аларга кушыла. Ул үзе озын-озын, бик матур итеп җырлый. Бигрәк тә ул «Зиләйлүк» көен яратып, күңел биреп җырлый, аны җырлаганда күзләрен йома, үзе бер уйга чума, бөтенләй дөньядан онытылган төсле була иде. Барабара без җиребезгә килеп тә җиттек. Безнең җир яныннан үтеп китүчеләр: «Син, Гариф, шәкертне иртәрәк сабанга кушкансың, аның сабагын оныттырырсың, шәкертләр иртә тормый бит»,— дип китәләр. Минем абзый Гариф аларга: «Юк-юк, аны сабанга мин кушмыйм, хәзергә йокларга яткырам. Үзе теләп кенә кырга килә ул!» — дип кала. Чыннан да, абзый мине күп вакыт иркәләп кенә йөртә: атка менгәндә дә, аттан төшкәндә дә миңа ярдәм итә, йокымнан уятканда да бик кызгана төсле: «Энем, тор әле, энем, канатым, тор әле, кырдагы йокы тагы да тәмлерәк булыр»,— дип кенә уята иде. Бер дә генә торасым килмәгәнне белсә, бөтенләй калдырып, мине уятмыйча да кырга китәр иде. Кырга барсам да, ул мине авыр эшләргә кушмый, сабан да сөрдерми, тик атлар ашату, эчерү кебек вак эшләргә генә кушкалый иде.

Атларны җигеп, сабанны көйләп, абзый җир сукалый башлады. Мин арбага менеп, печән өстенә күккә карап яттым, йоклый алмыйм, тургайлардан күземне ала алмыйм. Алар торган саен матур, моңлы һәм гүзәл сайрый баралар, шуны күреп, минем дә очыкырые булмаган саф, тын зәңгәр күктә тургайлар кебек очасым бик килә. Бик сирәк кенә сукачыларның: «На, на... буразна, кая бара!» — дип, атларга кычкырган, сызгырган тавышлары минем колакка килеп бәреләләр. Мин күктәге кошларны карый-карый йокыга киткәнемне сизми дә калганмын. Тик абзый-

ның: «Энем, тор әле, байтак вакыт үтте бугай, атларга да каптырып алыйк»,— дигән бер тавышына мин уянып киттем. Кояш югары ук менгән һәм шактый кыздыра башлаган иде. Сабанчыларның да күбесе хәл җыярга, атларын ашатырга туктаганнар иде. Безнең сары алаша белән туры бия дә башларын чайкап, эсселектән пошкыра башладылар. Минем арбадан торганымны көтәр-көтмәс, аларның икесе дә минем арбадагы печәнгә килеп кадалдылар. Сары алаша печәнгә генә риза булмагангадыр, астан солы караган кебек, арбадагы бөтен печәнне борыны белән каерып, чөеп җибәрде. «Ниһаять,ни котыра!» дигән бер тавышка гына ул туктады. Ул арада абзый арба күләгәсенә иске бишмәтен салып, авылда тугылган бер кишеле кызыл шакмаклы ашъяулыкны җәеп утыра иде. Ашъяулыкта ярты кара икмәк белән биш йомырка миңа күренде. Мин аларның өчесе абзыйга, икесе миңадыр, дип уйладым. Абзый ашъяулыкның бер читендә төйнәлгән тозны чиште дә: «Энем, туганым, тозлап, тәмләп йомырка ашап җибәр әле»,— дип, миңа бер йомырка бирде. «Берсен соңрак ашарсың»,— диде. Ул үзенә икмәк телемен бик зур, зур итеп кисте һәм йомыркасын яфрак калынлыгы итеп кенә турады. Ул бер йомырканы ашап бетергәнче әллә ничә зур икмәк телеме ашъяулыктан югалды. Ул йомырканы шикәр тешләгән шикелле генә вак каба, бигрәк тә тәмен белеп ашый, дим үз-үземә. Безнең җиребез авылга ерак, урман янында ук булганга, бүген төшке чәйгә өйгә кайтмадык. Төш җиткәч, абзый бер калай чәйнектә су кайната калды. Мин туры биягә атланып, алашаны бер янга тагып, коега су эчерергә киттем. Туры биянең сырты тигезрәк, йомшаграк булганга һәм атланганда да тыпырчынып тормаганга, мин һәрвакыт аңа гына атланып йөри идем. Бу көн үтте. Кешеләр дә үз җирләрен бетереп, авылга кайта башладылар. Без дә бу җирне бетереп, өйгә киттек. Өйдә атларны

яхшылап ашаттык та абзый белән башка бер җиргә янә урман янына куна килдек. Без авылдан әйләнеп килгәнче кояш батып, шактый караңгыланып та килә иде. Килгәч, сабанны көйләдек, җирне берничә генә әйләндек тә атларны туардык. Безнең кырда кунуыбыз бу ел беренче генә булды. Абзый үзе арба янында әйберләр саклап калырга, мине урманга атлар саклап, ашатып кунучы сукачы малайлар янына ике ат белән кунарга җибәрергә булды. Малайларның кайда кунганлыкларын мин белми идем. Абзый миңа юл күрсәтеп: «Менә шул юлдан бар да урманга кергәч, уңга борыл да, айга таба бар, шул айдан бер дә аерылма. Эчкә үк кергәч, «малайлар!» дип кычкыр. Алар сиңа тавыш бирерләр. Иртән алар белән бергә кайтырсың»,— диде. Без алай-болай иткәнче, караңгы төшеп, бер читтән ай да калыккан иде. Мин тиз генә атларымны алып, абзый күрсәткән юл белән урманга таба ычкындым. Урманга да кердем, уңга киттем, айга карап та юнәлдем. Атлар пошкыра-пошкыра күңелле генә чабалар, юл буендагы агач ботаклары да янга таккан атымны сыдырып, тырнап калалар. Кайсыбер ботаклар минем киез ак эшләпәмне дә эләктереп алып кала язалар. Мин, байтак-байтак барып, урман эченә үк кергәч, берничә аланнар да үткәч, «малайлар» дип кычкырам да кычкырам. Миңа каршы бер тавыш та ишетелмәгәч, тагын: «Малайлар, малайлар, малайлар! Сез кайда?» — дип, берөзлексез кычкырам. Минем тавышлар урманның әллә кай җирләренә яңгыратып-яңгыратып китәләр. Әллә кайда, ерак бер җирдә, «малайлар, сез кайдау»дигән төсле була. Мин һаман бер туктамыйча айга карап чабам гына... малайлар, малайлар, малайлар!

Болай да булмагач, авызыма кулымны куеп яңгыратып та кычкырган булам. Һичбер җирдә миңа каршы биргән бер тавыш та сизелми. Шул вакыт мине курку ала: йөрәгем леп-леп итә башлый. Беразрак чап-

тырып һәм сикертеп барам да туктап тагын кычкырырга тотынам... Юк, юк. Ай да болыт астына керә башлады. Караңгылык коела гына бара, минем актык өметем, юл күрсәтүчем дә бетүгә якынлаша. Кызу йөргәндә ботаклар да маңгаемны тырнап-тырнап калалар. Куркуымнан мин авыртканны да тоймыйм, чабам да чабам, туктыйм да кычкырам. Атларым да, минем хәлне белгән, сизгән һәм аңлаган кебек, бер дә миңа карышмыйча, буйсынып кына баралар. Үлән күргәч, бертуктамый башын төртеп, ашап, теңкәмә тия торган сары алашам да хәзер башын күтәреп кенә, бер дә йөдәтмичә генә бара. Ул арада ай бөтенләй каплана. Төшлектән болытлар каралып, тамырланып, нәкъ урман өстенә күтәреләләр. Кинәт яшен дә ялт итеп китә. Урман эче инә күренерлек яктыра. Мин хәзер чынлап адашканымны, кунучы малайларны таба алмавымны бик яхшы беләм һәм аңлыйм. Мине тагы курку чорнап ала, башым ут кебек яна, йөрәгем урын таба алмый... күзләрем тона... Агач араларыннан кинәт «прх, прх, прх» итеп очкан кошлар минем котымны очыралар... Мин һаман барам да барам. Күк күкри башлый, көчле яшен яшьни. Төшлек ягында дөнья җимерелгән төсле, шалтыррр, шалтыррр күк күкрәгәндә, яшен яшьнәгәндә ат янында торырга бер дә ярамый, яшен ата торган җен атка ышыклана икән дигән сүзләр кылт итеп минем күңелемә килеп төшә, мин тагын куркам. Атларымны борам да килгән юлым белән кире артка чабарга тотынам. Дөм караңгы, күзгә төртсәң, бернәрсә күренми. Атларым юлдан чыгып, чыгып торган төпчекләргә абынып та, сөртенеп тә китәләр. Мин аз гына аттан очып төшмиче калам. Бер кулымны ялдан бер дә алмыйм, атларым, колакларын кайчы кебек торгызып, куркына-куркына гына чабалар. Кайчакта алар өркеп тә, кыелып та китәләр. Кайда гына мине егып калдыралар инде дип, минем җаным тәнемә сыймый бара. Күкнең күкрәве арта гына бара. Шул вакыт бөтен

дөнья коточкыч бер хәлгә әйләнә. Шалтырап яшеннәр яшьниләр. Урман тагы бер яп-якты, бер дөм-караңгы була. Чаба, чаба, чаба мин бер урман ачыклыгына килеп чыгам. Ерак түгел бер җирдә печән кибәне төсле бернәрсә тора. Мин тиз генә аның янына ук барып җитәм. Бернәрсә юк. Йөрәгем жу итеп китә. Өрәк, җен, шүрәле дигән нәрсәләр минем исемә төшә, гүя теге печән кибәне шул өчнең берсе... Мин аның янына килүгә, ул юк булды. Кычкырып елыйсым килә. Шүрәлегә курыкканны белдерәсем килми. Курыкканыңны белсә, ул кытыклап үтерә, имеш! Җен белән өрәктән котылу өчен бар кебек белгән, йә бикләгән догаларны, «Аятел-көрси»не укырга кирәк, диләр иде. Ерак та китмәдем: минем алдымда берничә арбалы кеше бара. Аларның сызгырганнары, сөйләшкәннәре миңа ап-ачык ишетелә. Мин, бераз шатланып, бар көчкә чабып, аларның артларыннан җитмәкче булам. Барып җитәм, бернәрсә анда юк. Һәммәсе күздән юк була. Минем курку чиктән аша. Бөтенләй катам. Ни уйларга да, ни эшләргә дә белмим. Тирә-ягымны җеннәр, шүрәләләр, өрәкләр урап алганнар, тик минем көчем генә, түземлелегем генә аларны миңа якын җибәрмиләрдер, дим. Теге печән кибәне белән әлеге арбаларның җен булуларына мин чынлап ышанам. Тик бер яктан бозлы яңгыр килеп басмаса ярар иде, дип телим. Күкнең күкрәве катылана, яшеннең яшьнәве көчәя барса да, урман өстендәге болытлар кояш баешына таба авышкан төсле булалар. Минем өстән зур гына, сирәк кенә тамчылы бер яңгыр бик тиз узып китә. Берничә урында минем күлмәгем тәнемә ябыша. Төшлек турындагы болытлар кояш баешы ягында дөнья тетрәтеп шалтырый, шалтырый... Мин әллә кая барам. Бара торган юлым да миңа таныш түгел. Туктап тормас өчен, тик бер якка таба гына чаба бирәм. Аз гына яфрак шылтырап, селкенеп һәм бәрелеп китсә дә, шүрәле муеныма атланып, кытыклап үтерер төсле булып, йөрәгем бер

әрни, бер туңып, бер кызып китә. Ул арада минем бәхеткә таң да ата башлый. Таң аткач, этәч кычкыргач, җеннәр, шүрәлеләр, өрәкләр юк булганын белеп, минем куркуым җиңеләя һәм азая башлый. Бара-бара урманны бөтенләй кисеп, бер арыш кырына килеп чыгам. Кайсы авылның кыры икәнен белмим, ул миңа таныш түгел. Ачыгып һәм арып беткән атларым арышка кадалалар. Мин кулымдагы бер тышавым белән аларны кыйный-кыйный, шул арышларны таптатып, әллә кайда, еракта томанлы гына күренгән бер авылга юнәлдем. Бу авыл чын үз авылыбыз икән. Мин аның янына барып җиткәч тә, аны танымыйм, башым әйләнгән. Тик капкабыздан керүгә иркәләнеп, йә бик шатлыгымнан кычкырып елап җибәрдем. Монда шүрәлеләр, өрәкләр, җеннәр юк булалар. Әни белән апам йөгереп чыгып, мине күтәреп алып өйгә керәләр. «Балакаем, ни эшләдең, битләрең тырналып, канап беткән, ни булды сиңа»,— дигән тавышка: «Урманда адашып йөрдем. Төн буе малайларны таба алмадым, абзый кырда»,— дидем дә йокларга яттым.

Минем кайгыдан йортның асты-өскә килгән, читтә кыш укып, җәй бераз гына вакытта кунак булып йөри торган шәкерт бала булганга, өебездә мине артыграк сөяләр һәм яраталар иде. Абзыем Гариф иртәгесен урманда мине эзләп, интегеп һәм йөдәп беткән. Минем хәбәрне ишеткәч, ул куркып, көн буе өйгә кайта алмады.

Менә мине шулай ай алдады!

*1913*



# Мөгаллим

Мин тимер юл белән «Д» станциясенә килеп төштем (Уфа губернасында). Чөнки мин бара торган «К» авылына шуннан башка уңайлы юл юк иде.

Вокзалга төшүем белән, минем читкә китүче мосафир икәнемне белеп, татар ямщиклары мине чолгап алдылар: «Барин, тебе ямщик надо? Повезем»,— тавышлары күтәрелде. Мин кая барачагымны белдергәч, ямщиклар арасыннан берсе алга чыгып: «Әйдә, барин, сезгә юлдаш та бар, сезгә күңелле дә булыр, икегезне дә алып китәрмен. Атларым бик яхшылар, очалар гына!..» — диеп, мине алып китте.

Шул арада миңа юлдаш булачак кеше дә килеп җитте. Без таныштык, ул үзен мөгаллим дип тәкъдим итте. Мин аңа юлдаш булуыма шатлык изһар иттем[1]. Ул арада ямщик: «На, хайваннар, бик матурлап кына бариннарны илтик әле, бәхетегезгә каршы, юлчыларның менә дигәннәре табылды!» — дип сөйләнә-сөйләнә атларын юлга чыгарды. (Чәйлек алу өчен юлчыларны төрле матур сүзләр белән мактау, күтәрү — ямщикларның беренче сыйфатлары инде.)

Ямщикның өстендә киң ак чикмән. Билен бик нык бәйләгән, башында чәүкә оясына охшаган, маңгаен бөтенләй каплап алган бүрек. Үзе кыска буйлы, сары сакаллы, бөтен битен төк каплап алган. Озын, салынып торган кашлары эчендә күк күзләре җылтырап уйнап торалар. Сөйләшкән вакытта еш-еш уң күзен кыса, сүзе бетәр-бетмәс кытырдап көләргә тотына. Күренгән хәрәкәтләреннән аның хәйләкәр, үткен ямщик икәнен аңлап була.

Пар ат матур гына салдырып китте. Мине алып килгән поезд өч свисток биреп үз юлына юнәлде.

---

[1] *Изһар итү* — белдерү.

Кырга чыгып җитүгә, ямщик: «Сикерттереп алыгыз әле, атлар, бариннарның бәхетенә каршы, бүген юл да таба кебек, атна буена яңгырлар теңкәгә тиеп беткән иде»,— диеп сөйләнә-сөйләнә атларга берәрне төшерде. Вакыйган, атна буена өзлексез яуган яңгыр бик йөдәтеп бетергән, бу җылы, кояшлы көн җанга зур рәхәт бирә иде.

Вакыт күп булып, сентябрьнең яртылары узганга, моннан соң ышанычлы көннәр көтелмәгәнгә, бүгенге кояшның җылысыннан күбрәк файдаланасы, тәмле саф һаваны күбрәк йотасы, бу җылы кояш капланыр да, җил чыгар да, тагы бөтен дөнья ямьсезләнер дип, һәр матур минутның кыйммәтен, ләззәтен белеп, сизеп үткәрәсе килә иде.

Мин, бөтен дөньямны онытып, бертөрле рәхәт тынга чумып бара идем. Ул арада станция дә шактый артта калган иде. Ямщикның чыбыркысын бер уңга, бер сулга селтәп, миңа таба бераз бөгелә төшеп: «Менә бу җирләрнең һәммәсе әүвәлдә башкортныкы булган»,— дип сөйләнә башлавы, мине тынлыктан, тәмле хыялдан уятып җибәрде.

Башкортларның хәлләре миңа бик ачык мәгълүм булганга, ямщик сүзе миңа ят вә яңа тоелмады.

Мин сүзне икенчегә борып:

— Иптәш, быел да мөгаллим буласызмы? Әллә хәзер үк мөгаллимлеккә барасызмы? — дип сорадым.

— Мин бара торган «К» авылына мөгаллимә кирәк, дип хәбәр булган иде. Рәфикам[1] өчен шуны белешергә барам. Үземнең урыным бар. Рәфикамне монда урнаштыргач, үзем мөгаллим булып башка җиргә китәм.

— Рәфикагез әүвәл кайда укыткан иде соң?

— Әле беренче елы гына. Укытканы юк, укыды.

---

[1] *Рәфика* — берәүнең хатыны, тормыш иптәше.

— Кайда укыды, сезнең аңа рәфикъ булуыгыз бер ел гынамыни?

— Өченче ел инде. Аның тарихын кыска гына булса да сөйлим инде. Рәфикам фәкать үземнән генә укыды. Миңа килгәнче, аз гына язу танырлык кына укыган иде. Мин мәдрәсәне тәмам итеп чыккач, бер ел мөгаллим булдым да аны алдым. Аны да мөгаллимә итү уе белән үзем бик нык тырышып укыттым... Минем планыма буйсынып бик тырышып укыды. Бар көчен шуңар сарыф итте. Ике ел тоташ үземдә укып, быел Уфадагы мөгаллимәләр курсында да беренче булып чыкты. Менә быел башлап мөгаллимә була. Киләсе җәйгә, исән булсак, ул тагын укуын дәвам иттерер. Ул бертөрле булгач, үземнең ныклап русча укырга уем бар.

— Үзегезнең дә матди җәһәтегез тәэмин ителмәгәч, рәфикагез дә ярдәм итәрлек булмагач, ике ел бик читен үткәндер. Ничек соң башта ук берәр мөгаллимә алырга уйламадыгыз?

— Читенлекне сөйләргә дә ярамый инде. Ике ел эчендә дөньяның ачысы-төчесе тәмам татылды, мин инде бөтен авырлыкны үземнең идеям өчен корбан иттем. Рәфикамә юлыгуым ихтыяри эш булмады. Надан икәнен белсәм дә, аны кеше итүемә ышандым. Минем шәкерт чагымда ук үзем мөгаллим, рәфикам мөгаллимә булып, изелгән, беткән татар милләтенә хезмәт итү беренче идеалым иде. Шунда гына бәхет төсле иде. Хәзер инде, Аллага шөкер, максатыма ирешеп киләм. Инде бераз гына мәшәкать чигәсе калды.

— Туганкай, мин сезне мондый идеалыгыз белән тәбрик итәм. Күргән авырлыкларыгыз үзегез өчен түгел, бәлки, мөкатдәс санаган милләтегез өчен сез үзегезнең мең газап белән тапкан тиеннәрегезгә гади бер татар кызын укытып, тырыштырып милләткә яраклы, файдалы бер эшче ясагансыз. Хәзер инде ул

үзе меңләп татар кызын мәгърифәт нуры белән яктыртачак. Сез инде мондый гали, чын файдалы эшегез өчен үкенмәссез, әлбәттә, үкенмисездер бит?

— Юк, үкенмим. Түземлек бетеп, башны кайда куярга урын тапмыйча изелгән вакытларда үземне шелтәли идем, хәзер инде онытылды. Рәфикамнең мине аңлавы, эшемне тәкъдир итүе тагын да өметемне арттыра, җиңеллек бирә.

Матур гына сөйләшеп барган вакытта, ямщик, юл кырыенда тирес казып яткан дуңгызны чыбыркы белән сыдырып, әче кычкырып җибәрде. Дуңгызның чинаганы биш чакрымга ишетелгәндер. Ямщик: «Ах, мәлгунь, дин дошманы, атларны куркыта язды»,— дип, тагын берничәне өстәде. Аннан соң: «Мәлгуньне симерткәннәрмени!» — дип кытырдап көләргә тотынды. Без дә кушылдык, без тагын сүзне бордык.

— Рәфикагез нинди шартлар белән мөгаллимә булып бара?

— Әйтергә оят, иптәш, кышлык өчен айга ун сум. Кырык кыз бар, имеш.— Жалуньесе аз икән. Безнең мөгаллим, мөгаллимәләрнең хәлләре бик күңелсез инде. Мәгыйшәтләре[1] һич тәэмин ителмәгән.

— Мөгаллим, мөгаллимәләр өчен иң читене шул. Алар һәр җирдә хосусый байлар тарафыннан чакырылалар. Аларга шул чакырган байларның кесәләренә карап йөрергә туры килә. Әгәр шул экономия бирә торган бай кәефенә карап йөрмәсә, мөгаллим яки кыш уртасында куыла, яки икенче кыш алынмый. Бер җирдә урнашып берничә ел торган мөгаллим бик сирәк. Көз җиткәч, мөгаллимнәр анда сугылып, монда сугылып урын эзләргә тотыналар. Бер идеалың булмаганда татар галәмендә мөгаллим булу — иң кара хезмәтче булудан да читен эш.

---

[1] *Мәгыйшәт* — тормыш

— Шулай инде, туган, элегә татар галәмендә бер эшебез дә җайга салынмаган, һәммә эшебез томан, болыт эчендә. Сез инде шул мөкатдәс идеалыгыз белән барыгыз. Икәүләп торып татарның яңа нәселен агартырга тырышыгыз!

Шуннан соң безнең арада сүз киселде, икебез дә уйга чумдык. Күп вакыт үтмәде, мөгаллим төшә торган авылга да килеп җиттек. Мөгаллим төште. Аннан аерылу, яңа таныш булса да, миңа шактый күңелсез булды. Мин аерылуыма чын күңелемнән тәәссеф итеп[1] үз юлыма юнәлдем. Минем барачак авылым аннан җиде чакрым иде. Мөгаллим — озын гына буйлы, ябык чырайлы, озынчарак кына йөзле, мөлаем зур гына соры күзле, карап торырга сөйкемле, уйчан, җитди генә бер егет. Һәрбер сүзеннән, хәрәкәтеннән тормыш белән изелгәнлеге күренеп тора. Көлсә дә салкын, кайгылы көлә. Вакытсызрак чыккан маңгай җыерчыклары да аның үткән тормышыннан хәбәр биргән төсле күренәләр. Юл буе мин аны оныта алмадым. Аның нык, саф идея иясе булуына ышандым. Авылдан бераз киткән идек, ямщигым миңа таба борылып, уң күзен кысып көлеп: «Әллә моның хатыны мөгаллимә булырга укыймы? Аннары эш барып чыга инде... Авылыңнан гына кач, йөзендә, төсендә мөселман кыяфәте дә юк!» — дип куйды.

Мөгаллимнең сөйләшкәннән тыш артыграк бирмәве, чәйлек төртмәве ямщикның кәефен бозды бугай — ул һаман аңардан көлеп кенә барды.

Барган авылда өч көн тордым да яңадан «Д» станциясенә киттем. Ни күзем белән күрим: юлда әлеге мөгаллим юлдашым рәфикасен урнаштырырга «К» авылына килә. Без яңадан очрашуыбызга шатланыштык, ул мөгаллимәсе белән мине таныштырды. Алар-

---

[1] *Тәәссеф итү* — кайгыру, борчылу.

ның килгән мәнзарәләре[1] мине бик борчыды. Аларның тарантас артына бәйләгән яшел сандыктан башка нәрсәләре күренми, мөгаллимәнең йөзендә дә арыганлык, изелгәнлек галәмәтләре сизелә иде кебек. Мин актык кул бирешкәндә: «Милләтебезнең истикъбале[2] сезнең кебек эшлекле, каһарман мөгаллим вә мөгаллимәләргә баглы икәнен хәтердән чыгармагыз, сезнең бөтен читенлеккә түзеп, җиң сызганып эшләвегез генә безгә өмет бирә. Сез милләтнең мәгънәви тамыры: сез нык булсагыз, аның яфрагы яшел, чәчәге матур, җимеше татлы булыр. Яшәгез, татарга файдалы затлар!» — дип, аларның күңелләрен күтәрергә тырыштым. Аларның кайгылы, төшенке күңелләрен аз гына булса да күтәрү минем мөкатдәс бурычым төсле күренде. Аерылыштык. Алар күздән югалганчы торып, эшләпәмне селкеп, исәнләшеп киттем. Бу миңа шактый җиңеллек вә рәхәт бирде. Көннең дә кәефе юк. Һава салкын, җилле. Күктә болытлар да бөтен дөньяны каплап алганнар иде.

*1913*

---

[1] *Мәнзарә* — күренеш.
[2] *Истикъбаль* — киләчәк.



## Сандугач

Майның урталары. Мин кышын шәһәрдә укып, җәй туган илемә кайттым. Авылның иң матур вакыты: көннәр җылы, ямьле, һава саф, ләтыйф[1], авылны урап алган кырларда төрле ашлыклар ямь-яшел булып үсәләр. Күкне тутырып тургайлар сайрый. Кырларны бөтенләй әйләндереп алган урманнардагы төрле агачлар куе, яшел яфракларга, чәчәкләргә күмелгән. Анда тагын мең төрле кошлар сайрый. Анда сандугачлар, анда күкеләр, анда тагын тургайлар һәм башкалар.

Урманнарның аланнары төрле-төрле матур чәчәкләр белән бизәкләнгән. Ул чәчәкләр куе үләннең карасу кыяклары эченнән, күктәге йолдызлар кебек күзгә карап, көлеп, елмаеп торалар. Куе агачлар эченнән вак ташлыклардан көмеш кебек суы салкын чишмәләр мөлдерәп һәм чылтырап агалар. Авыл

---

[1] *Ләтыйф* — йомшак.

аркылы чыккан тирән генә, тар гына саф сулы инеш ямь-яшел болынны икегә аерып китә. Ул инештә бер чыкмыйча балалар, үрдәкләр, казлар җәй буе коеналар. Ул инешкә төш вакытында су эчәргә ат, сыер, сарык көтүләре төшерәләр. Матур соң безнең авыл! Болынга чыксаң, болыннан кырга барсаң, кырдан урманга китсәң, урманнан кайтасы килми. Тәмле һаваны йотудан, матур кыр, урманны караудан, кошлар тавышы тыңлаудан һич тә туймый йөрисең. Утырасың, ятасың, рәхәт, өй искә дә килеп төшми. Безнең йорт артында гына бер кечкенә генә бакчабыз бар. Анда зур агачлардан: тал, карагай, каен, шомырт, миләш; кечкенәләрдән: чия, карлыган, кура җиләк үсә. Карт шомырт, яшь каен һәм киң яфраклы өлкән карагайлар уртасында кечкенә бер алан — ачыклык бар. Ул ачыклыкка карлыган, чия түтәлләренең бер башлары килеп чыга. Мин һәрвакыт иртән шул куе гына үләнле һәм күләгәле аланда укып утырам. Күп вакыт ялгыз гына булам. Менә миңа иптәшкә бу бакчага бер сандугач ияләшә һәм миннән ерак түгел куе яфраклы тал-тирәк башында еш-еш сайрый башлый. Мин аның безгә килүенә һәм бакчага ияләшүенә бик шатланам. Гүя ул миңа әллә кайчаннан бирле көткән кунагым төсле тоела. Ул сайрый башлагач, мин укый алмыйм, тик аның тавышын гына тын алмыйча тыңлыймын да тыңлыймын.

Бигрәк моңлы, бигрәк ямьле, бигрәк гүзәл сайрый да инде ул!.. Баласын суга төшереп җибәргән ананың өзелеп-өзелеп, әрнеп-әрнеп елаганы кебек, сандугач та һич туктый алмыйча, онытылып, бирелеп сайрый да сайрый. Мин күп вакыт дөньямны онытып, аның тавышына, моңына бирелеп, тирән уйга батам, рәхәткә чумам, кулымнан китапларым да төшә. Ирексез күзләрем тал башына текәләләр. Кайсыбер вакыт сандугач туктаган, очып та киткән була. Минем колагыма һаман сайраган моңлы тавышы

ишетелә. Сискәнеп китәм, юк була. Кайсыбер чакта минем яныма кечкенә бер сеңлем дә килә. Ул әле ун яшендә генә, матур гына йөзле, озын керфекле, зур гына күзле, бик иркәле. Ул бигрәк тә туган җанлы: син кайгырсаң, ул да кайгыра, еласаң, ул да елый, шатлансаң, ул да шатлана. Бервакыт өзелеп-өзелеп сандугач сайрый. Ул минем яныма ук утыра да агачка, сандугачка таба карап:

— Абый, сандугач нигә болай сайрый икән? — ди.

— Чит илләрдә калган ата-анасын, туганнарын сагынып сайрый. Аның җырлавы, елавы, моңаюы шулай инде,— дим.

— Ул беләмени, кош бит ул,— ди сеңлем.

— Белә шул, белмәсә шулай сагынып сайрамас иде ул...

— Шәкерт абый, син читтә безне сагынасыңмы?

— Сагынам. Мин дә шулай сезне сагынып җырлыйм һәм уйлыйм.

— Әнине дә, мине дә һәм бүтән туганнарыңны да сагынасыңмы?

— Сагынам шул, күрәсем килә.

— Без дә бит сине бик сагынабыз. Әнием егетләр гармун уйнап китсәләр дә, сине сагына, кич утырганда кызлар җырласа да, ул елый да, гает көннәрендә, бәйрәм ашлары пешергәндә дә сине сагына: «Менә шәкерт абыең гына монда юк»,— дия иде ул. Ул арада әни чәйгә чакыра. Мин сеңлемне бик матур гына сөям. Ул да мине кочаклый, үбә. Без өйдә өчәү генә: әни, мин, сеңлем. Һаман көннәр үтә, мин бик күңелле генә авылда торам. Җанда рәхәт, тыныч, күкрәк тәмле һава сулый да сулый. Минем моңлы, серле иптәшем һаман бакчадагы сандугач була. Мин аны һәрвакыт сагынып каршы алам. Аның тавышыннан һич тә туймыйм. Туктаса гына өзелеп калам. Ул һаман тал-тирәк башында гына сайрый. Бик сирәк кенә әллә куркынып, карагай башына да



күчә. Мин әле белми идем, сеңлем сандугачның оясын эзләп тапкан. Куе гына карлыган чыбыклары арасына бик матур гына түм-түгәрәк итеп ясалган дүрт йомыркалы оя. Мин бик озак карап торам да сеңлемә бер дә аңа якын бармаска, йомыркаларны тотып карамаска кушам. Оядагы йомыркасын кул белән тотсаң, сандугач бакчадан күчә, имеш!..

Майның 25е. Мин иртән вакытсыз уянам да бакчага керәм. Сәгать биш кенә. Кояшның иртәнге сөекле, шәфкатьле нурлары яфрак араларыннан минем аландагы җиләк чәчәкләре арасында уйныйлар, йөгерәләр. Минем иптәшем сандугач сайрый да сайрый, сайрый!.. Мин тал-тирәк төбенә барып ятам. Тал-тирәкнең яфраклары арасында сандугачымны эзлим дә эзлим. Сандугачкаем, кечкенә генә бер ботакка баскан да, әле бер якка, әле икенче якка каранып, әйләнеп, чумып, онтылып сайрый. Ул бу көн шундый матур, шундый гүзәл сайрый, һич тә түзәрлек түгел, аның сайраганда бер үрелеп, бер киерелеп һәм бер йомылып киткән тамак астын минем үбәсем килә. Һичбер аның болай каты, артык гүзәл, матур сайраганын ишеткәнем юк иде. Нигә генә болай өзелә икән, нәрсә генә уйлый икән, дим. Ул да туктый, мин тагын да кереп ятам. Мин яңадан уянганда сәгать унбер була. Мин бакчага таба бара идем, менә сеңлем бакчадан чабып елап кайта: «Шәкерт абый, шәкерт абый, сандугачың үлгән, тал төбенә егылып төшкән!» — ди. Минем йөрәгем өзелеп-өзелеп китә. Ни әйтергә белмим, тик «Ах, бичара, ах, бичаракаем» гына дия алдым. Сеңлем дә үзенә тилмереп, бер миңа, бер сандугачка карап тора. Ул да яшьле күзләре белән миңа ни әйтергә дә белми. Мин сандугачны сөям, бүген иртә генә сайраган иде бит, бичарам! дим. Әле үлгәч тә һаман көлеп, елмаеп торган төсле, аның мөлаем күз кабаклары, керфекләре матур гына йомылган. Кечкенә генә борыны агарып, саргаеп киткән һәм

аның канатлары кысылып кына торалар. Мин кызганам, әрним. Гүя минем бик кыйммәтле нәрсәм югалган: җаным сызлана, күңелем сына, бакчага керәм. Анда өметсезлек. Сандугачкаем юк та юк! Кич җиткәч, сандугачны бик матурлап ак кәфенгә төрәм дә сеңлемә бакчаның иң матур җиренә күмәргә кушам. Икенче көнне үк исемә төшеп, сандугачның оясын тагын күрергә, карарга барам. Ни күзем белән күрим: оя җимерелгән, ватылган. Йомыркаларның берсе дә юк. Мин тагы кайгырам, пошынам: бичара, бичара син шул оя, йомырка, бала кайгысыннан моңаеп, сайрап үлдеңме икәнни? дип, өметсезлек белән бакчадан чыгып китәм. Ләкин ул сандугачны бик озак гомер оныта алмыйм.

*1914*





# Йолдыз бала

*(Оскар Уайльдтан)*[1]

Ике ярлы утын ячучы соңга калып кына кичен өйләренә кайтып баралар иде. Аларның юлы нарат агачлыгы аркылы үтәргә туры килде. Кыш көне иде. Ачы, каты суык бөтен табигатьне туңдырды, богаулады. Кар калын катлау булып җирне каплады. Юлчылар узып бара торган кечкенә юлның ике ягындагы агач ботаклары да суыктан шартлап ярылып китәләр иде. Урмандагы җанварлар, кошлар да һәм кортлар да каты салкыннан газап чигәләр иде. «Ах, нинди гаҗәп һава, нинди салкын» дип, бүре дә койрыгын кысып, аксап, кайда керергә дә белми. Чыпчыклар да: «Уят, уят, уят, уят, безнең җиребез үлде,

---

[1] *Оскар Уайльд* — Уайльд Оскар Фингал (1854—1900) — инглиз язучысы.

аны ак кәфенгә урадылар»,— дип сөйләшәләр һәм суыктан зарланалар. Суык шул дәрәҗәдә каты иде ки, чыршы агачының эчендә торучы кечкенә тиеннәр, елыныр өчен берсе икенчесенә сыенып, якты дөньяга карарга да куркып, бер уймак кебек төрелеп торалар иде. Тик мөгезле мәче башлы ябалаклар гына бу көнге һавага шатланалар иде. Аларның йоннары, канатлары кыраулаңып катса да, алар аның өчен борчылмыйлар, тик үзләренең саргылт күзләрен уйнатып, бөтен урман эчендәге тынлыкны бозып, берсе икенчесе белән кычкырышалар һәм шаулашалар. «Ах, бездә нинди матур көн бүген!» — диләр иде.

Ике утын яручы бармакларына бик нык өрә-өрә тимерле зур итекләре белән шакыр-шокыр итеп кар өстеннән һаман ераграк киттеләр. Бер мәртәбә тирән көрткә батып, көчкә генә чыктылар, икенче мәртәбә туңган сазламыкның шома бозына таеп егылдылар да күтәреп кайта торган чыбык-чабыклары таралып китте. Алар яңадан чыбыкларын бәйләп юлга чыктылар. Ул арада алар юлдан да ялгыштылар, аларны курку басты. Тик бераздан иске эзләренә төшеп, бик саклык белән генә алга барып урман авызына чыктылар да, үз авылларының утларын күрделәр. Авылны күргәч, алар шатлыктан үзара көлешеп җибәрделәр, аларга кар каплаган җир көмешкә, ай алтынга эверелгән төсле булды. Ләкин шунда ук аларның беренче шатлыклары бетеп, үзләренең начар хәлләре турында уйлап кайгырыша башладылар. Аларның берсе болай диде:

— Ник шатландык әле без, тормышның тик байлар өчен генә икәнен яхшы беләбез бит. Безнең кебек бичара ярлыларга ни кызык, ни шатлык бар соң? Шушы урманда туңып үлсәк яки берәр ерткычның тырнагына эләксәк тә аяныч түгел бит.

Аңа каршы икенчесе:

— Бик дөрес, туган, берәүләргә бик күп, икен-

челәргә бик аз бирелгән. Дөньяның яхшылыклары бик аз адәмнәр арасында бүленгән, мәгәр кайгылардан башка безгә нинди генә әйбердә дә бертигезлек күренми,— дип җавап бирде.

Шулай итеп, алар үзләренең начар көннәре турында озак кына зарланышып, кайгырышып барган бервакытта, искиткеч бер вакыйга булды: бик матур елтыравыклы бер йолдыз атылды. Ул, күк диңгезен ярып, башка йолдыз яныннан кысылып китте дә бик зур тамаша белән карап торган юлчылардан берничә адым гына бер җиргә килеп төште. «Әй, бу бит бер казна! Аны эзләп табарга кирәк!» — дип кычкырышып, йолдыз төшкән җиргә чаба башладылар болар. Аларның берсе кызурак барып, чыннан да, бер алтын әйбернең җирдә ятканын күрде. Бу әйбер йолдыз төшереп, алтыннан ясалган, берничәгә бөкләп куйган бер төргәк иде. Борын килгәне, күктән төшкән мал таптык, дип, артта калган иптәшенә кычкырды. Ул да килеп җиткәч, тапкан малны үзара бүлешү өчен төргәкнең янына гына килеп утырды. Төргәкне ачып җибәрсәләр, ни күзең белән күрәсең, алтын да, көмеш тә, башкача бер кыйммәтле нәрсә дә юк! Тик... йоклап ята торган кечкенә генә бер бала. Аларның берсе икенчесенә карады да:

— Нинди өметсезлек! Менә безнең уй, хыялыбыз нәрсәгә барып терәлде? Безгә бәхет юктыр инде. Бу бала белән генә ни эшлисең? Аңардан адәм баласына ни файда булыр? Аны монда калдырыйк та, үз юлыбыз белән китик. Без бит үзебез дә фәкыйрьләр. Безнең үзебезнең дә балаларыбыз бар. Чит кешенең баласы өчен үз балаларыбызның икмәкләрен тартып алырга һичбер хакыбыз юк,— диде.

Моңа иптәше каршы килде:

— Юк... Бу һич тә мөмкин түгел. Әгәр бу баланы кар өстендә һәлак булырга ташлап китсәк, бик катылык, мәрхәмәтсезлек кылган булабыз. Мин дә

синең кебек үк фәкыйрь. Минем дә зур гаиләм бар, өемдә дә җитми, шулай да мин бу баланы үз өемә алып кайтып, хатыным тәрбиясенә тапшырырмын,— диде дә бик саклык белән генә баланы кулына алып һәм суык үтмәсен өчен төргәккә ныграк урап, өенә таба китте.

Юл буенча иптәше аның йомшак күңеллелегенә исе китеп барды һәм авылга җитәр алдыннан гына:

— Син баланы алдың, инде миңа төргәкне бир, чөнки бергә тапкан әйберне бүлешергә кирәк,— диде.

Баланы алып кайтучы:

— Ялгыш әйтәсең, бу төргәк сиңа да, миңа да түгел. Ул баланың үз әйбере. Хуш, сау бул инде,— диде дә, үзенең өенә кайтып, ишек кага башлады.

Аның хатыны ишекне ачып, таза-сау кайткан ирен күрде дә шатлыгыннан аны кочаклады, үпте һәм аның өстендәге карларны сыпырып, җилкәсендәге бәйләгән чыбыкларын алып, өйгә керергә кушты. Мәгәр ире бусагадан эчкә атламыйча торды:

— Мин урманда бер әйбер таптым, аны синең карамагыңа китердем,— диде.

Хатыны:

— Нәрсә китердең? Безгә күп кирәк, чөнки өебездә һичбер әйберебез юк, күрсәт инде,— дип сорады.

Ире, төргәкне сүтеп, хатынына йоклап яткан баланы күрсәткәч, хатынының исе китеп:

— Әй син, үз балаларыбыз гына җитмәгәнмени? Ни генә уйлап тагын өебезгә ташландык бер бала китердең. Ул безгә бәхетсезлек китермәсме икән? Аны ничек карарга кирәк? — диде һәм ирен орышырга тотынды. Аңа каршы ире:

— Юк, хатын, бу Йолдыз бала,— диде дә ни рәвештә һәм ничек итеп баланың табылуын сөйләп бирде. Ләкин хатыны һаман тынычлана алмады.

— Безнең үз балаларыбызга да тәрбия җиткерә

алмыйбыз. Без чит баланы ничек карыйк соң? Безгә дә бит ярдәм итеп, мал китереп бирмиләр,— дип борчыла гына барды.

Аңа ире:

— Син шулай дисең, хатын, чыпчык балаларына Тәңребез азык җибәрә бит,— диде.

— Соң, чыпчыклар ачтан үлмиләр дип уйлыйсыңмы? Хәзер кыш көне түгелме соң? — диде хатыны.

Утын яручы хатынының бу соңгы сүзенә бер җавап та бирмәде. Тик аска гына карап торды. Ачык ишектән өйнең эченә кереп торган каты салкын җил хатынны өшетә башлады. Ул өшеп, калтыранып:

— Нигә соң ишекне япмыйсың, карт, өй эченә салкын җил кереп тора, мин туңам инде,— диде.

Аның сүзенә каршы ире:

— Күңел җылысы булмаган бер өйдә һәрвакыт шулай салкын була ул,— диде.

Шуннан соң хатыны, бер сүз дә җавап бирмичә, утка таба китте дә, аз гына торгач, яшькә тулган күзләре белән иренә карады. Шуннан соң аның ире зур-зур гына атлап эчкә керде дә баланы хатынның кулына бирде. Хатыны бу баланы үбә-үбә үз балалары белән бергә китереп яткырды һәм ашатты. Икенче көнне утынчы Йолдыз баланың төргәген сандыкка җыеп куйды. Хатыны баланың муенында булган гәрәбә теземен төргәк янына салды.

Йолдыз бала утынчының үз балалары белән бергә үсте. Алар белән бер савыттан ашады, алар уйнаган уеннан бу да калмады. Еллар, көннәр үткән саен ул, Йолдыз бала, матурланганнан-матурлана гына барды. Ул үзенең карага мәел[1] чәче, ак, нәфис һәм балкып торган йөзе, ал чәчәкләргә охшаган иреннәре, ялтырап, уйнап торган матур күзләре һәм искиткеч

[1] *Мәел* — тартым.

зифа буе белән бөтен авылның кешеләрен гаҗәпкә калдыра һәм барчасын үзенә тарта иде.

Аның матурлыгы файдага ашмады, ул бик һавалы, тәкәббер, мәрхәмәтсез булып үсте. Ул утынчының үз балаларына һәм авылның бөтен баласына бик түбән күз белән карый башлады. Үзен «гали бер нәселдән, йолдыз баласы» дип таныганга, башкалардан нәфрәтләнә, җирәнә иде. Бара торгач, бөтен авыл баласы аңа буйсындылар. Йолдыз бала алар өстеннән бер хаким булды. Йолдыз бала ярлыны да, сукырны да, аксакны да кызганмады. Дөресен әйткәндә, нинди генә бичараны күрсә дә, кызгану, аяу түгел, аны ничек булса да мыскыл итәргә, рәнҗетергә тырышты. Икмәк сорап йөрүче фәкыйрьләрне яратмады. Аның матурлыгы алга киткән саен, аяусызлыгы, башкаларга усаллыгы да арта гына барды. Ул тик үз-үзен генә сөя иде. Җәй көннәрендә тын һавада бер авылның бакчасындагы күл янына барып саф, тын суга төшкән үз күләгәсенә карый һәм үзенең матурлыгына сокланып, шатлыгыннан көлеп тә җибәрә иде.

Утынчы һәм аның хатыны ничә мәртәбәләр аны тиргәгәннәр иде: «Йә, уйлап кара әле, балакай, без сине ничек тәрбия кылдык, ни өчен син фәкыйрьләргә, ятимнәргә болай каты мөгамәлә кыласың, нигә аларны аз гына кызганмыйсың?» — диләр иде. Бер карт рухани да күп вакытны аны үзенә чакырып, вәгазьләп, аның күңелендә бөтен мәхлукатка[1] мәхәббәт тудырырга тырыша иде. «Чебен дә сиңа якын, аңа да усаллык кылма, бөтен кошларның да үзләренә күрә ирекләре бар. Син үз кәефең өчен аларга тозаклар салма. Мәхлукатның үз өлешенә күрә бер урыны бар. Дөньяга кайгы-хәсрәт

[1] *Мәхлукат* — җан иясе.

кертергә синең ни хакың бар соң, мөгезле хайван да бер җанга тими бит»,— дия иде.

Йолдыз бала аларның киңәшенә, вәгазенә колак салмый, әһәмият бирмичә тора да, тагын алардан тәхкыйранә[1] көлеп, үз иптәшләре янына барып, хөкем сөрергә тотына иде. Бөтен авыл балалары аны баш итеп таныйлар һәм аңа берсүзсез буйсыналар иде. Чөнки ул бик матур, җитез булу өстенә, бик оста бии, сызгыра һәм матур, моңлы тавыш чыгарып, курай уйный иде. Алар, ул кайда китсә, шунда баралар, ни кушса, шуны эшлиләр. Йолдыз бала бер нечкә чыбык белән әрләннең күзләрен казып алганда, кошларның канатларын каерганда, үтеп баручыга уйнап таш атканда да, аның иптәшләре тик елмаеп, көлеп кенә торалар иде. Ул һәр урында һәм һәр эштә аларны кушып йөртә-йөртә, алар да үзе кебек мәрхәмәтсез һәм каты күңелле булып киттеләр.

* * *

Бервакыт бу авылга бер фәкыйрь хәерче хатын килеп керде. Аның киеме тетелеп, өзгәләнеп беткән һәм ташлы, базлы [чокырлы] юлда килә-килә аякларыннан каннар тамып тора иде. Ул хатын бик кызганыч хәлдә, аз гына ял итәр, тын алыр өчен бер агач төбенә килеп утырды.

Йолдыз бала бу хатынны күрүгә үзенең иптәшләренә әйләнде:

— Карагыз әле, бу нинди коточкыч, ямьсез хәерче килеп, матур, ямь-яшел агачның төбенә утырган. Әйдәгез, ул җирдән аны куып җибәрәбез. Чөнки ул безгә ямьсез, куркыныч! — диде дә, аның янына килеп, аннан көлә башлады.

---

[1] *Тәхкыйранә* — мыскыллы.

Ул хатын исе китеп, бер дә күзен алмыйча, бу баланың күзенә текәлеп карап тора иде.

Ерак түгел бер җирдә утын ярып торган баланың тәрбияче атасы моны күреп алды да тиз генә килеп:

— Син мәрхәмәтсез, син шәфкатьсез! Бу фәкыйрь, бичара хатынның ни гөнаһсы бар. Ни өчен син аның белән кансыз мөгамәлә кыласың? — диде.

Йолдыз баланың тагын ачуы кабарып, ут кебек янып, җиргә типте дә:

— Миннән хисап алырга синең хакың юк, мин синең балаң түгел. Мин сиңа буйсынмыйм! — диде.

Аңа утынчы:

— Дөрес, шулай булса да, мин урманнан тапкан вакытта кызганып сине өемә алып кайткан идем,— диде.

Шул сүзне әйткәндә, теге хатын кычкырып, һушсыз булып егылды. Утынчы аны үз өенә алып килде һәм аның хатыны төрле чаралар белән фәкыйрь хатынны исенә китерергә тырышты. Ул тәмам айнып, сулыш алып җиткәч, башка нәрсә хакында бер сүз дә әйтмичә, утынчыдан сораша башлады:

— Син урманнан бала таптым, дидең бугай, әйтче, зинһар, бу вакыйга моннан ун ел элек булмадымы?

— Дөрес, мин аны моннан ун ел элек урманнан таптым,— диде.

— Аның янында нинди әйберләр бар иде соң? Аның муенында бер гәрәбә теземе юк идеме? Ул йолдызлар төшереп алтыннан тукыган төргәккә уралмаган идеме?

Утынчы:

— Дөрес, шулай иде. Син әйткәннәрнең һәммәсен мин аның белән бергә тапкан идем,— дип җавап бирде дә сандыктан бер төргәк белән гәрәбә тезелен алып күрсәтте.

Бу әйберләрне күрүгә теге фәкыйрь хатын үкереп елап җибәрде һәм:

— Бу баланы ун ел элек мин урманда югалткан идем. Бу — минем балам. Барыгызчы, зинһар, тизрәк аны минем яныма җибәрегез. Мин аны эзләп, мең азаплар күрдем. Бөтен дөнья аны эзлидер,— диде.

Шуннан соң утынчы һәм аның хатыны тиз генә өйдән чыгып киттеләр дә баланы чакырдылар. «Өйгә кайт, анда үз анаң көтә»,— диделәр. Йолдыз бала гаҗәпләнеп һәм шатланып өйгә йөгереп керде дә көтеп торган әлеге сәләмә хатынны күреп:

— Кайда соң минем анам? Мин монда бу хәерчедән башка беркем дә күрмим, әйтегез,— диде.

Ул арада фәкыйрь хатын:

— Мин синең анаң! — дигән иде, Йолдыз бала аптырап калды һәм бик ачуланып, маңгайларын җыерып:

— Әллә гакылдан яздыңмы, син хәерче бит, ничек мин синең балаң булыйм?! Син моннан югал, икенче мәртәбә мин синең җирәнеч йөзеңне күрәсе булмыйм! — дип кычкырды.

Хатын баласының сүзләрен өзелеп тыңлап торды да:

— Шулай булса да, син минем балам, мин синең анаң,— дип үкереп елап тезләнде дә ялварып тагын да:

— Мин сине урманга алып бара идем. Качкыннар миңа һөҗүм иттеләр, шул вакыт сине миннән тартып алдылар. Язмышның көненә калдырып, алар сине ташлап киттеләр,— дип елавында дәвам итте.— Мин беренче караштан ук сине таныдым, инде алтын төргәк белән гәрәбә теземне күргәч, тик актык шикшөбһәләрем дә бетте, югалды. Йөрәгем, балам, мин синнән үтенәм, әйдә син минем белән бар, мин бөтен дөньяны калдырмыйча сине эзләдем. Мин сине ташлап китә алмыйм.

Йолдыз бала урыныннан да кузгалмыйча, бер сүз дә әйтмичә торды, хатынның сүзләре аңа бер генә дә

тәэсир итмәделәр бугай. Тик тынлык эчендә аның үксеп-үксеп елаганы гына ишетелә иде. Ниһаять, Йолдыз бала бик борчылган халәттә бу хатынга карады да:

— Чыннан да, син минем анам булсаң да, син монда күренергә тиеш түгел идең. Син бит мине хурлыкка төшерәсең, оятка калдырасың. Мин хәзергә кадәр үземне йолдыз баласы дип исәпләп йөргән идем. Үземнең бер сәләмә хатын баласы икәнемне күңелемә дә китермәгән идем. Соң, соң... син нәрсә белән мине ышандырырга уйлыйсың? Кит инде моннан, кит моннан. Сине күзем күрмәсен! — диде.

Анасы кайгырып, ни эшләргә белмичә:

— Ай-яй балакаем, бер генә мәртәбә үзеңне сөеп калыймчы! Мин бит сине бик авырлык белән генә таба алдым,— дип ялваруында булды.

Йолдыз бала, ачуланып, маңгайларын җыерып, аның өстенә карады да:

— Булмас, ни сөйлисең, син бит...— дип сүзен өзде.

Шуннан соң бу хатын өметсезләнеп урыныннан торды да, канлы яшьләрен агызып, үкси-үкси урманга таба китте. Йолдыз бала, аның китүенә шатланып, яңадан уйнарга иптәшләре янына йөгерде.

Иптәшләре аны күрүгә:

— Сиңа ни булды, син хәзер коточкыч ямьсез бакага һәм бер еланга охшагансың. Син безнең яннан кит, син куркыныч! — дип шауладылар.

Йолдыз бала шуннан соң ни эйтергә дә белмичә, маңгаен җыерды да болар ни сөйлиләр, мин су янына барып үземнең матурлыгымны күрим әле дип, елга янына барып, суга карады. Ни күзе белән күрсен, аның йөзе баканыкына охшаган, бөтен тиресе елан кабыгы белән капланган. Ул үзенең бу төсен күреп, куркып, һушыннан китә язды. Шуннан елап, әрнеп, үлән эченә ташланды да: «Үз анамнан бизгән өчен

миңа бирелгән җәза бу. Мин аңа каты мөгамәлә кылдым. Инде мин бөтен дөньядан эзләп, аны табарга китәм. Аны тапмый торып, мин тынычлана алмыйм»,— диде.

Шул арада аның янына утын яручының кечкенә кызы килде дә кулын аның җилкәсенә салып:

— Син әүвәлге кебек матур түгел икәнсең, аңа шаккатма, китмә, бездә кал, бервакытта да синнән көлмәм! — диде.

Йолдыз бала кызның бу киңәшенә каршы:

— Һичбер мөмкин түгел. Минем куркыныч төсем анам белән начар мөгамәлә кылганлыгымнан, аңа тәмсез сүзләр әйткәнлегемнән Тәңрем тарафыннан җибәрелгән җәзадыр. Шулай булгач, ничек итеп мин монда калыйм. Хәзер миңа көн-төн йокламыйча, аны эзләп табарга, аңардан гафу үтенергә кирәк,— диде.

Шуннан соң урманга качты да урманда анасын кычкырып эзли башлады. Ул кичкә кадәр кычкырып эзләп йөрсә дә, аның тавышына әнкәсе килмәде. Ул, кояш баткач, хәл алыр өчен яфраклар өелгән агач төбенә барып утырды. Аның мәрхәмәтсезлеген белгән кошлар, җанварлар һәммәсе дә ул утырган агачтан һәм җирдән качып киттеләр, тик бака белән елан гына аңардан чирканмады, аның тирәсендә йөриләр иде. Иртән уянып киткәч, агачтан берничә ачы җимеш ашады да, кайнар яшьләрен агыза-агыза, урман эченә таба юнәлде һәм һәрбер очраган мәхлуктан анасын сораша-сораша барды. Ул бер әрләнне күрде дә: «Син җир астында йөрисең, әйтче, зинһар, минем анамны күрмәдеңме?» — диде. Әрләнаңа җавабында: «Син бит минем күземне чукып чыгардың, шулай булгач, мин ничек күрим?» — дип әйтте. Шуннан соң ул бер чыпчыкны күрде дә: «Син иң зур агачларның башларында очып йөрисең, ул җирдән сиңа бөтен дөнья күренә, әйтче, зинһар, минем анамны күрмәдеңме?» — диде. «Кайдан күрим?

Син бит үзеңнең кәефең өчен канатларымны кисеп алдың»,— дип, чыпчык җавап бирде. Алай да булмагач, чыршы куышына оялаган кечкенә тиенгә барып: «Минем анам кайда икән?» — диде. Аңа каршы тиен: «Син минем анамны да үтердең, үз анаңны да яхшыга эзләмисеңдер әле»,— дип җавап бирде. Шулай итеп, Йолдыз бала беркемнән дә матур сүз ишетмәде. Шуннан соң өметсезләнеп, башын түбән иеп, тагын куе урман эченә таба китте. Өч көн баргач, урман авызына барып чыкты да җәелеп ята торган яланга таба юнәлде.

Авылларда очраган балалар аңардан көләләр һәм авыл кешеләре аңар ашарга, эчәргә әйбер, кич кунарга урын да бирмиләр, аның ямьсез, куркынычлы кыяфәтеннән шикләнеп, аны үзләренә якын да җибәрмиләр иде. Һичкем аны кызганмый иде. Ул шул читенлектә, шул начарлыкта өч еллар буена анасын эзләп йөрсә дә, беркем дә әнкәсе турында хәбәр белми иде. Кайсыбер вакыт ул, юлда анасын күргән төсле булып, таш, чокырлы юлдан чабарга тотына, шулай итеп, аякларын чи канга батырып бетерә иде. Ләкин ул анасын һаман таба алмый иде. Аңа каршы очраган юлчылар бернәрсә дә күрмәгәнлекләрен әйтеп, тик аңардан көләләр генә иде. Ул өч ел буена анасын эзләп йөрде. Мәгәр беркемнән дә үзенә җылы сүз һәм ачык йөз күрмәде. Шулай итеп, ул үзенең чәчеп куйган игенен урды, чөнки ул бөтен дөньяны үзенә дошман ясап бетергән иде.

Бервакыт ул кич белән елга буена салынган һәм зур курганлы бер кала янына килде. Бик арыган, талган хәлдә, ул шәһәрнең капкасыннан кереп китмәкче булган иде, ләкин сакчылар аңа ирек бирмәделәр. «Калада ни кирәк сиңа?» — дип кычкырып аны туктаттылар.

— Мин анамны эзлим, мин сездән үтенәмен, мине эчкә җибәрегез, бәлки, мин аны каладан табармын,—

Йолдыз бала ялварса да, булмады, сакчылар аңардан көлделәр генә.

Шуннан соң сакчылардан берсе, кара мыеклысы, үзенең калканын җиргә куеп:

— Менә сиңа дөресе: хәзер сине күреп, анаң һич тә шатланмас, чөнки син сазлы күл бакасыннан чирканычрак һәм иң кабахәт еланнан да ямьсезрәк. Кит син тизрәк, кит. Монда синең анаң юк,— диде.

Шуннан соң сакчылардан кулына сары әләм тотып торганы:

— Кем соң синең анаң, нигә аны эзлисең? — диде.

Йолдыз бала күзләреннән яшьләр агызып:

— Минем анам да үзем кебек бер теләнче, мин аның белән бик начар мөгамәлә кылдым. Инде аны табасым, аның гафуын үтенеп каласым килә, зинһар, мине кала эченә җибәрсәгез лә, бәлки, ул шунда тора торгандыр?! — диде.

Сакчылар аның сүзен тыңламадылар. Йолдыз бала, калага керүдән өмет өзеп, елый-елый китеп бара иде, сакчылар янына кыйммәтле сугыш кораллары таккан, алтынлы тимер кием, калкан кигән бер гаскәри килеп, хәзер генә кемнең калага керәсе килгәнен сорады.

Сакчылар:

— Ул адашып йөри торган бер хәерче бала иде. Без аны куып җибәрдек,— диделәр.

Гаскәри аларга каршы көлеп:

— Бикярга[1] гына җибәргәнсез, без ул комсыз нәрсәне берәрсенә коллыкка бер касә эчемлек бәрабәренә булса да сатар идек,— диде.

Боларның яннарыннан үтеп баручы усал йөзле бер карт моны ишетеп:

— Ул хакка булса мин алыйм! — дип, тиешле ак-

---

[1] *Бикяр* — юкка.

чаны бирде дә Йолдыз баланы үзе белән калага алып китте.

Алар берничә урамнар, тыкрыклар киткәч, бер ишек янына туктадылар. Биек стенага һич тә беленмәслек рәвештә ябыштырылып ясалган һәм өстенә агач ботаклары салынып тора торган ишек теге картның йөзеге кагылу белән ачылып китте. Алар баскычтан бакчага барып чыктылар. Бакчаның бөтен җирендә кара мәк утыртылган һәм төрле җирдә яндырылган балчыктан ясалган зәңгәр кешеләр куелган. Монда кергәч, карт үзенең бизәкле ефәк шарфын алды да Йолдыз баланың күзен бәйләп, каядыр җитәкләп китте. Йолдыз бала күзеннән шарфын алгач караса, үзен җир астындагы мөгездән ясалган фонарь белән генә яктыртылган караңгы бүлмәдә күрде. Карт аның алдына күгәргән икмәк куйды да: «Аша, тыгын!» — диде, бер чынаяк тозлырак су куйды да: «Эч, йотын!» — диде.

Ул Йолдыз баланың ашап-эчеп бетергәнен көтте дә ишекне тимер чыбыклар белән бик нык бикләп чыгып китте.

Бу карт бик билгеле сихерче һәм Нил тау тишегендә торучы бөтен дөньяга мәгълүм фәкыйрь сихерченең шәкерте иде. Ул иртән торды да: «Безнең кала капкасыннан ерак түгел җирдә, урманда өч алтын тәңкә саклана: берсе ак алтыннан, икенчесе сарыдан, өченчесе кызылдан сугылган. Бүген син ак алтыннан сугылганын китерергә тиеш. Әгәр син аны китерә алмасаң, мин сиңа йөз камчы сугармын. Бар син тизрәк. Кояш батар алдыннан, мин сине бакча ишеге төбендә көтеп торырмын. Яхшы кара, әгәр тапмасаң, сиңа читен булыр, беләсеңме? Син бит хәзер минем кол, мин сине бер касә эчемлеккә сатып алдым»,— диде дә, баланың күзен яңадан ефәк шарф белән бәйләп, мәкле бакча аркылы җитәкләп китте һәм, баскычлардан үткәч, йөзеге

белән түбәнге ишекне ачты да Йолдыз баланы урамга җибәрде.

Бала, шәһәр читенә чыгып, усал сихерче карт әйткән урманга таба китте. Бу урман искитәрлек матур иде. Гүя урман хуш исле чәчәкләр һәм сайраучы кошлар белән тулы иде. Йолдыз бала рәхәтләнеп урманга кереп китте. Тик шунысы гына начар иде: ул кайда гына басса да, шул җирдә каты тигәнәк үсә, чәнечкеле чытырманнар аңа юлны каплыйлар, усал кычыткан аны өтәләп, яндырып ала, үләннәр үзләренең инәләрен кадыйлар иде. Шуннан соң баланы өметсезлек каплап алды, шулай булса да, таңнан алып төшкә, төштән алып кояш батканчы сихерче карт әйткән ак алтын тәңкәне бик тырышып эзләде. Кояш батар вакыт калага карап елый-елый кайта башлады. Менә урманны чыгыйм дигәндә генә, куе урман эченнән бер кайгылы, зарлы тавыш ишетелгән төсле булды. Ул үз кайгысын онытты да урман эченә чабып керде.

Ул урман эчендә ауга эләккән куянны күрде һәм куянны кызганып аудан коткарды. «Мин үзем чын бәхетсез кол булсам да, сиңа хөррият бирәм»,— диде. Аның сүзенә каршы куян: «Дөрес, син миңа хөррият бирдең, мине үлемнән коткардың, инде минем сиңа нинди файдам тияр?» — дип җавап бирде. Йолдыз бала: «Мин ак алтыннан сугылган тәңкә эзлим, әгәр мин аны таба алмасам, хуҗа мине кызганмыйча кыйныячак»,— диде. Аңа каршы куян: «Син минем арттан бар, калма, мин аның кайда икәнен беләмен, мин сине нәкъ шул җиргә илтермен»,— диде.

Йолдыз бала бик буйсынып кына аның артыннан китте дә, куянның күрсәтүе буенча зур имән төбеннән көн буе эзләп тә таба алмаган ак алтын тәңкәне барып алды һәм шатланып, куянга рәхмәтләр укып: «Син минем изгелегемә каршы артыгы белән изгелек кылдың»,— диде. Аңа каршы куян: «Юк, һич

артык түгел, син ничек миңа ярдәм итсәң, мин дә шулай гына»,— дип җавап бирде дә урманга чабып китте.

Йолдыз бала калага юнәлде. Кала капкасына җиткәндә генә, башы соры киндергә уралган, йогышлы кутыр чиренә эләккән бер авыру кеше килде. Киндердәге күз өчен калдырылган тишектән кызган күмер кебек тик күзләре генә күренеп һәм янып тора. Ул Йолдыз баланы күрү белән үзенең кыңгырауларын шалтыратып каршы килде һәм ялварып: «Зинһар, миңа акча бир, юкса, мин ачлыктан үләрмен, мине каладан куып чыгардылар, инде мине кызганучы беркем дә юк»,— дип сорана башлады. «Ах абый, миндә бер генә тәңкә бар. Әгәр мин аны хуҗама китермәсәм, ул мине кыйнар, сугар»,— диде бала. Теге авыру кеше һаман соравында, инәлүендә дәвам иткәч, Йолдыз бала кызганып, алтын тәңкәсен аңа биреп калдырды.

Бакча ишеге төбендә көтеп торган сихерче карт аны бакчага кертүгә: «Ак алтыннан суккан тәңкәне таптыңмы?» — дип сорады да юк хәбәрен ишетүгә аны кыйнап, изеп ташлады һәм аның алдына ашарга-эчәргә бернәрсә дә калдырмыйча, буш савытлар гына куйды да яңадан бүлмәне бикләп чыгып китте.

Икенче көнне иртә белән сихерче яңадан Йолдыз бала янына килде һәм: «Әгәр син бүген сары алтыннан суккан тәңкәне табып китермәсәң, мин сиңа йөз камчы сугармын»,— диде.

Йолдыз бала тагын урманга китте һәм бөтен көн буена сары алтын тәңкәне эзләде. Мәгәр бер җирдән дә таба алмады. Ул, кояш батарга якынлаша башлагач, җиргә утырды да еларга тотынды. Ул арада аның янына кичә аудан коткарган куян чабып килеп чыкты һәм: «Нигә елыйсың, урманнан ни эзлисең?» — диде. Аңа каршы Йолдыз бала: «Мин монда кай җиргәдер яшеренеп торган бер сары алтын тәңкәне

эзлим. Әгәр мин аны таба алмасам, миңа хуҗам бик каты җәза бирәчәк»,— дип җавап кайтарды. Куян: «Алай булса, әйдә минем арттан бар»,— диде дә, кечкенә генә чишмә төбендә ялтырап яткан сары алтын тәңкәне күрсәтте. «Мин сиңа нинди генә рәхмәтләр укыйм инде, син мине икенче мәртәбә коткарасың»,— диде Йолдыз бала. Куян: «Юк, бернәрсә дә кирәкми. Син үзең башлап мине кызгандың»,— диде дә урман эченә чабып китте.

Йолдыз бала капкага җитәр алдыннан гына, кичәге каладан сөрелгән авыру тагын чабып килде дә: «Ходай өчен миңа акча бир, юкса мин ачтан үләрмен»,— дип ялварып, инәлеп сорана башлады. Йолдыз бала аңа каршы: «Минем букчамда бер генә тәңкә акчам бар, әгәр аны хуҗама китермәсәм, ул мине бик нык азаплар»,— дисә дә, теге авыру һаман инәлеп соравында булды. Шуннан соң Йолдыз бала кызганып, сары алтын тәңкәсен биреп калдырды.

Сихерче карт Йолдыз балага бакча ишеген ачты да: «Сары алтыннан ясалган тәңкәне таптыңмы?» — диде һәм «Юк, мин аны таба алмадым»,— дигән җавапны ишетү белән Йолдыз баланы кыйнарга, азапларга тотынды, үзәгенә үткәнче изеп ташлаганнан соң, аны богаулап, яңадан җир астына ябып куйды. Сихерче карт иртән тагын килеп керде: «Әгәр бүген син кызыл алтыннан суккан тәңкәне китерсәң, мин сине азат кылырмын, әгәр тапмасаң, миннән шәфкать булмас, җаныңны алырмын»,— диде.

Йолдыз бала урманга китте. Анда көн буе тырышып, кызыл алтын тәңкәне эзләде һәм беркайдан да аны таба алмады. Кич җитә башлагач, җиргә утырды да кычкырып еларга тотынды. Шул арада әлеге куян йөгереп килде дә: «Нигә елыйсың, син эзли торган кызыл алтын тәңкә синең артыңдагы тау тишегендә генә бит. Елама инде, бәхетле бул!» — диде. Йолдыз бала куянга карап: «Ни белән мин сине бүләклим.



Нинди генә изгелек кылыйм инде. Син бит өченче тапкыр мине коткарасың»,— дигән иде, куян: «Син бит башлап мине кызгандың»,— диде дә күздән югалды.

Йолдыз бала тау тишегенә барып, кызыл алтын тәңкәне табып, аны үзенең букчасына куеп, бик ашыгып, шатлана-шатлана калага кайтып китте. Әлеге авыру тагын ерактан ук моны күреп алды да: «Бирче миңа кызыл алтын тәңкәңне, юкса мин үләрмен, үләрмен»,— диде. Йолдыз бала аны кызганды да: «Ул сиңа миннән дә артыграк кирәктер»,— дип, алтын тәңкәне биргәч, Йолдыз бала үзенең алдагы язмышын уйлап, бик кайгыра, азаплана башлады. Ах, авыр, чөнки коточкыч картның ни кылачагы аның күзенә күренә иде.

Йолдыз бала шәһәр капкасына якынлаша башлагач, каршысына баш иеп килгән сакчыларны күрде. Алар:

— Безнең патшабыз нинди матур,— диделәр.

Алар артыннан килгән иге-чиге булмаган кала халкы:

— Бөтен дөньяның иң матуры, иң гүзәле ул! — дип кычкырдылар. Йолдыз бала моны күреп, елап җибәрде һәм үз-үзенә: «Аларның һәммәсе минем ямьсезлегемнән, минем бәхетсезлегемнән көләләр»,— диде. Моңа каршы чыккан халык шул дәрәҗәдә күп иде ки, ул бөтенләй юлыннан язды. Ул үзенең бер зур сарай алдындагы мәйданга барып чыкканын сизми дә калды. Патша сарайларының капкалары ачылып китте. Ул капкадан вәзирләр, руханилар чыгып, Йолдыз баланың алдына, каршысына килеп, бик түбәнчелек белән:

— Син безнең патшабыз, син безнең патшаның баласы, күптәннән бирле без сине көтәбез! — диделәр.

Аларга каршы Йолдыз бала:

— Нигә сез мине патша баласы дисез, мин фәкыйрь

хатынның баласы, нигә сез мине матур дисез, мин бит үземнең коточарлык икәнемне бик яхшы беләм,— диде.

Шуннан соң алтынлы тимер кием кигән гаскәри үзенең калканын күтәреп Йолдыз балага таба китерде дә:

— Минем падишам үзенең матурлыгына ничек шикләнеп карый икән? — диде.

Йолдыз бала ни күзе белән күрсен, үзенең борынгы кебек матур, гүзәл йөзле булуын күрде. Аның әүвәлге чибәрлекләре бөтенләй кире кайткан. Аның өстендә, күзләрендә әлегә кадәр бервакытта да күренмәгән бер хикмәт сизелә.

Руханилар һәм вәзирләр башларын иеп һәм тез өсләренә чүгеп:

— Бүген шундый көн, бүген безгә киләчәк кешенең безнең патшабыз булачагы күптән хәбәр ителгән иде. Бүген киләчәк кеше безгә баш булырга, патшаның таягын алырга, таҗын кияргә тиеш. Без аның туры, гади хаким булуын гына телибез,— диделәр.

Ул, аларның үтенеченә каршы:

— Мин бу урынга ярый торган кеше түгел, мин туган анамнан биздем. Аны табып, аның күңелен тапмыйча минем тынычланачагым юк. Зинһар, мине җибәрә күрсәгез лә! Мин аны эзләп табарга тиеш. Һич бу җирдә кала алмыйм. Зинһар, җибәрегез, патшаның таягын һәм таҗын бирсәгез дә, миңа кирәкмидер,— дип, кала капкасына бара торган урамга борылган иде, ни күзе белән күрсен, алдында фәкыйрь бичара анасы һәм аның янында һәркөн капка төбендә алтын тәңкәләрен алып кала торган карт күренде. Ул, шатлыгыннан шашып, кычкырып, анасының ертылып беткән аякларына барып егылды һәм канлы күз яшьләрен агызып:

— Анам, мин үземнең зурланган вакытымда синнән бизгән идем. Инде син шушы түбән, хур вакы-

тымда мине какма, читкә үткәрмә. Анакай, син минһән комсызлык күрдең. Зинһар, зинһар, анам, күз яшем, бирче миңа мәхәббәтеңне, алчы мине үзеңә, ташлама инде үз балаңны! Анам!..— дип ялварырга тотынды.

Мәгәр анасы бер сүз җавап бирмәде. Шуннан соң Йолдыз бала һәркөн очратып, алтын тәңкәләрен бирә торган картның ап-ак аякларын кочаклап:

— Син бит минем ярдәмемнән өч мәртәбә файдаландың. Үтенче, зинһар, анамнан, ул миңа бер генә сүз әйтсен? — диде. Шуннан тагын анасына әйләнеп:

— Анам, бәгърем, бу азапны җиңәргә минем көчем җитмидер. Үтенәм синнән, мине гафу ит, югыйсә мин яңадан урманга китәрмен...— дип һаман инәлүендә, ялваруында булды.

Анасы кулын аның башына куйды да:

— Тор,— диде.

Аның артыннан үзе һәркөн ярдәм иткән «авыру» да баланың башын тотып:

— Тор инде! — дип кычкырды.

Йолдыз бала күтәрелеп, алар өстенә караса, ни генә күрсен, аның алдында патша белән патша хатыны басып торалар. Патша хатыны, патшаны күрсәтеп:

— Менә синең атаң, син шуңа ярдәм иткән идең,— диде.

Патша хатынын күрсәтеп:

— Бу синең анаң, хәзер син аның аякларын күз яшең белән юдың,— диде дә һәр икесе Йолдыз баланы кочаклап сөйделәр һәм сарайга алып киттеләр дә патша киеменә киендерделәр.

Йолдыз бала таҗ киде. Патша таягын алды. Елга буена салынган каланың патшасы булды. Ул бик туры хөкем кылды һәм яхшы идарә итте. Сихерче картны үз иленнән кудырды. Утын яручыны һәм аның хатынын бик зур итеп бүләкләде. Аларның балаларын дәрәҗәле урыннарга куйды. Ул һәркем, һәрнәрсә

белән яхшы мөгамәлә кыла иде. Кошларга, җанварларга тидертмәде. Үзенең кул астындагы бөтен кешеләргә мәхәббәт салырга тырышты һәм ачларга азык, ялангачларга кием бирде. Шулай итеп, бик тизлек эчендә моның җирендә тынычлык хөкем сөрә башлады. Ләкин бу тынычлык озакка бармады. Йолдыз баланы элек күргән газаплар, авырлыклары килеп бастылар. Өч елдан соң ул үлде. Аның урынына утырган патша илне бераз начар идарә кылды. Ләкин Йолдыз бала исеме бик озак еллар һәм гасырлар халык алдында онытылмады.

*1914*





## Канатлы тай

Авыл. Җәй. Майның соңгы көннәре авышып бара. Кыр эше булмаганга, халыкның һәммәсе авылда тора. Яшь ир балалар көндезләрендә болын, инеш буйларында уйнап, күбәләкләр куып, коенып йөриләр. Кичләрен «ат-ат» уйнап, авылны яңгыратып, бөтен тынлыкны алып торалар. Кыз балалар да көндезләрен «күлмәк, яулыкларыбызны малайлар алып китмәсеннәр» дип, курка-курка гына коеналар. Болыннарда каз каурысы, йоннар, күбәләкләр куып йөриләр дә кичрәк «бишташ» һәм «кунак-кунак» уйнап, караңгы төшә башлагач, «кырый чыгыш», «түндек алыш», «киртәң бир» һәм «куыш» уйнарга тотыналар. Мин дә авыл баласы. Малайлар арасында иң күп уйнаучы, иртәдән кичкә чаклы болыннан, инеш буеннан кермим. Өйгә кайтмыйча, болыннарда, кырларда йөрим. Эссе көннәрдә, үрдәк кебек, судан чыкмыйча коенам. Хәзер генә мине бернәрсә бәйли: тимеркүк биябез буаз. Инде колынлау атнасының соңгы көннәре. Мин уйнарга да, коенырга да бармыйм, барсам да, тиз үк әйләнеп кайтам, чөнки мин тай көтәм дә тай көтәм. Көн көтәм, төн көтәм,

ашамыйм, эчмим, һаман тай көтәм дә тай көтәм. Коенырга баручы, коенып кайтучы дуслар, иптәшләр дә минем янга кереп, тай хакында сөйлиләр. Үзләренең аның хакындагы уйларын әйтәләр.

— Нинди тай булыр икән, айгырмы, бияме, карамы, коламы, сорымы, турымы?

Айгыр тай булыр, әгәр бия тай булса, инде әллә кайчан колыннарга вакыт, бия тай булса, болай озак йөрми. Әнә корсак асты тамырлары да бик өрелгән, айгыр тай.

— Бия тай,— ди берәү.

— Юк, бия тай булыр. Бу ел елы шундый. Барлык кешенең биясе бия тай колынлаган,— ди икенчесе.

— Ә соң теге Атукларның[1] кола бияләре айгыр тай колынлады ич.

— Теге оч Атукларныкымы?

— Соң.

— Шул, кояш әгәр, бия тай. Аларның бияләре айгыр тай колынлаганы да юк.

— Мин әйтәм, әйдә бәхәсләшик.

— Әйдә, әллә куркаммы. Әле кичә генә бергә кырдан кайттык. Мин әйтү белән теге, кем үзе, фу, теге Кыстук (Хөснетдин) тегермәннән кайта иде. Айгыр тай. Эти дә: «Шәп айгыр булыр, түшләре киң, аяклары дүртесе дә дүрт җиргә басып тора, сырты да киң, айгырына охшаган»,— диде.

Малайлар бер-берсе, икенчесе белән айгыр булыр, бия булыр, дип кычкырышып, аз гына якалашу дәрәҗәсенә ирешмичә калдылар. Әле кычкырышып, карамы, коламы, турымы дигән сүзләргә барып җитмәде.

Ул арада өйдән эти чыгып: «Балалар, анда нишләп

---

[1] *Атук* — Габдулла (*Ш.Әхмәдиев*).

йөрисез, ат тешләмәсен үзегезне, таралыгыз»,— дияргә өлгермәде, икенче яктан әни чыгып: «Атасы, Шакирны бия типмәсә ярар иде, бигрәк шул җирдә бутала. Ул инде тай дип саташып беткән, уеннан, ашавыннан калган, биябез болай да усал, ул-бу булмасын дим»,— диде. Әтинең башында чалма, өстендә яшел сыман чапан, башы кечкенә чалмалы артыш таяк[1] кулында. Ул өйлә намазына чыгып бара иде. Әни тавышыннан соң туктады да, безгә таба иркәле, яраткан тавыш белән озайтып: «Шакир, балакай»,— дип кычкырды. Мин тиз үк борылып: «Монда, әти, монда»,— дип тавыш бирдем. Әти дә арт абзарга, минем янга килде. Ул килгәч, салам өстендә ята торган тимеркүк бия, матур колакларын азрак торгызып, торырга теләгән төсле кузгалып алды, әтинең якын бармаганын белгәч, тагын үз хәленә кайтып, кояшка кызынган халәткә керде. Азрак пошынган, көчәнгән сыман булды. Аның зур, куе кара ялы һәм койрыгы җирдә түшәлеп ята иде. Әти биянең өстеннән карап, «сөбханалла» дип, нәрсәдер укынды да: «Көтүдән алып калуыбыз яраган әле, хәзер бөтенләй авырайган икән, син, Шакир, бүген якын барма. Карап торырга ярамый. Бәлки, Алла боерса, иртәгәләргә колынлар»,— дигән сүзе тагын да мине тайга ныграк бәйләде. Мин иртәнге көнне күрмәм төсле тоела башлады. Нинди озын көн. Әле кояш аз гына төштән авышып бара. Кайчан кич була? Кайчан төн узып, иртә җитә? Барысы озак. Бер ел, бер гомер төсле. Үзем һаман тайның нинди булуы турында гына уйлыйм: айгырмы, бияме, карамы, аламы, сорымы, турымы?

Минемчә, нинди тай кирәк: айгыр тай. Үзе чем-кара булсын, ялы, койрыгы бөдрәләнеп торсын, тибә,

[1] *Артыш таяк* — җимеше медицинада кулланыла торган, һәрвакыт яшел ылыслы куактан ясалган таяк.

тешли торган булмасын. Ул арада бер зур гына малай, биянең өстенә карады да иске генә, каралып, каешланып, читләре кырылып беткән кәләпүшен төзәтеп: «Әй малай, таең канатлы булса, менә шәп булыр иде»,— диде. Мин кинәттән аның ябык йөзенә, зур, матур күзләренә карадым да: «Тай канатлы буламы? Ул кош түгел бит»,— дидем. «Була шул, канатлы ат та була»,— диде. Шуннан соң бик ныклап, берәмләп сораштырырга тотындым. Ул киң генә койма баганасына каралып беткән ялангач аякларын салындырып утырды да иренеп кенә сүзгә кереште: «Әнә теге, фу, үзе кем әле, кыр капкасы каравылчысы, бабай Шәйдүк карт. Ул зерә бай булган. Әнә теге бай Садыйкның йортлары аныкы булган бит. Авылда элек аннан да бай кеше булмаган. Ул хәзер садакага килгән көлтәләргә генә кыр капкасын саклый. Шул Шәйдүкнең, бик бай чагында канатлы аты булган. Бер җирдә дә аңа узышырга бер ат та чыкмаган. Ул атын йөретмәгән җирне калдырмаган. Кая гына барса да, бер ат та аның йөгерегенә каршы килә алмаган. Бөтен авыл, бөтен шәһәрләрнең сабантуйларында беренче булып килгән. Казан сабан туенда да аңа бер ат чыдамаган. Бервакыт Казанда бик зур сабан туе булган, ди. Анда дөньяда иң яхшы атлар чабышырга килгәннәр, ди. Зур байларның аргамаклары[1], йөгерекләре алдында авыл аты бер тай кебек кенә калган, ди. Сабан туена килгән халык бу кеч-кенә атны күреп: «Бу адәм көлкесе нигә килгән икән?» — дип әйтәләр, ди. Бервакыт атларны егерме биш чакрымнан узыштырырга җибәргәннәр. Карасалар, малай, куян хәтле генә бернәрсә килә, ди. Уклау кебек тәгәри генә, ди. Менә барысы да: «Кем аты да кем аты?» — дип, ду киләләр, ди. Бервакыт оч-

[1] *Аргамак* — чабышкы ат.

кын кебек килеп җитсә, ул Шәйдүк аты, ди. Үзе аз гына «ых» та дими, тик башларын бутап, чабарга гына ыргылып тора, ди. Әле башка атлар күзгә дә күренмиләр, ди. Менә шау-шу кузгалган. Синең атың сызыкка барып җитмәгән, моннан борылып кайткан, дип, Шәйдүкнең өстенә киләләр, ди. Шәйдүк бер дә курыкмаган. Менә атларыгыз килсен дә, яңадан җибәреп карарбыз, дигән. Менә йөгерекләр килеп җиткәннәр, барысы да ак күбеккә төшкәннәр, тыннарын да ала алмыйлар, корсак асларыннан яңгыр кебек су ага, ди. Байлар чабучы малайларыннан Шәйдүкнең аты сезнең сызыкка җиттеме? дип сорыйлар икән, малайлары: «Җитте, бергә кузгалдык, сызыкка җитеп, һап итеп алуга, ул күздән югалды. Ул артта калгандыр, ахры»,— дигәннәр иде. Бу малайларга да ышанмадылар. Тагы шау-шу, тавыш кузгалган. Шуннан соң Шәйдүк: «Ышанмасагыз, арагыздан кайсыгыз бәхәсләшә?» — дигән. Бер зур корсаклы Казан бае килеп чыккан да: «Менә минем атым белән узышып карасын, мин бер меңнән бәхәсләшәм»,— дигән. Шәйдүк бер сүз әйтмәгән. «Ярый, акчаңны сал»,— дигән. Берәр меңне салышып, атларын утыз чакрымнан җибәргәннәр. Әй малай, Шәйдүктән көләләр, ди. Бер сала татарының бер меңе китте. Теге аргамак аны ике мәртәбә әйләнер, дип әйтәләр, ди. Менә малай, бервакыт йомгак кебек бер ат килә, ди. Оча, ди, малай, оча, ди. Әйтерсең лә кош, ди. Үзе чапкан төсле түгел, тик шуып, тәгәрәп килгән төсле, ди. Кем аты? Шәйдүк аты, Шәйдүк аты! дип тавыш күтәрелә, ди. Ул арада Шәйдүк йөгерерге халык алдыннан карлыгач кебек йомылып, үтеп китә, ди. Әле зур корсаклы байның аты һаман күренми, ди. Бай бер кызара, бер яна, ни әйтергә, ни эшләргә дә белми, ди.

Шәйдүк аты «ых»та дими, тик очарга гына тора, ди. Теге аргамак, шабыр суга төшеп, ак күбеккә манчылып, көчкә генә килеп җиткән, ди. Барлык ха-

лыкның исе китеп, Шәйдүкнең атын карарга җыелганнар. Әнә малай, аны бүләклиләр, ди. Берсе чапан, икенчесе читек-кәвеш, өченчесе бишмәт яудыралар гына, ди. Теге зур корсаклы Казан баеннан көләләр генә, ди. Шуннан соң ул хурлыгыннан Шәйдүкне чакырган да: «Менә сиңа, Шәйдүк, бәхәсләшкән өчен бер мең сум бирәм, әгәр атыңны алышсаң, үз атымны бирәм, өстәвенә өч мең тәңкә кушам»,— дип әйтә, ди. Шәйдүк көлеп кенә җибәргән, ди. «Синең аргамагың минем атның бер тоягына да тормый, аның бер ялы да өч мең тәңкә тора. Акча кирәк булса, үзем бирермен сиңа»,— дигән. Шуннан бай бигрәк хурланган, ни эшләргә, ни кылырга да белмәгән. Шуннан Казан байлары берсе-берсе белән үлчәшеп, акча арттырыша башлаганнар. Берсе биргән биш мең, икенчесе алты мең, өченчесе җиде мең... Шәйдүк берсенә дә бирмәгән, ди. Байлар тагын да хурлана төшкәннәр. Алай да булмагач, барысы сүз берләштереп, Шәйдүкнең йөгереген агу каптырып үтерергә булганнар. Бер кешене яллаганнар. Ул кеше кичен солы салырга керәм дип, атка мышьяк каптырган, ди. Шул агу бирүче кеше шулай сөйли, ди. Бервакыт акрын гына сарайга керәм, дип әйтәдер, ди. Шәйдүкнең аты сарайда һич күренми. Аннан карыйм, моннан карыйм, юк. Улак янына ук килеп күтәрелебрәк карасам, ни күзем белән күрим, Шәйдүкнең йөгереге куян кебек посып, аякларын алга сузып, улакның эченә менеп яткан. Мин үз куркуымнан кулымдагы нәрсәм җиргә төште дә китте. Шул тавышка ат уянып китте дә күз ачып йомганчы җиргә сикереп тә төште, дип әйтәдер, ди. Ул кеше бик күп күргән, атлар карагы булган, ди. Мондый ат күргәнем юк иде. Кызганып кулымдагы агуымны үзем эчә яздым. Ул ат канатлы иде. Шуңа күрә улакка менеп яткан. Канатлы ат юеш, түбән җирдә ятмый, дип әйтәдер, ди. Иртәгесен аны карасалар, аның бер сөям

генә озынлыгында канатлары бар, ди. Шәйдүк атның үләксәсен күреп, һушыннан яза язган, ди, бик кычкырып елаган, ди. «Атам-анам үлгәндә дә болай кайгырмаган идем»,— дип әйтәдер, ди. Шул канатлы ат үлгәч, аның бәхете артка киткән. Бара-бара бөтен дәүләтеннән язган. Хатыны, балалары да үлеп беткәннәр. Ул аның ындыры иске кибән белән тулы булган. Йорты тулы терлек булган. Үзе бик бай булып торган. Хәзер торырга йорты да юк. Кыш көнендә хәер сораша, җәен басу капкасын саклап тамагын туйдыра. Мин бичара картны кызганып елый яздым. Биям дә, таем да онытылды. Картның бөтен хәле күз алдыма килеп, тын да алмыйча кара күзле дус малайның сүзен тыңладым. Аның сүзен бетергәнне көтә алмыйча: «Ул атны кайдан алган икән?» — дидем. Ул аны үзе үстергән, әллә каян, башкорт ягыннан алып кайткан биям бар иде, колынлаганда тайны тотып аякландырдым, шуның өчен ул канатлы булды. Әгәр тайны тотып аякландырсаң, канатлы була, тотмасаң, йөрергә теләгән булып, көчсез вакытта бер егылып, бер торып канатын сындыра, дип әйтәдер, ди.

Кара күзле малай сүзен бетерде дә кулына кәләпүшен суга-суга: «Кич була, малай, кунарга барырга да вакыт җитә»,— дип китеп тә барды. Минем кебек авызларын ачып, теге малайдан күзләрен дә алмыйча тыңлаган малайлар да таралып киттеләр. Ул арада тимеркүк бия дә аягүрә басып, ашарга теләгән кебек, әллә нәрсә чүпләнеп, йолкынып тора иде. Кара күзле малайның Шәйдүк бабай хакында сөйләгән экияте минем бигрәк тә тайга булган мәхәббәтемне көчәйтте. Инде мин канатлы тай турысында гына уйлыйм, күңелемдә тик шул гына инде. Чын кара айгыр тай булсын. Ялы, койрыгы бөдрәләнеп торсын дигән теләк урынына нинди булса да ярар иде, тик канатлы йөгерек тай булсын иде, дим. Көн буе

уйлыйм да уйлыйм, бар нәрсәм онытыла, булачак таемны ничек тә канатлы итәсем килә. Китә хыял, китә уй, гүя таем канатлы булып, бөтен җирдә атаклы бер йөгерек. Мин аның өстен юып, ял, койрыкларын бизәп, яхшы, кыйммәтле йөгәннәр кидереп, Казан сабан туена барам. Анда Шәйдүк атына караган кебек, минем саладан килгән атка да көлеп кенә карыйлар.

Мин эчемнән генә: «Күрерсез әле, мин сезгә күрсәтермен»,— дим. Барлык атлар белән мине ат өстеннән күтәреп, сөеп төшерәләр. Менә байлар бәхәсләшеп безнең атны алырга телиләр. Берсе бирә өч мең, икенчесе биш мең, өченчесе җиде мең, ун мең... Минем әти бик эреләнеп кенә: «Аның бүген алда килүе дә йөз мең сум тора»,— ди, атны сатмый. Мин, байлар хурланып, үчекләнеп, төндә генә атны мышьяк каптырып үтермәсеннәр, дип, шул көнне әтидән авылга китәргә сорыйм. Аңа Шәйдүкнең хикәясен сөйләп бирәм, имеш. Шул уй, шул шатлык дулкыны эчендә мин тагын абзардагы тимеркүк бияне бер карап китәм. Караган саен ул да миңа шул өметләрне әйтеп, сөйләп торган төсле була. Кич тә җитеп бара. Ничек итеп тайны тотып аякландырырга кирәк. Үзем булдыра алмыйм. Биянең янына барырга да котым оча. Бәлки, әти канатлы тай турында ишеткәне дә юктыр, алай дисәң, Шәйдүк карт сакалы агарганчы әти белән бер авылда гомер иткән. Шул арада кылт итеп күңелемә хезмәтче килеп төшә. Мин әйтәм, шуңа биш тиенне бирәм дә бу эштән котылам. Һәм шулай була да, ул разый була. «Бир биш тиенеңне, төн буе саклап чыгам. Тайны тотып аякландырам»,— ди. Мин бик шатланып биш тиенне бирәм. Шуннан соң күңелем бераз тынычланган төсле була. Инде тайның канатлы булуында бер шик тә юк кебек. Ничек соң башка кешеләр бу хәйләне белмиләр, нигә тотып аякландырмыйлар икән, дип уйлый-уйлый йокыга

китәм. Ләкин йокым йокы түгел, төшем төш түгел, аз гына йокыга китәм дә тагын сискәнеп, куркынып китәм, уянам. Һаман да кара төн була. Ул арада минем алдымда чем-кара тай. Аның матурлыгыннан күз чагыла. Ялы, койрыгы бөдрәләнеп тора. Әнисенең тирәсендә, бүре баласы кебек, уйнап, сикереп йөри. Мин бер кисәк икмәк сузам да ул, матур, кечкенә колакларын йомып, бер качыр кебек торгызып, миңа таба чабып килә, икмәкне каба. Мин борылып типмәсен дип, күлмәк чабуларымнан тотып, чабып китәргә җыенып торам, имеш. Менә тай юк. Киң, яшел болын. Бер якта кыр, икенче якта зур инеш. Минем тимеркүк бия шул болында, бар көченә кешнәп, чабып йөри. Тае юк, берьялгызы. Мин анда чабам, монда чабам, тай юк та юк. Шул арада кулына йөгәнен тоткан хезмәтче Сабир килеп чыга. Сабир абзый, тай кая? дим. Ул эндәшми дә. Кулын болгап, «ма, ма, ма, ма» дип, бия артыннан чаба. Мин аның артыннан. Менә бия бер җирдә төртелә дә шуннан китми, үзе пошкыра, үзе кешни, үзе исни, тагын пошкыра, тагын исни. Мин дә барып җитәм. Ни күзем күрсен, тай бугазланган. Тыпырчынмыйча да ята. Мин кычкырып җибәрәм, котым оча, шул куркуга уянып китәм.

Таң аткан, иртә намаз вакыты. Әти тәһарәт алып йөри. Аннары чалмасын, чапанын кия дә, артыш таягын алып, мәчеткә китә, капкадан чыккач, яңадан кайтып: «Анасы, син кара әле, бия колынлаган, балаларны аның янына якын җибәрмә. Әллә кая тешләр, йә тибәр»,— ди дә яңадан китә. Бия колынлаган диюгә, минем күзләрем гомердә йокы күрмәгән төсле, ачылып китәләр. Мин исни-исни йортка чабып чыгам. Әни күрмичә дә кала. Арт абзарга бия янына барганда, хезмәтче каршы очрый. Сакладыңмы, тотып аякландырдыңмы? дим. «Төне буе шуны саклап, керфекләремне дә йомганым юк, тотып



аяклandырдым, җиргә егылмады, айгыр тай»,— ди. Шуннан ук кебек атылып, койма башына барып асылынам. Ни күзем күрсен: чем-кара тай. Күкрәкләре дә киң генә, кечкенә генә, нәни генә бөдрәләнеп торган койрык, яллары. Ул инде нәкъ мин уйлаган тай. Юк, мин уйлаганнан да матур. Ул энисенең корсагына сөялеп, курка-курка гына басып тора. Үзе кечкенә балалар кебек дер-дер калтырый. Анасы аны һаман ялый, һаман сөя, башын баласы өстеннән алмыйдыр. Аз гына тае читкә китә башласа, өңрәнеп аның янына бара. Мин дә барып аның муеныннан тотып аласым килә. Менә ул миңа алды белән әйләнә, ни күзем күрсен: маңгаенда кечкенә генә агы — кашкасы бар. Ул матур, ул сөйкемле, шатлыгымнан иснәүләрем, калтырануларым барысы бетә. Ул арада энә хөрмә төшеннән ясаган зур тисбесен[1] тарта-тарта, яланаягына җиңел башмак кына киеп, әни миңа таба килә. «Шакир, кай арада син монда килеп өлгергең, мин сине йоклап ятасың дип тора идем. Бар кайт, балакай, йокла, этиең күрсә ачуланыр»,— ди. «Мин якын бармыйм бит. Койма башыннан гына карап торам»,— дим. Әни минем янга килеп, бераз тайны карап тора да, нәрсәдер укып: «Сөбханалла, бик матур икән, тфу, тфу, тфу, Алла теләсә, этиең сиңа атар»,— диде дә мине койма башыннан күтәреп төшерде.

Мин яңадан барып ятам. Йокым күзгә дә керми. Шатлыктан йөрәк күкрәккә сыймый, кара тай, бөдрә айгыр, ял, бөдрә койрык. Аның өстенә кашкасы бар. Иң шәбе канатлы тай... дим. Мин һәр көн битне дә юмыйча иң элек тайны карарга барам. Әгәр өйдә булса, озак вакыт аның янында әвәрә булам, аны үчек-

---

[1] *Тисбе* — хөрмә төшеннән яки миләш агачыннан туксан тугыз төймәле муенса кебек итеп эшләнә, төймәләрен, Алланы мактый торган сүзләр әйтеп, берәм-берәм тарталар.

лим, кулга чакырам. Әгәр дә кырда кунган булса, түземсезлек белән көтеп, аны каршы алам, кайтуы белән, «кнәш, кнәш, ма, ма, ма» дип, бер кисәк икмәк тотып, аңа каршы барам. Әгәр эссе көн булса, ул миңа илтифат та итмичә, башларын бутап, чебен, черкине куып ята да чабып ышык җиргә кереп китә, үзе балалар төсле матур итеп төчкерә, пошкыра. Ә көн сүрән, яңгырлы булса, сабыр гына булып, анасы янында тора. Янына бозаулар, сарыклар, кәҗәләр килә башласа, колакларын йомып тибәргә хәзерләнә. Мин инде ул вакыт: «Карагыз, карагыз әле, тай тибә»,— дип көләм, шатланам. Үзем ничек тә аны кулга ияләштерергә уйлыйм. Тик анасы гына бик усал: якын бара башласаң, хәзер колагын йомып, томырылып киләдер. Күп азаплангач, күп артыннан йөргәч, миңа ияләшә, чакыргач, кулга килә башлыйдыр, ләкин тоттырмый, якын ук килә дә, борылып яңадан чабып китә. Мин аңа хезмәтчедән кечкенә генә матур йөгән ясатам, кечкенә арба да хәзерләргә тырышам. Өебездәге барлык кеше аны ярата. Аның турысында гына сөйлиләр. Кайсы вакыт без түгәрәкләнеп утырып чәй эчкәндә, йә аш ашаганда, ул анасы белән берәр җирдән чабып кайтып керәләр, башка сүзләр онытылып, тик шулар хакында гына сүз башлана, бервакыт әни: «Яшь бала, яшь тай булган өйдә гайбәт булмый икән»,— дип куйды. Әти дә: «Шулай шул»,— диде. Инде күптән бирле тайны «Шакир тае» дип атаганнар иде. Кайвакыт этинең миңа ачуы килсә: «Бу тай бияне бик суыра, аны сатарга кирәк, әле ул кайчан үсеп мал була, хәзер анасын эштән чыгара»,— дия иде. Әгәр мине иркәләп сөйсә: «Хода кушса, Шакирның таен үстерәм дә матур йөгәннәр, яхшы арбалар, матур сбруйлар алып бирермен. Җигеп кунакка, урманнарга, кырларга карарга йөртермен. Шакирны чит калага укырга илткәндә, кунакка алып кайтканда, бу айгырны

җигәрмен»,— дия иде. Минем күңелемдә: канатлы тай, йөгерек сабан туе, Казан сабан туе, дигән матур уйлар гына очып йөри. Төндә дә шул, көндә дә шул!..

Җәйнең уртасы җитеп бара. Халык бик кызуланып каты сукага хәзерләнә. Берөзлексез йорт, сарай тирәсендә сабан тырма кайгысы белән йөри. Кирәк тимер-томырларны карый, төрле җепләр ишә, кәләпүшен салган, кулларын, җиңнәрен сызганган, изүләрен чишкән, халык эшкә хәзерләнә, сабан җитә. Яңгыраган сабан тавышлары авылның тынлыгын боза, бөтен кыр чуп-чуар була. Иртән үк тургайлар, сандугачлар мең төрле көй, тавыш белән сабанчыларны котлап каршы алалар. Аларның эшләрен мактыйлар... Кырга баручы, кырдан кайтучы егетләр, моң күңелләр тургайларга ияргән төсле җырлашып кайталар.

Безнең хезмәтче Сабир да, үзенең кирәк нәрсәләрен электән үк карап, изге сәгатьтә, җомгадан соң каты сукага китә. Ул китү белән, әни сабан садакалары бирә башлый.

Без эти белән тайлы бияне җигәбез дә иген кырларын карарга чыгабыз, кырлар бик күңелле: арыш куе, арыш төбе саламга бай. Инде арыш та коскан. Кечкенә ат сырты күренмәслек озын да. Кайсы җирләре дулкынланып куян куып торалар. Нинди матур, нинди күңелле! Әти кырга чыгу белән шатлыгыннан шөкранасына Ясинын укып, бик озынлап дога кылды. Вакытында яңгырлар булса ярар иде, дип кыйблага, төш ягына күтәрелеп карый. Көн кояшлы, һава эссе генә. Шуннан әллә яңгыр булыр, дип уйлый, төш ягыннан тамырланып, каралып тора, ди эти. Ул арада минем тай уйнап туя алмый. Кайсы чакта артта ук кала да шуннан соң бар көченә күтәрелеп ала да күз ачып йомганчы килеп тә җитә. Арба яныннан арышларны таптап анасы алдына килеп чыга. Бигрәк көчле чаба да соң инде! Ул тагын артта

кала. Тагын шулай уйнап килә. Мин әйтәм: моның канатлы булуында шик юк, дим. Мин иген дә карамыйм, эти сүзләрен дә тыңламыйм, тик тайның ни эшләгәнен генә карап, тикшереп торам. Артта калса, «кнәш, кнәш, кнәш» дип кычкырырга тотынам, үзем каршы килгән кешеләргә ияреп китмәсен дип куркам да. Арба яныннан үтә башласа, бер булса да аркасыннан сыйпап, сөеп калырга телим. Арыш кырын үтеп, каты ашлык кырына җитәбез, солы, борайлар да күңелле. Аларның кара туткыллы кыяклары куе, калын көпшәләре бигрәк тә матур, күңелле булып күренә. Әти монда җиткәч тә, нәрсәләрдер укып дога кыла: «Бу ел ике кыр да Ходага шөкер, солы күп булса, синең тай да симез, көр булып кыш чыгар, шатлык белән рәхәтен күрергә генә насыйп булсын»,— ди.

* * *

Кырдан кайтуга эти хезмәтче янына китәдер. Мин тайчыгымны озатып каламын. Ул төчкерә-төчкерә һәм чебенләп анасы артыннан китә.

Мин инешкә барып, озак кына коенып кайтам да йокларга ятам. Кырдагы таемның юлдан чабып килүләре күңелемә төшәдер, бигрәк тә матур, бигрәк тә көчле чаба. Нинди шома, нинди ерак сикереп ала, дим. Шул матур уй эчендә йокыга да китәм.

Төшемме, өнемме? Тимеркүк бия кешни. Мин тыңлаган кебек булам, торырга да телим, тора да алмыйм. Һаман кешни, һаман яңгырый. Сискәнеп уянып китәм, дөресен дә йортта дөнья яңгыратып тимеркүк бия кешни. Мин таемның өйгә кайтуына шатланып, ук кебек атылып йортка чыгам, бия баганага бәйләнгән, ыргылып-ыргылып кешни дә кешни. Әти белән хезмәтче терлек чала торган җирдә әллә нишләп кайнашалар. Ни күзем күрсен, ни күзем күрсен: минем канатлы таемның аяклары бәйләнгән,

башы кыйблага борылган. Мин кычкырып: «Әти, тай нишләгән, ни эшлисез?» — дим дә өзгәләнеп-өзгәләнеп еларга тотынам. «Чабып килеп аягын сабанга кысты, балакай»,— ди әти. Үзе: «Хәерсез сәгатьтә кырга чыгылган икән»,— дип нәрсәдер сөйләнә. Мин күз яшьләре эчендә үксеп, таемның өстенә карап торам. Ул тыпырчына, ул авыр сулый, күзләреннән яшь аккан төсле. Ул, «Әнием, бәгъרем, мине алсана, мине коткарсана» дигән төсле өзелеп карап тора. Ул елый, мин дә елыйм. Ул сыкрана, мин аңардан да бигрәк сыкранам. Җитмәсә, анасы арканны өзәрдәй булып ыргыла, кешни, үзен-үзе кайда куярга белми. Мин аны кызганам, тагын йөрәкләрем өзелә...

Хуш, чем-кара, канатлы, кашка таем!

Бик озакка кадәр мин канатлы таемны оныта алмыйм. Кыр капкасы төбеннән үткән саен, канатлы таем минем күңелемә төшеп, Шәйдүк бабайны кызганам. Үземнең дә йөрәгем өзелеп китә.

*1915*





# Кечкенә Мук хакында хикәя

*(Вильгелм Гауфтан)*[1]

Минем сөекле туган илем булган Нәкиядә бер кеше тора иде. Аны кечкенә Мук дип атыйлар иде. Ул вакыт мин кечкенә булсам да, кечкенә Мук хәзер дә күз алдымда тора төсле. Бервакыт этием шул кечкенә Мук өчен үземне кыйнаганга, аны бер дә онытырлык түгел шул, кечкенә Мук ул вакыт инде карт иде, ләкин үзенең буе өч-дүрт терсәк озынлыгыннан артык түгел иде. Аның гәүдәсе бик кызык иде: сыны кечкенә, ләкин төзек, баш бик зур, болай акыллы кешеләрнең башыннан баш бик зур һәм авыррак. Ул

[1] *Вильгелм Гауф (1802—1827)* — немец язучысы. Бу экияте, 1904 елда русча тәрҗемә ителеп, Петербургта басылып чыккан.

бер зур өйдә тик ялгызы гына тора. Аш-суны үзе хәзерли иде, урамнарда аны аена бер генә мәртәбә күрергә мөмкин була иде. Әгәр көн уртасында морҗасыннан төтен күренмәсә, кечкенә Мукның исәнме, үлеме икәнен белүче булмый иде, кайсы вакытта ул үзенең өй түбәсенә чыгып та йөрештергәли иде. Бу вакыт урамнан караганда өй түбәсендә тик бер баш кына күренгән төсле була иде. Без инде балалар гаҗәп төрле халык: безнең өчен берәр кешедән көлү кебек артык берни дә юк. Әгәр кечкенә Мук урамда күренә калса, безнең өчен аңардан да зур бәйрәм булмый, без аның өе алдына электән үк җыелышабыз һәм өметсезлек белән аны көтәбез. Иң башлап ишек ачыла, аннан Мукның искиткеч зур башы гына күренә, баш артыннан кечкенә генә гәүдә кисәге, аның өстенә чабулары төптән киселгән җиләне һәм бик киң балаклы чалбар, билендә искиткеч озын һәм киң билбау, билбау артына шундый озын хәнҗәр бәйләнгән, хәнҗәр Мукка бәйләнгәнме, әллә Мук хәнҗәргә тагылганмы икәнен белеп тә булмый. Ул чыгуга бөтен дөнья тавыш белән тула, без бүрекләребезне һавага ыргытабыз һәм аның тирәсендә ыргыйбыз, сикерәбез. Кечкенә Мук үзенең өеннән чыккач та һәрвакыт безнең белән исәнләшә, безгә ачык йөз күрсәтә, аннан соң бераз аягын өстерәбрәк алга таба китә, аның аягында дөньяда башка тиңдәше булмаслык зур, өлкән, йомшак башмаклар. Ул бара, без дә аның артыннан калмыйбыз, үзебез бертуктамый: «Кечкенә Мук, кечкенә Мук»,— дип кычкырабыз. Безнең аның хакында чыгарган бәетебез дә бар иде:

Зур өйдә ишетеләдер стук, анда йөридер Мук,
Чыгадыр ул урамга, тик күренә аенда бер халыкка.
Башының зурлыгы бер чүлмәк, сыныдыр бер бармак.
Карасана... тук, тук, тук, куып җит безне, бәләкәй Мук.

Күп вакыт шулай итәбез, мин инде башкаларның һәммәсеннән дә шуграк, уенчырак, мин аның һәрвакыт җилән чабуыннан тартам. Бервакыт мин арт яктан аның башмакларына да бастым, ул егылып китте. Миңа боларның һәркайсы бик көлке булып тоела иде. Ләкин бу көлүем кинәттән бетәдер. Мук тора да акрын гына минем эти йортына таба юнәлә һәм йорттан минем эти белән чыгадыр, эти шактый иелеп, хөрмәт белән аның кулыннан тотадыр. Мин борчыла башлыйм, озак вакытлар мин куркынып йөрим. Ачлыкка чыдый алмыйм. Мин бик мескен, юаш сыман гына булып эти янына кайтам, кайтып керүгә этием: «Син, балам, бичара Муктан көлдеңмени, аны үчекләдеңмени? — ди.— Тыңла әле, менә мин сиңа Мукның әйткәнен сөйләп бирим, аннан соң син үзең дә аңардан көлми башларсың. Иң элек үзеңнең хезмәт хакыңны ал әле»,— ди. Шул сүзләрне әйтеп, этием кирәкле җәзасын бирде бугай, шуннан соң ул бәләкәй Мук хакында белгән үзенең бар нәрсәсен сөйләргә кереште:

— Кечкенә Мукның чын исеме Мукра иде. Аның атасы фәкыйрь генә булса да, һәркем тарафыннан яратыла, хөрмәт ителә торган кеше иде. Ул ялгызы гына гомер сөрә иде, аның хатыны яшьли үлеп китте. Буе кечкенә булганга, угылы Мукны бер дә яратмый, шуның өчен дә аны бернәрсәгә дә өйрәтми иде, кечкенә Мук, уналты яшькә җиткәндә, бер бала төсле генә иде. Аның атасы һәрвакыт диярлек угылын шелтәләп: «Инде сиңа бу кечкенә балалар башмагын ташларга күптән вакыт»,— дия иде. Ләкин уенчак һәм гакылсызрак Мукта һаман үзгәреш күренми иде. Бервакыт аның карт атасы егыла да бик нык имгәнеп үлеп тә китә. Кечкенә Мук чын ятим булып, бер тиен акчасыз, дөньяда берүзе генә калды. Аның шәфкатьсез якыннары кечкенә Мукны өйдән куып чыгаралар, чөнки аларга Мукның этисе бу-

рычлы булып үлә, шуннан соң ул өеннән куып чыгарган туганнарының киңәше белән җир йөзендә үзенең бәхетен эзләргә китә һәм юлга чыкканда алардан атасының киемен сорап ала. Тегеләр көлә-көлә киемнәрне бирәләр. Тик монда шуны әйтергә кирәк: Мукның атасы зур һәм тулы гәүдәле кеше иде, шуның өчен дә аның киемнәре Мукка ярарлык түгел иде. Ләкин Мук озак уйлап тормый, ул киемнең озын, артып торган җирләрен кисә дә ничек тә булса киядер, ул нигәдер ошап бетмәсә дә, киеменең киңлегенә бер дә күз салмый, тик аның озын җирләрен генә кыскарта. Менә син хәзер күргән нәрсәләр башында чалма, билендә киң билбау, ботта бик киң чалбар, өстендә койрыксыз кырылган бишмәт — боларның һәммәсе дә аның атасыннан калган мирас әйберләрдер, ул атасының Дамаска хәнҗәрен һәм кулына таягын ала да каладан чыгып китә. Ул үзенең бәхет эзләп барганын уйлый-уйлый көн буе күңелле генә юлдан бара, әгәр юлда бер пыяла кисәге күрсә, бервакыт бриллиантка әйләнер, дигән матур уй белән аны кесәсенә сала, әгәр берәр җирдә кояш яктысында ялтырап торган мәчет манарасы һәм көзге кебек җәелеп яткан күлне күрә дә хәзер ул үзен әллә нинди ят, тылсымлы дөнья уйлап бар көче белән шул җиргә таба чаба башлый. Һай, вәкарь[1] гына уй шул аны алдаган, ымсындырган матур галәмәтләре якында ук югалалар, аның ач карыны, талган аяклары үзенең мондый гына дөньяда торганын искә төшерәләр, шулай итеп, ул ачлыктан газап, җәфа чигеп, ике көн бара, инде бәхет таба алуыннан да өметен кисә башлый, ул җиргә ятып йоклый, ачлыктан төрле үлән тамырлары, урман җимешләре белән генә тукланадыр. Өченче көнне ул иртән еракта зур шәһәр күрә, аның стеналарында ярты ай галәмәте ялтырый, өй

[1] *Вәкарь* — горур.

түбәләрендә әләмнәр җилфердәп торалар, гүя алар кечкенә Мукны сәламләп каршы алган төсле. Шәһәрнең матурлыгын исе китеп, ул озак карап тора, аңа әллә кем «Әй, кечкенә Мук, анда сине бәхет көтәдер» дигән төсле була да ул шатлыгыннан сикереп торып, шунда таба китә, «анда бәхет булмаса, беркайда да юк» дигән була ул үз-үзенә. Ул барлык көчен җыя да шәһәргә китә. Шулай да аңа озак ук барырга туры килә, аның кечкенә аяклары бик читенлек белән генә алга атлыйлар, ул арып егылып китмәс өчен утырып хәл җыя-җыя гына бара, менә ул шәһәрнең капкасына ук керә. Итекләреннән тузаннарын кага һәм үзенең таягын ала да, зур гына атлап, шәһәр буйлап китә. Ул инде ничә урамнарны үтсә дә, бер җирдә дә ишек ачылганын һәм үзе уйлаганча «Кечкенә Мук, тизрәк кер, аша-эч һәм аякларыңа хәл алырга ирек бир!» дигән тавыш та ишетми. Ул бик күңелсезләнеп бай йортларга карап бара. Кинәттән ни күзе белән күрсен: бер тәрәзә ачыла да бер карт хатын башын тыгып кычкыра: «Монда, монда тизрәк-тизрәк килегез, ашыгыбрак, ашъяулык тулы әйбер, балың бер якта торсын, пешкән ботка сезне көтә, күршеләр, тизрәк җыелыгыз, ашыгыбрак!»

Өйнең ишеге ачыла, берничә эт, берничә мәче ишектән чабып керәләр. Мук нишләргә дә белмичә, чакырган җиргә барырга шикләнеп, бераз карап тора, ләкин ачлык аның куркаклыгын бетерә. Ул өйгә кереп китә. Аның алдыннан ике мәче баласы баралар. Мук алар артыннан юнәлә, чөнки алар Мукның фикеренчә ашханә юлын яхшырак беләләр. Баскычтан менүгә, Мук тәрәзәдән кычкырган карчыкка очрый. Карчык әллә нәрсә сөйләнеп карый да Мукның ни өчен кергәнен, аңа нәрсә кирәген сорый: «Соң син бит ботка ашарга бар кешене чакырдың, мин бик ачмын, шуңа күрә монда кердем»,— ди, кечкенә Мук әбигә. Карчык көлеп җибәрә: «Кайдан соң син килеп чыктың бер кы-

зык кеше? Соң, минем тик сөекле мәчеләрем өчен генә ботка пешергәнемне бөтен шәһәр белә бит, тик кайсы чакта гына бу көнге кебек алар янына туйга күршеләремне чакырам»,— ди. Кечкенә Мук карчыкка атасыннан соң булган үзенең начар хәле турында сөйләп бирә һәм аңардан бүген мәчеләр белән бергә туйдыруын үтенәдер. Мукның чын күңеленнән сөйләгән сүзләре карчыкка бик ошый да аңа кунак булырга рөхсәт итә һәм яхшы итеп ул Мукны карап тора да: «Кечкенә Мук, син монда хезмәткә кал, эш сиңа аз, яхшы булыр»,— диде. Мукның күңеленә мәче боткасы бик тәмле һәм яхшы кебек күренгәнгә, шунда ук карчыкта хезмәткә калырга ул риза була. Хезмәт җиңел булса да, бик кызык кына төсле: карчыкның дүрт ата мәчесе ике ана мәчесе бар иде. Мукның бар эше һәркөн иртә белән аларның йоннарын тарау һәм хуш исле май белән аларны сөртү, ашаган вакытта яхшы тәлинкәләрдә аларга азык бирү һәм кич ятканда аларны ефәк тышлы мендәрләргә салу һәм хәтфә юрганнар белән ябу. Алардан башка өйдә берничә баш эт бар, алар артыннан да йөрергә кирәк, шулай да болар артыннан йөрү мәчеләрнеке кебек түгел, карчык мәчеләрне үз балалары кебек сөя һәм иркәли. Баштан эш яхшы барган төсле иде, Мук һәрвакыт тук була, арырлык эш тә юк, карчык та аңардан разый төсле. Тора-бара мәчеләр тынычсызлана башлыйлар, карчык өйдә юк вакыт булса, алар котырган төсле бүлмәләрдә, идән буйларында чабышырга тотыналар, бөтен әйберләрне түгеп, актарып, ватып бетерәләр, карчыкның аз гына тавышы ишетелүгә, барысы күз ачып йомганчы мендәрләргә утырып бетәләр дә, бернәрсә дә булмаган кебек акрын гына койрыкларын бутап торалар. Карчык өйдә эшләнгән җыйнаксызлыклар, башбаштаклыкларның һәммәсе өчен тик Мукны гына гаепли, бичара Мук никадәр әйтсә дә, аның сүзенә колак салмый, чөнки карчык

бернәрсә дә эшләмәгән төсле тилмереп карап торган мәчеләренә Муктан артыграк ышана. Мук монда да бәхет таба алмавына бик кайгыра башлый һәм карчыктан китәргә үзенә сүз бирә. Ләкин ул инде беренче сынавыннан акчасыз сәяхәткә чыгуның ни дәрәҗәдә авыр эш икәнен бик аңлаганга, ничек булса да, карчыктан түләргә вәгъдә итсә дә, әле һаман бирмәгән хезмәт хакын алырга уйлый: бу өйдә һәрвакыт ябып тора торган һәм аның эченә Мукның бер генә мәртәбә дә карамаган бер бүлмә бар иде. Карчыкның шул бүлмәдә буталганы күпвакыт ишетелә һәм Мукның анда ни барын беләсе килә иде. Ул инде шул бүлмәдә карчыкның хәзинәсе бардыр дип уйлый башлый, ләкин ишек һәрвакыт бикле торганга, хәзинә янына керергә мөмкин түгел иде. Бервакыт иртән карчык өйдән чыккан гына иде, кечкенә эт Мукның янына чабып килә. Ул этне карчык никтер сөйми, ләкин Мук башка хайваннарның һәркайсысыннан аны артык күрә, шуның өчен эт аңа бик нык иләшкән иде. Кечкенә эт килә дә Мукны гүя бер җиргә чакырган кебек була, акрын гына аның чалбарыннан тартып китә. Мук аның белән уйнарга яратканга күрә дусы артыннан бара. Эт туп-туры карчыкның ятак бүлмәсенә керә дә Мукның бервакытта да күрмәгән кечкенә генә бер ишекнең янына барып туктый, ишек яртылай ачык. Эт анда кереп китә, аның артыннан Мук та юнәлә. Мукның шатлыгына чик юк, чөнки ул моңа кадәр эзләнеп йөргән җиремә килеп кердем, дип уйлый. Бөтен җирдә алтын юкмы икән дип эзләнә, алтын күренми, ләкин төрле төстәге кием һәм гаҗәп төсле савытлар күп күренә, бигрәк тә бер савыт аның күзенә чалына, ул пыяладан ясалып, нәкышләп[1] бетергән. Мук аны тотып әйләндерергә тотына. Бу савытның

---

[1] *Нәкышләп* — бизәкләп.

капкачы очып төшә дә челпәрәмә килеп ватылып китә. Нинди коточкыч хәсрәт!

Кечкенә Мук куркуыннан аз гына үлмичә кала, хәзер инде аның өчен качудан башка бернәрсә дә калмый, чөнки карчыкның аны бу эше өчен үтерү ихтималы бик бар, ул инде юлга эләктереп китәр өчен тагын бер мәртәбә бүлмәне карап чыкты. Аның күзенә җиңел башмаклар гына күренә, алар матур булмасалар да, гаять тә зурлар. Мукның башмагы инде тузган иде. Бу башмакларның зур булулары бигрәк тә аның күңеленә ошыйлар. Әгәр аларны кисә, әлбәттә, һәркем: «Мук бала вакытындагы башмакларын киеп туздырган»,— диярләр. Ул тиз генә үз башмакларын ташлый да боларны кия. Шулвакыт арыслан башы төсле чукмар башлы таяк та аны кызыктыра. Ул аны да бүлмәдән алып чыгып китә һәм күпме-күпме көч белән юлга чыгып йөгерергә тотына. Аның болай каты чапканы гомерендә беренче генә булгандыр. Гүя аны бер яшерен көч алып барган төсле була иде. Ул үзенең чабуын туктатырга бар көче белән тырыша, тик булдыра алмый, башмаклар бии, ком туздырып, Мукны өстерәп алга баралар, ниһаять, ул гаҗиз булып, атларга кычкырган кебек, үз-үзенә: «Тукта, тпру, тпру» — дип кычкыра. Башмаклар шунда ук туктыйлар. Мук борыны белән җиргә егылып китә, ул үзенең кыйбатлы булган табылдыгы өчен гаять шатлана, инде ул үз хезмәте бәрабәренә бернәрсә тапты. Моннан соң бәхеткә ирешү җиңел булыр. Шул тәмле, матур уй эчендә Мук йокыга китә. Аның өчен кечкенә гәүдә зур башны күтәреп тора алмый, әлеге изгелек иткән эт дусы аның төшенә кереп: «Сөекле Мук, син бит әле башмакларыңның хикмәтен белеп бетерә алмыйсың, бел аны, әгәр үкчәң өстендә өч мәртәбә әйләнсәң, үзең җиргә очарсың, таягың белән һәртөрле казна-хәзинә табарсың, әгәр алтын казна булса, таягың өчне, көмеш



булса, икене сугар». Бу хәбәр төштә генә күренгән булса да, Мук үзенең бәхетен сынап карарга уйлый, тик шунысы кыен: ничек итеп үкчә өстендә әйләнергә кирәк. Ул эш бик җиңел кешегә дә шактый кыен, авыр булачак. Мукның исә, бердән, үз башмаклары бик олкән, икенчедән, башы бик авыр. Шуның өчен башмакларының хикмәтен күргәләгәнче берничә мәртәбә борынын җиргә бәргәләп аладыр.

Ниһаять, ул үкчәсе белән тәгәрмәч кебек әйләнеп китә дә иң якындагы бер шәһәргә очып китәргә уйлый, ул арада башмаклар да һавага, болытлар арасына күтәрелеп китә, Мук ни күзе белән күрсен: бер шәһәрнең базарына килеп төшкәнен тоймыйча да кала, ул халык арасында әрле-бирле йөрергә уйлый, ләкин тиз үк, тын урамга китүне артык күреп, халык эченнән тая. Базарда аны төрле яктан кысалар, этәләр, аның башмакларына басалар, яисә һәркемне эләктереп йөри торган кылычы өчен аңа ачуланалар. Кечкенә Мук бик җитди рәвештә тырышып, ничек тә булса берәр нәрсә табу турында фикер йөртә башлый. Күмелгән казнаны таба торган таягы барын белә, ләкин ул казнаны кайдан эзләргә кирәк. Иң азак чиге ул үзен күрсәтеп тә акча табарга мөмкин, тик аның хөббе нәфсе[1] генә алай итәргә ирек бирми. Менә аның кинәттән үзенең чабарга шәпле икәне исенә килеп төшә, әллә шул башмаклар белән азык табу чарасына керешергә кирәкме икән? Чөнки тиз йөгерүче булып яллану өчен урын табарга була. Бигрәк тә мондый хезмәтчеләр патша сарайларына кирәк була иде. Мук озак исәпләми, тота да бер сарайга китә, капка төбендә аны бер сарай сакчысы туктатып, аның кем икәнен, кайдан һәм ни өчен килгәнен сорый, үзенең хезмәткә керергә уе

[1] *Хөббе нәфсе* — мин-минлеге.

барлыгын сөйләгәч, Мукны сарай назыйрына[1] алып китәләр. Мук, түбәнчелек белән сәлам биргәннән соң, назыйрга патшаның хәбәр йөртүче хадимнәреннән[2] берсе буласы килгәнен сөйләп бирә. Назыйр Мукның башыннан аягына кадәр бер күтәрелеп карый да кычкырып көлеп җибәрә: «Ах, җен суккан нәрсә, терсәк буйлы аякларың белән йөгерүчеләр рәтенә керергә уйлыйсың, хәзер күздән югал, минем синең белән шаярасым килми!» — ди назыйр. Мук үзенең чынлап әйткәнен, шаярырга бер дә теләмәгәнен һәм иң көчле, кызу чабучылар белән йөгерешеп, сынап карарга хәзер икәнен сөйли, назыйр кызыксынып, аның йөгерүен сынарга уйлый. Мукның кәефен яхшылату өчен ашханәгә илтеп, яхшы итеп аны туклandырырга куша. Назыйр үзе патша янына сарайга кереп китеп, кечкенә Мук хакында хәбәр бирә, аның хәлен сөйли. Патша уенны яратучан кеше булганга, шатлык белән бу кызык хәбәрне кабул итә.

Тиз генә сарай артындагы бер зур болынга тамашаны карау өчен бөтен сарай әһленә мәйдан ясала. Патша сарай егетләренә, кызларына хәбәр иттерә, болар үзләренең якыннарына, алар тагын үзләренең белеш-танышларына хәбәр тараталар. Шул көн кич аягына йөри алган һәркем кечкенә Мукның тамашасын күреп көләргә җыелды. Бөтен сарай әһле хәзерләнгән урыннарга урнашкач, Мук мәйданга чыгып бик түбәнчелек белән генә халыкка баш ия, ул чыгуга бөтен халыкның шатлыклы тавышлары күккә күтәрелә, чөнки алар мондый гаҗәп кешене гомерләрендә беренче мәртәбә генә күрәләр: зур башлы, кечкенә генә гәүдәле, койрыксыз җилән, киң чалбарлар, чамасыз олкән башмаклар, янда тагылган озын хәнҗәрләр шулкадәр кызык төсле күренә, һич кыч-

[1] *Назыйр* — башлык.
[2] *Хадим* — хезмәтче.

кырып көлмичә була торган түгел, сарай назыйры, Мукның теләве буенча, иң яхшы йөгерүчене сайлап ала. Ике йөгерек килеп басалар, бер шаһзадә Амарза китәргә ишарә ясый, йөгерекләр уклар кебек атылып китәләр, иң элек Мукның иптәше уза, ләкин тиз үк аны куып җитә дә үтеп тә китә һәм алдан барып билгеләнгән бер урынга килеп туктый, моны күреп, халык гаҗәпсенеп тын да алмыйча торалар. Башлап патша кул чапкач кына, бөтен халык көчле хәрәкәткә килә, шатлана, кычкыра: «Яшәсен, яшәсен өскә чыгучы!» — диләр. Мукны патшага китерәләр. Мук аның аягына егылып: «Бөек патшам, мин әле иң кечкенә һөнәремне сезгә күрсәттем. Миңа үзеңнең хадимнәрең рәтенә керергә рөхсәт итсәнә!» — ди. Патша Мукны күтәреп: «Сөекле Мук, син минем сарай йөгереге булырсың. Һәрвакыт минем каршымда торырсың, һәр ел йөз алтын һәдия[1] алырсың. Беренче дәрәҗәдәге хадимнәр белән бер өстәлдән ашарсың»,— ди. Моны ишетеп Мук үзен бәхеткә ирештем дип уйлый һәм рәхәтләнеп, тынычлап китә. Ул бик тиз патшаның мәрхәмәтенә ирешә, аңа ярап китә, чөнки ул патшаның кушкан бик авыр эшләрен дә бик тизлек, осталык, турылык белән урынына китерә.

Мукның болай зур дәрәҗәдә үсүен башка хадимнәр күрә алмый башлыйлар, чөнки аларга тиз йөгерүдән башка бернәрсә дә белмәгән кечкенә Мукка бу урынны бирү бик хурлык кебек тоела. Шуннан соң аны үтерүгә төрле чаралар эзләргә тотыналар, ләкин патшаның Мукка булган чын ышанычы һәммәсен кырып ташлый. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә Мук шактый югары дәрәҗәгә менеп утыра. Мук үзенең тирәсендәге күңелсезлекләрне сизә, ләкин аның турысында күп уйламый. Ничек булса да, аларга ярап, үзен алардан сөйдерергә тели, чөнки ул ис-

[1] *Һәдия* — бүләк.

киткеч яхшылык кылырга, күңелле булырга тели, тырыша һәм усаллык кылырга күңеленә дә китерми. Менә аның тылсымлы таягы кинәт исенә төшә, аны инде ул соңгы вакытларда оныткан да иде. Менә, ди, таяк белән миңа казна табылса, ул иптәшләр белән дә килешеп булыр иде, ди Мук. Бер чит дошман ил һөҗүм кылган вакытта патшаның атасы тарафыннан бакчага күмелгән хәзинә турында бер генә түгел, ничә тапкырлар ишеткән иде ул, атасының ул хакта угылына әйтергә өлгерә алмаганын да күп сөйлиләр иде. Моннан соң Мук хәзинәне табу уе белән таягын алып бакчаның ерак почмакларында еш-еш йөри башлый. Вакыйган, бервакыт ул шулай йөргәндә, таяк кагылып, дерелдәп китә һәм өч мәртәбә җиргә суга. Мук шунда ук кылычы белән янында торган агачка бер билге ясый да сарайга кире китә. Кичен көрәк алып яңадан бакчага чыга. Хәзинә бик тизлек белән генә аның кулына керми, чөнки аның көче аз, көрәк иләмсез авыр. Ике сәгать азапланып, ул аз гына чокыр казыды. Төн буена эшләп, мең бәла белән бик каты җиргә барып төртелде. Ул тагын кызыбрак эшләргә тотына, шуннан соң тиз үк тимер капкачны ачып җибәрә, чокырга төшеп, капкачны алып караса, ни күзе белән күрсен: бер чүлмәк алтын тәңкәләр... Мукның көчсез куллары аларны күтәрә дә алмыйлар. Алай да булмагач, ул алтын тәңкәләрне чалбарына төйи, билбавына кыстыра, җиләненә тутыра, калганын җир белән каплый да, алтын төягән төенчекне аркасына асып, сарайга кайта. Инде барлык дошманнарым дус булырлар, дип уйлый.

Ләкин ул алай булмады. Мук тәҗрибәсезлегеннән алтын белән генә чын дуслыкны алырга мөмкин түгеллеген белмидер иде. Аның үкчәсендә бер әйләнергә дә үзенең төене белән күздән югалырга кирәк иде. Ләкин ул юмарт кулы белән тирә-ягындагыларга алтынны бер дә кызганмыйча чәчте дә чәчте. Аның

болай булуы яхшылык урынына көнчелекне генә арттырганнан-арттыра барды. Мукка иптәшләре төрле бәлаләр яба башлыйлар. Баш повар: «Мук ясалма акчалар белән булыша»,— ди. Назыйр Әхмәт: «Ул патшаның бөтен нәрсәләрен алдап ала»,— ди. Мукның иң каты дошманы, патша хәзинәсен караучы Архаз: «Мук бик осталык белән хәзинәдән урлыйдыр»,— ди. Шуннан соң барысы да сүз куешалар. Бервакыт сарай хадимнәренең олугларыннан Куршуси бик мескен, бик борчылган төс белән патшаның каршына килә. Ул хәлне күреп, патша ирексез аның сүзләренә колак сала: «Ах, патшам! Ахрысы, минем өчен сезнең мәрхәмәт яктыгыз болыт булып каплангандыр»,— ди. «Нинди бикәр[1] уйлар бу, дус? Минем синнән мәрхәмәтемне кызганганым юктыр бит?» — ди патша.

Куршуси вәсвәсә кылырга тырышып, патшаның шактый вакыттан бирле Мукны гына бүләкләп, башка чын күңел белән туры хезмәт иткән хадимнәрне онытуы турысында сөйләп бирә. Патша аның ни әйтергә теләгәнен аңлый алмый, шуннан соң аңа Мукның чамасыз булган юмартлыгы турында сөйләп, ничек булса да, аның патша хәзинәсен талавына ишарәләр ясарга тырыша. Исәп-хисап бирергә яратмаган хәзинәдар[2] бу рәвештә Мук зарарына сөйли иде. Патша Мукны тәфтиш кылырга[3] һәм мөмкин булса, аны сакларга куша.

Мукның акчасы бетә. Ул яңадан көрәк ала да бакчага китә, анда җәйгән җиләненә алтыннарны салыйм дигәндә генә, аңа усаллык кылучы сакчылар килеп чыгалар да патшага алып китәләр. Патша, вакытыннан кичектермичә, бу эшне башкарырга

---

[1] *Бикәр* — нигезсез, сәбәпсез.
[2] *Хәзинәдар* — хәзинә сакчысы.
[3] *Тәфтиш кылу* — тикшерү.

карар бирә. Хәзинә чүлмәген җирдән казып алалар һәм көрәк, җиләнне патша аягы янына китереп куялар. Хәзинәдар: «Без Мукны чүлмәкне җиргә күмәргә торган вакытта эләктердек»,— ди. Мук исә үзен гөнаһсыз санарга тырышып, чүлмәкне күмәргә уйламаганын, әмма казып алырга теләгәнен сөйли. Мондагы бар кешеләр дә аның сүзеннән кычкырып көләләр.

Патша кечкенә Мукның эшләгән начарлыгына кәефе китеп һәм ачуы килеп: «Ах, бәдбәхет! Син, ахры, шундый ахмаклык, оятсызлык белән үзеңнең патшаңны алдармын, дип уйлыйсыңдыр. Хәзинәдар, минем хәзинәдән югалган акча шул түгел микән?» — ди. «Моның шул акча булуында һич шик кылып булмый, падишаһым! Моның урланган акча булуына ант итә аламын»,— ди хәзинәдар.

Шуннан соң патша Мукны богаулап хибескә[1] ябарга, алтыннарны, хәзинә сандыгына салу өчен, хәзинәдарга тапшырырга кушадыр. Моны ишетеп, хәзинәдар шатлыгыннан үзенең кайда торганын белми һәм тизрәк өенә кайтып, алтыннарны санарга ашыгадыр. Ул яман кеше чүлмәк төбенә куелган: «Дошман мәмләкәткә һөҗүм кылды, туфан кебек ишелде. Мин хәзинәмнең бер кисәген күмәргә мәҗбүр булдым. Әгәр аны табып минем угылыма китереп бирмәсә, шул кешене минем бәддогам сугар. Патша Сәгъди»,— дип язылган мәктүбне беркемгә дә әйтми.

Кечкенә Мук бик кайгы эчендә тоткын булып төнне үткәрде. Чөнки ул патшаның нәрсәсен урлаган өчен, әлбәттә, үлем җәзасы булыр, дип уйлый, ләкин тылсымлы таягының серен әйтә алмый, чөнки ул вакыт таяк та, башмак та кулыннан китәчәкләр. Хәзер инде аның башмаклары бер хезмәткә дә ярамыйлар: богау бик кыска булганга, үкчәгә басып

[1] *Хибес* — төрмә.

әйләнү һич мөмкин түгел, иртән үлем җәзасына алырга килгәндә, таякның серен әйтергә уйлый: «Исән калу таяктан аерылуга караганда артыграк булыр»,— ди. Ул патша белән үзе генә сөйләшергә сорый һәм аңа мәсьәләне сөйләп бирә. Патша элек ышанмый. Шуннан соң Мук таякны сынап карарга үтенә. Бакчаның бер җиренә алтыннар күмеп, Мукка эзләргә кушалар. Таяк, бик тиз алтын бар урынны табып, өч тапкыр җиргә суга. Шуннан соң патша хәзинәдарның алдаганын аңлый да, шәрекъ гадәте буенча, аңа ефәк җеп җибәрә, ул шул җеп белән үзен асып үтерергә тиеш, дигән сүз була.

«Менә нәрсә, Мук,— ди патша,— мин сине үлемнән коткарам, әлбәттә, таягың кебек синең башка яшерен серләрең дә бардыр. Менә сиңа ике нәрсә, кайсысын сайласаң да, үз иркең: берсе мәңгелек хибес, яисә әйт: синең аякларыңның тиз йөгерүендә нинди хикмәт бар?»

Төнен караңгы зинданда яту үзәккә үткәнгә, Мук курка. Шуңа күрә башмактагы серне ул ачып бирә, тик үкчәгә басып өч тапкыр әйләнү кирәклекне генә әйтми. Патша шунда ук башмакларга баса. Ни күзе белән күрсен, ул бакча эчендә ук кебек чаба башлый. Туктарга тели, булдыра алмый. Чөнки башмакларны ничек туктатырга икәнен белми. Мук үзенең гөнаһсыз җәзасы бәрабәренә патшадан үч алырга теләп, ярдәмгә кул сузмый. Патша һушыннан язып егылганчы йөгерә дә йөгерә.

Патшаның Мукка ачуы чиктән аша: «Мин сине үлемнән коткарырга сүз бирдем һәм сүземне бозмамын, ләкин син бүген кичкә кадәр минем мәмләкәт чигендә булмасаң, мин сине агачка асармын»,— ди.

Башмаклар һәм таяк хәзинә саклана торган җиргә озатылалар. Мук, үзенең ахмаклыгына сукранып, әүвәлгедән дә ярлырак булып, сарай капкасыннан чыгып китә. Шунсына шөкрана кылып, рәхмәт әйтерлек бар: бу мәмләкәт зур булмаганда, Мук кичкә

кадәр хөдүдкә[1] ирешә аладыр. Ул үзенең башмакларында йөрергә өйрәнгәнгә, хәзер алардан башка йөрүне дә онытып бетергән иде.

Мәмләкәт чигенә җиткәч, Мук сәфәрен икенчегә борып җибәрә. Чөнки адәмнәрдән чынлап бизә һәм дөньядан качып, урманга барып, тик ялгыз берүзе генә торырга уйлый. Урманда да аңа торырга нәкъ яраралык, әйбәт урын да табыладыр. Тирә-якта каплап алган, куе күләгә төшерә торган инҗир агачлары, алар астыннан саф сулы чишмә ага. Мук йомшак үләнгә ята да үзен ачлыктан үтерергә уйлый. Ул яту белән, бик талу сәбәпле, үлмәстән элек каты йокыга китә. Йокыдан уянгач, ул үзенең карынында ачлык газабы сизәдер. Шуннан соң ул ачлыктан үлү иң читен, иң начар эш икәнен белеп, тирә-ягыннан ашарга эзләнә башлый. Аның нәкъ баш турысында гына пешкән һәм өлгергән инҗир җимешләре асылынып торалар. Ул агач башына менә дә бик матур итеп үскәннәренең берничәсен ашап төшә, аннан соң инешкә барып су эчә, ул су эчендә искиткеч зур баш, зур борын һәм иләмсез зур колаклар күргәч, аз гына һушыннан язмый кала. Шуннан ук ни күзе белән күрсен, аның үз колаклары ярты аршин озынлыгында булганнар. «Ни эшләдем соң мин, нинди хезмәтем бәрабәренә мин бу ишәк колакларын алдым. Мин үз бәхетемне таптаган нинди ишәк?» — ди Мук һәм кайгырып кына агач төбенә утыра. Ләкин бик тиз тагын тора, чөнки ул һаман ач әле, ашамлык әйбере һичбер кайда күренми, ни эшләмәк кирәк? Тагын шул ук инҗирләргә таба сузыла. Монысында ул туйганчы ашый. Шуннан соң ул иләмсез зур колакларны чалма эченә тыгып, аз гына булса да үзен матурларга уйлый, колакларын капшап карый. Ни күзе белән күрсен, теге зур колаклар инде юк. Шуннан

---

[1] *Хөӱдүд* — чик, ил чиге.

соң килбәтсез колакларының югалганлыкларын һәм коточкыч ямьсез борынының кире элеккеге хәленә кайтканын чынлап белү өчен тагын елгага таба йөгерә. Барып суга карый, дөрес тә шулай. Минем болай булуга инҗир сәбәп булды микәнни? Бер мәртәбә ашагач, колаклар, ямьсез борыннар килеп чыкты, икенче мәртәбә ашагач, алар тылсым белән юк булдылар. Шулай ук әүвәлге бәхет йолдызы кире дә килергә уйлыймы икәнни? Шуннан соң Мук һәр агачтан да инҗирләр тутыра да яңадан бер киткән иленә бара. Иң якын шәһәрдә киемен алмаштыра да элекке патшасы туган шәһәренә китә.

Бу вакыт елның җимеш бик аз табыла торган бер чоры була. Мук сарай капкасы төбенә генә килеп утыра. Ул патшага кирәк булган нәрсәләрне сатып алырга чыгучы аш остасын бик яхшы белә. Аңа озак көтәргә туры килми, дөрестән дә аш остасы базарга чыга да әйберләрне карап йөри. Кинәттән инҗиргә күзе төшә: «Аһа, менә бу сирәк була торган нәрсә, әлбәттә, моны алып кайтсам, патшама ярармын. Бөтен хакы күпме тора?» — ди повар. Мук уртача гына хак белән сатып җибәрә. Аш остасы янындагы колына савытын бирә дә башка җиргә китә. Мук инҗирләрне ашап берәр бәхетсезлек, күңелсезлек хәл булса, сатучыны таптырырлар, дип, тиз генә базардан тая.

Патша бик шат булып утыра. Илдә аз була торган әйберләрне табып китерә алган өчен һәрвакыт аш остасын мактый, повар бер читтә елмаеп, шатланып тора. «Иртә кычкырган күкенең башы авырта» дигән сүз хәтеренә дә килми. Ханзадәләр[1] поварның бүген нәрсә хәзерләгәнен түземсезлек белән көтәләр. Савытларда бик матур итеп хәзерләнгән инҗирләр бирелгәч, шундагы бар халык та гаҗәпләнеп китәләр. «Нинди тәмле!.. Повар, син уңган кешесең, безнең

---

[1] *Ханзадә* — хан улы, патша улы.

күңелебезгә ярарлык зур хезмәтләр күрсәтәсең!» — ди патша. Шул сүзләре белән патша үзе инҗирләрне кешеләргә өләшәдер. Һәрбер ханзадәгә икешәрдән, сарай хатыннарына, вәзирләргә, агаларга бирәр инҗирдән бирә, калганын үз алдына куеп ашый башлый. «Әти, ни эшләп син кинәт болай үзгәрдең?» — дип, ханзадә кычкырып җибәрә. Патша кып-кызыл кызара. Һәммәсе күтәрелеп, патшага карыйлар. Дөрес тә, зур озын колаклар патшаның җилкәсенә кадәр салынып торалар, ямьсез озын борын сакал өстенә чикле төшә. Үзара караша башлыйлар, һәммәсе акрынлап кына шул хәлгә кереп бара...

Сарайга ирешкән бу куркыныч хәлнең ни дәрәҗәдә начар тәэсир иткәнен тел белән әйтеп тә булмый. Шунда ук бөтен шәһәрнең докторларын чакырып китерәләр. Никадәр даруласалар да, колаклар, борыннар кечерәймиләр. Бер ханзадә операция ясатырга разый булып, колак, борыннарын кистерә, ләкин алар яңадан үсәләр.

Бу хәбәр бөтен шәһәргә тарала һәм Мукка да килеп җитешә. Мук эш башларга вакыт икәнен аңлап, муафикъ[1] киемнәр таба да, төсен алмаштырып, кәҗә йоныннан ясалган озын сакал куеп, сарайга барып керә. Мук үзен читтән килгән мосафир[2] доктор дип тәкъдим кыла. Әүвәл башта аның хезмәтеннән тартыналар. Арадан бер ханзадә шифалы инҗирне ашарга күнә, ашау белән аның ямьсезлеге бетә, әүвәлге матур хәленә кайта, шуннан соң барлык кеше оста докторга сарылалар. Патша, моны күреп: «Менә сиңа бар хәзинәм, теләсәң кайсын ала күр, тик мине бу оят, шыксыз хәлемнән чыгара күр!» — ди.

Патшаның сүзләре Мукның колагына музыка кебек яңгырап китә. Мук сарайга кергән вакытта

---

[1] *Муафикъ* — ярашлы, үзенә туры килгән.
[2] *Мосафир* — юлчы.

идәндә башмакларының һәм аның белән бергә таягының торганын күргән иде. Ул патшаның хәзинәсен караган булып, башмакларына таба килә. Һәм аларның эченә кереп баса. Таякны кулга ала. Ясалма сакалын ташлап, кечкенә Мук кыяфәтендә патша янына килеп: «Ах син, сүзеңдә тормый торган патша, син тугры хезмәтчеләрнең эшләрен шулай тәкъдир итәсеңме? Мин кечкенә Мук хакында сагынмаклык булсын өчен, синең озын колакларыңны калдырамын»,— ди һәм, шул сүзләрне әйтеп бетергәч, башмакларының үкчәсендә әйләнә дә, Мук юк булып китә. Патша, ярдәмгә кеше дә чакыра алмыйча, авызын ачкан көенә кала.

Менә шул вакыттан бирле кечкенә Мук берүзе генә тора, чөнки ул адәмнәргә нәфрәт күзе белән карый. Тәҗрибә күрмеш аны акыллы итте. Кыяфәте әүвәлгечә кызык сыман калса да, аңардан көләргә ярамый, тик аннан гыйбрәтләнергә генә кирәк.

Менә шул рәвештә минем эти Мук хакында сөйләп бетерде. Мин үземнең кечкенә Мукны мыскыллавыма бик үкендем һәм эти дә мине гафу итте. Минем аркылы бөтен иптәшләрем дә аның башыннан үткәннәрен белделәр. Без һәммәбез дә аны сөя башладык, бервакытта да аңардан көлмәдек, без аны олуг, хөрмәтле кеше кебек таныдык.

*1915*





# Хан кызы

## 1

Моннан мең еллар элек Кара Идел[1] буенда, Болгар иленең алтын каласында Алмас хан тора иде. Болгарлардагы байлык, яхшы тормыш, тугрылык, белем күплек тугрысындагы шөһрәт бик ерак илләргә, күп патшаларга таралган иде. Чит илләрнең кешеләре дә Болгар иленә бай, тыныч, рәхәт җир дип бик кызыгалар иде. Күп вакыт комсыз патшалар, Болгарның байлыгына кызыгып, яу белән киләләр, илне таларга тотыналар иде.

Болгарлар үзләре һәрвакыт сугышырга, чит илләргә һөҗүм кылырга яратмасалар да, үзләренә каршы ук, сөңге күтәргән дошманнарны бик осталык белән кире кайтаралар иде, чөнки аларда корал, сугыш кирәкләре бик яхшы эшләнә иде. Шулай да кайсы вакыт көтмәстән килеп баскан зур яулар Алтын калага кереп, иге-чиге булмаган байлыктан өлеш алып китә иде.

[1] *Кара Идел* — Волга, Идел елгасы.

Болгар иле зур ил иде. Кара Идел, Чулман[1], Вятка, Пермь, Агыйдел сулары буенда торган чит халыклар, кабиләләр матур, тыныч тормышны болгарларга, тик шуларга буйсынып торуда гына дип беләләр. Әгәр читтән дошман килсә, уртак көч, батырлык белән тыныч ил өчен сугышалар иде.

Алтын кала бу Болгар иленең иң матур, хан тора торган шәһәре иде. Кайсы вакыт аны Болгар каласы дип тә йөртәләр иде. Ул Алтын каланың матурлыгы, байлыгы искиткеч иде. Чит илләрдән, ят патшалыклардан илгизәрләр сокланып, аны күрергә киләләр иде. Ул Кара Иделнең иң матур җиренә, калку гына җиргә салынганга, әллә кайдан күренеп тора иде.

Алмас ханны да, Болгар иле башка ханнарны да ярата иде. Ләкин Алмас ханны үзенә башка, артык яраталар иде, чөнки ул бик туры сүзле, гүзәл холыклы, моның өстенә кечек күңелле хан иде. Аның каршында барлык кеше бер иде, хөкеме туры, биләргә[2] ирек бирми, һәр җирдә дөрест хөкем йөртә иде. Шуның өчен дә Алмас хан бөтен илнең сөекле ханы, изге атасы иде.

Болгар иленең тынычлыгы, Алтын каланың бай матурлыгы, Алмас ханның чын гакыл иясе хан булуы чит илләрдәге сәйяхларның[3] күңелләрен җәлеп кыла иде. Болгар иленә килә торган илгизәрләрнең исәбе-хисабы булмый иде. Илгизәрләр үз йортларына, үз илләренә кайтып, Болгар иле, Алтын кала, Алмас хан сарайлары тугрысында таң-тамаша калып сөйлиләр, тыңлаучыларның исләрен китәрәләр иде. Кайсыбер илгизәр: «Болгар илендәге рәхәт тормыш, Алтын каланың матурлыгы тугрысында инде сөйләп аңлатырлык кына түгел иде»,— дип башлый да киң генә, рәхәт кенә сулап, шулай сөйләргә керешә:

---

[1] *Чулман* — Кама елгасы.
[2] *Би* — түрә.
[3] *Сәйях* — сәяхәтче.

— Айлар барасың, атналар барасың, әллә ничә халыкларны үтәсең, һаман Алтын калага җитеп булмый. Җиттең дигәндә генә, ничә көннәр барасың. Ул арада: «Карагыз, иптәшләр, теге нәрсә?» — дигән тавышка күтәрелеп киткән якка томырылып карыйсың, чыннан да, нәрсәдер урманнардан югары булып күренә. Шуннан соң, менгән атларыңны туктатып, тагын ныграк карыйсың.

— Егетләр, бу Алтын кала инде.

— Шул булырга кирәк, күрәсезме? Әнә калкып-калкып торган зур багана кебек нәрсәләр, ак ташлар! Ул арада Алтын кала күздән югала. Ахрысы, без уйсурак җиргә җиткәнбездер, тагын калку җиргә чыгабыз.

— Чын да шул хәзер ачык күренә бит.

— Шул булыр, егетләр, Тәңрегә мең теләү, җитәбез, ахрысы.

— Җиттек инде хәзер, бүген Алтын калада кунарбыз.

— Кичкә калсак эченә җибәрмәсләр, сакчылар кояш баегач җибәрмиләр бугай.

— Тәңре кушса, читтәрәк кунып, изге көн иртән...

— Кояш югары бит әле, озакламый җитәрбез инде, монда гына бит инде.

Безгә якын күренсә дә, Алтын кала ераклаша гына бара. Без барабыз, барабыз. Безнең тирәбездә куе, зур урманнар. Андагы бал, чәчәк исләре безне каплап ала. Алтын калага якынлашкан саен, күренешләр матурая, төрләләнә, җан куана. Ул һавалары тәмле, сулап туяр хәл юк. Шул җирдән китәсе килми. Айлар, атналар буенча юлда күргән авырлыклар, борчылулар һәммәсе онытыла. Менгән атларыбыз, дөяләребез җиңеләеп, тиздән озаклап, иркенләп ял итәчәкләрен сизгән төсле пошкырына башлыйлар.

Ул арада күтәрелеп карыйсың да, ерак-ерак җирдә кап-кара болыт төсле бернәрсә күренә.

— Карагыз әле, иптәшләр, бу нәрсә болытмы?

— Су.

— Нинди су?

— Кара Идел!

— Кара Идел, Кара Идел, Кара Идел, егетләр, карагыз әле, нинди зур! Иге-чиге юк!

— Тәңрегә мең теләк, Кара Иделгә җиттек. Алтын кала шуның янында бугай.

Шуннан соң тагын күңел күтәрелеп китә. Юлчылар, илгизәрләр барың бергә тупланып карап торасың. Су эченнән коенып чыккан каз-үрдәкләр кебек сөешеп, өсбашларны кагасың, атларның йөген иярләп, төзәтеп, яңадан алга юнәләсең. Алтын кала бер якында ук төсле, бер әллә кая төсле күренә. Инде җиттек, менә ул каршыбызда дисең, бераздан карасаң, күзгә дә күренми.

Кояш та түбәнәйгәннән-түбәнәя бара. Акрынлап ул, куе агач артына яшеренгән куян кебек, Кара Идел артындагы тау-урманнар артына поса. Ул актык каравыңда Алтын каланы безгә ачыграк күрсәтә, инде безгә ак ташлардан салынган Алмас хан йортлары, башка угъланнар, бәкләр, мирзаларның өйләре апачык булып күренә. Көмеш кебек ялтырыйлар.

Шул арада юлның икенче тамагыннан уклар, җәяләр таккан, сөңге аскан, атка менгән бер кеше килеп чыга. Ул кара, үткен күзләре белән сөзеп карый да, ук кебек атылып, безнең янга килә. Атыннан егетләрчә сикереп төшә. Аның чәче шундый каты, кара, бөртекләп санарга була.

— Изге юл, мирзалар. Алтын каланың котлы кунаклары булыгыз!

— Тәңре ярлыкасын сезне. Илнең башы булыгыз! Бу йортны, атаклы Алтын каланы, сезнең олуг Алмас ханыгызны күрергә килүче илгизәрләр без. Батыр егет, үзегез кем буласыз?

— Мин Алмас ханның юлчабары булам. Хуш киләсез.

— Тәңрегә мең теләү! Алмас ханга йөз чөерәбез, җирдән туфрак алабыз.

— Ханнар ханы Алмасның алтын табаклары, көмеш аяклары чит ил мирзаларына ачык. Хуш килдегез!

Юлчабар, ук кебек атына менеп, тезгенне кагуга, аның түм-түгәрәк юргасы күздән югала. Юлчабар юргасы өстендә аз гына иелгән килеш, ябыштырып куйган төсле бара.

— Нинди матур, уңган бүз бала[1], хан кияве бул.

Безгә төрле юлдан төрле кешеләр ничә төрле телдәге илгизәрләр килеп кушылалар. Кем генә булмасын, бар да Алмас ханның йорты, байлыгы, турылыгы, галимлеге тугрысында сөйли.

— Алмас хан белән Алтын каланың тиңдәше бар микән?

— Алмас хан дигәндә, кемнең генә йөрәге тетрәми!

Ул ара булмый, «Карагыз әле нинди матур!» дип, бар кеше Алтын каланы мактарга керешә.

— Моны кеше ясамагандыр, фәрештәләр булышкандыр. Алар ярдәм итмәсә, кеше кулы ничек бу чаклы төзи алсын.

Җитәбез, җитәбез, дип ничаклы барсак та, каланы урап алган койма төбенә барып җитә алмадык. Бер тотам җир килдек тә, калку гына тугайга килеп туктадык. Бу илне яхшы белгән кешеләр дә безгә килеп кушылдылар.

— Бергә куныйк, юкса, ул-бу...— ди безнең беребез.

— Илгизәрләр, сез курыкмагыз, бу җирдә бернәрсә дә булмас, безнең илдә әйберләргә бик тә (йозак) салынмый, биләребезгә бер угрының эшен карарга туг-

---

[1] *Бүз бала* — яшь егет.

ры килгәне юк. Бу ил иң тыныч, иркен җир, бу җирдә тәңреләр[1] үзләре яшиләр, юлчыларны алар үзләре саклыйлар. Алмас хан аяк баскан җирдә, аңа буйсынган җирдә урлау, талау булмас.

Күктә кызыллык бетеп, караңгы төшә. Без туктаган түбәдән Кара Идел күренә. Яланнар, утлавыклар җәйрәп яталар. Бездән ерак түгел җирдә елкы[2] көтүләренең пошкырулары, кешнәүләре ишетелә. Кара Идел өстендә искән җиңел, салкынча җилгә тугай болынынннан күтәрелгән мең төрле чәчәк, үлән исе килеп кушыла, сулап туеп булмый, дөяләребез шунда ук утларга тотыналар. Атларыбызны беравык бәйләп торабыз. Иярләрен алу белән алар да үләнгә кадалалар. Башларын да каерып алып булмый.

— Нинди ямьле, күңелле җир бу ил! Сүзе бик чын, монда фәрештәләр торалардыр.

Төрле җирдә утлар ягыла. Илгизәр, бүз балалар думбралар чиртеп уйнарга, бәетләр (үләңнәр)[3] әйтергә керешәләр. Аксакаллар, зурлар бик тәмләп, кызыксынып, Болгар иле, Алмас хан, Алтын кала тугрысында сөйлиләр. Тыңласаң, илнең зурлыгын, байлыгын, болгарларның укымышлылыкларын, бөтен илгә, кояш чыгыш, кояш батыш якларына үзләрен танытканлыкларын күккә күтәреп сөйлиләр. Үткән ханнарны, ханбикәләрне сөйләгәннән соң, иркен тын алып, Алмас хан тугрысында сөйләргә тотыналар.

— Безнең тәңреләр Алмас ханга зур байлыкны биргән, байлыктан аның тиңдәше юк. Аның Алтын каласы белән ярышырлык, узышырлык кала күптән юк, тик тәңреләр аңардан бернәрсәне кызганганнар,

[1] Ул чакта әле болгарлар мөселман булмаганнар, тәңреләргә ышанганнар. Күкне, җирне, кояшны, тауларны Тәңре дип таныганнар (*Ш.Әхмәдиев*).

[2] *Елкы* — ат.

[3] *Үләң* — җыр.

аның ир баласы юк. Ил аның өчен тәңреләргә меңмиллион теләүләр кылса да, ханның үзенең яраткан аргамагы белән изге дөяне корбанга чалып карасалар да, булмады, Тәңре аңарга бер кыз гына багышлады, бу ил, бу бай йорт аңар кала инде.

— Алай димәгез, Алмас ханның үлемен искә алмагыз, аның өчен бөтен ил Тәңрегә корбан булсын.

— Чыннан да шулай, аның үлемен искә алу, әле ул яшь, бәлки, тәңреләр иркәк бала да[1] багышларлар әле.

— Аның Гөлбикәсе бар. Инде ул Тәңредән башка бала сорамый.

— Гөлбикә тугрысында сөйләмәгез. Болгар иле аның саулыгына, озак яшәвенә генә теләктә булсын.

Думбралар моңына, Болгар белән Алмас хан тугрысындагы сүзләргә бәллүләнеп[2], арыган көйгә изрәп йокыга китәсең.

Иртә белән төрле кош: сандугач, тургай, кәккүк тавышлары һәм агач артыннан калкып килә торган кояшның җылы, ямьле нурлары безне сөеп, иркәләп уяталар. Күзне ачуга, әллә нәрсә бирсәләр дә, яңадан йоклыйсың килми. Йөрәк талпына, күңел сикерә, әллә кая омтыла. Киң генә тын аласың да, чын шатлык, рәхәт белән Тәңрегә теләү кыласың.

Болгар шәһәре безнең каршыбызда тора. Калку җиргә салынган. Андагы йортларның түбәләреннән алып барлык җирләре кояшка каршы елтырап-җемелдәп торалар. Берсеннән-берсе матур сарайларга, йортларга туя алмыйча карап торасың.

Изге юл: без Алтын калага юнәләбез. Менгән атларның өзәңге тавышлары, дөяләрнең пошкырулары, арба шыгырдаулары бердән кузгала. Кара Идел сул якта кала.

---

[1] *Иркәк бала* — ир бала.
[2] *Бәллүләнеп* — тирбәлеп.

Без бераз уңга борылабыз. Аннан соң акрынлап кына киң тугай, болынлык эченнән югары калкабыз. Алтын калага якынайган саен, аны ураткан таш коймалар зурая гына, биегәя генә бара. Илгизәрләр, юлчылар таш калага юнәләләр. Койманы үтеп керүгә, ак таштан ясалган, бизәп бетергән матур өйләр алдыңа килеп басалар. Исең китеп, аларның әле берсен, әле берсен сорыйсың. Алардан беренче күренгәне үк Алмас хан йорты төсле була.

— Кем йорты бу? Алмас хан...

— Юк, бу бәкләрнең берсенеке.

— Соң, бусы?

— Ул Тәңребирде угъланның йорты.

— Менә бусы инде билгеле...

— Юк, юк, соң, илгизәр, сезнең бу илгә, Алтын калага беренче аяк басуыгызмыни?

— Беренче... мин инде алдыбыздагы йорт Алмас ханныкы ук дип белгән идем. Ул да түгелме?

— Алар барысы да илнең зур бай мирзалары. Менә бусы ыслау[1] иле белән алыш-биреш кыла торган Тимербай мирзаның йорты, әнә тегесе Тукбай мирзаныкы, анысы гарәп иле белән алыш-биреш кыла. Атаклы Багдад патшасына Болгар нәрсәсен куя. Аннан безнең илгә бездә булмаган ят әйберләр алып кайта. Хан сакчылары юлбасарлардан саклыйлар. Тукбайның янындагы күгелҗем йортның иясе дә илнең бик зур бае. Аның меңләп дөясе Болгар нәрсәсе белән кызыл баш Кытай илләренә чикле җитәләр. Чит илләрнең ханнарыннан, олугларыннан, бәкләреннән безнең Алмас ханга бүләкләр китерәләр.

— Соң, Алмас ханның үз йорты кайда?

— Әле яңадан бер таш капка булыр.

---

[1] *Ыслау* — славян, рус һәм аларга кардәш поляк, чех кебек башка халыклар (*Ш.Әхмәдиев*).

Алмас ханга керер өчен атларны, дөяләрне, арбаларны урнаштырып, җәяү барырга кирәк. Угъланнар, бәкләр, олуг мирзалар да ары җәяү генә керәләр.

Без Алмас ханга керү өчен ике таш койма үтәргә икәнен, шулай ук җәяү кеше генә анда үтә алуын электән үк белсәк тә, каршындагы матур йортларга исереп, үзеңә-үзең ышанмыйча, атлаган саен сорашасың да сорашасың.

Икенче капканы керүгә, хан йортын күрәсең. Ул син уйлаганнан да артык матур була. Хан йортының чын ташлары болытсыз кояшка каршы ялтырыйлар. Күз чагыла, карап булмый. Иң элек кайсы җиргә карарга белмисең. Берсенә күз салсаң, шунда ук икенчесен күрәсең килә. Хан капкасына якынлашканнан-якынлаша барасың. Ул арада курчак кебек бизәлгән атларга менгән хан сакчылары килеп, илгизәрләрдән сораша башлыйлар. Һәрбер сүзгә, сораган нәрсәгә бик түбәнчелек белән елмаеп кына җавап кайтаралар. Кирәк булган киңәшләрне бирәләр. Аларның ефәк кынга салган, чын ташлар утыртып бизәкләгән көмеш саплы ук-җәяләре, кылыч сөңгеләре кояшка каршы күз чагылдырырлык булып ялтырап торалар, әйтерсең лә бу сакчылар хан балалары!

Ул арада кичә юлда килеп кушылган ханның юлчабары, ук кебек килеп чыга да, үзенә кунак итәргә алып китә. Шуннан тагы сулышың киңәеп китә. Үз иленә, үз йортыңа килеп кергән төсле буласың.

Юлчабар да сине үз туганы кебек итеп каршы ала, аш-су бирә, кирәк нәрсәләрнең һәммәсен үзе башкара, юлбашчы була.

Аның ярдәме аркасында Алтын кала белән дә чынлап танышасың, ханнар ханы булган Алмасның йортында алтын аяклардан[1] кымыз татыйсың. Болгар

---

[1] *Аяк* — савыт (*Ш.Әхмәдиев*).

иле, Алмас хан, Алтын кала тугрысында ни әйтәсең инде!

Шул сүзләр белән илгизәр сүзен бетерә дә, иркенләп тын алып, калганын икенче вакыт сөйләргә калдыра. Икенче вакыт сөйли дә өченче вакытка калдыра. Аннары дүртенчегә, аннары бишенчегә калдыра. Иң ахырдан һаман да шул сөйләп бетерә алмыйча: «Әле мин өстән-өстән генә сөйләп, аның очына чыга алмыйм. Әгәр чынлап керешсәң ие!» — ди.

Дөресе дә шулай бит. Болгар иле бай, чөнки аның яхшы җирләрендә төрле иген, җимеш чәчелә. Шәһәр халкы һөнәргә, эшкә күмелгән. Нинди генә булса да яңалыклар шул һөнәрчеләрдән чыга. Эшләгән нәрсәләр[1] бик күп булып, Болгар иленең үз хәләтеннән артып калганга, матур, нәфис итеп ясалган әйберләр чит илләргә дә чыгарылалар. Болгар нәрсәләре чит ил базарларында атаклы, һәркемгә охшаулы нәрсәләр булып танылалар. Шуның өчен дә Болгар сәүдәгәрләре кояш чыгыш, кояш батыш, төшлек һәм төньягындагы чит илләр, чит патшалар белән алыш-биреш кылалар. Алтын кала сәүдәсе бөтен дөньяга таралып, зур исем ала. Кая гына барсалар да, Болгар сәүдәгәрләре зур ихтирам, дустлык белән каршы алыналар.

Алмас хан шул бай илен бик яхшы идарә кыла. Үз кулы астындагы барлык халыкка бер күз белән карый, һәммә җирдә үзенең тугры, дөрес хөкемен йөртә. Алмас үзе дә бик бай, комсыз күзле чит ил патшалары аның байлыгына бик кызыгалар. Тик гайрәтле, батыр болгарлар читләрнең өмидләрен мәйданга чыгартмыйлар.

Алмас ханның бәхетендә бер кимчелек булса, ул да иркәк баласы булмавы иде. Ул аның өчен бер бәхет-

[1] *Нәрсә* — әйбер.

сезлек булган кебек, Болгар илен дә бик борчый. Безнең тыныч, рәхәт, олуг Болгар иленә изге атабыз Алмастан соң кем генә менеп утырыр инде? дигән уй һәрвакыт искә төшерелә иде. Алмас хан угыл теләвенә багышлап, нинди туйлар кылмады, нинди укымышлы галимнәргә киңәш белән мөрәҗәгать итмәде, алай да булмагач, сихерчеләр, им-томчылар киңәшләренә дә колак салды, ләкин ни генә эшләсә дә, эш файдага ашмады, иркәк бала тумады.

Ул ничә хатын, ничә җария-кәнизәкләр алды. Һаман да бала тумады. Тик аның Гөлбикә атлы кызы гына булды. Аны үзенең яраткан һәм бик гыйбадәтче хатыны Ахак тудырды. Гөлбикәне тудыргач, Ахак хан хатыннары һәм кәнизәкләренең ханбикәләре дәрәҗәсенә мендерелде һәм һәрберсе аңар буйсынган төсле булдылар. Алмас хан Ахакны аерым иркәләргә тотынды. Ахак үзе бик сабыр, мөлаем табигатьле юаш кына һәм теләүдән армый торган сөйкемле генә Болгар кызы иде.

Гөлбикә бер кыз булса да, илдә бер булды, чын хан кызы булды. Аның матурлыкта тиңдәше һәм охшашы бөтен Болгар илендә булмады. Ул алтын бишегендә ефәк биләүләрдә кара күзләрен беренче мәртәбә ачып җибәргәндә үк, илдә бер матур кыз булачагын белгерткән иде. Шуның өчен дә күз тимәсен, дип, Гөлбикә беркемгә дә күрсәтелми, тик үз анасы, сөт анасы һәм караучы хадимәләр генә аңар курка-курка гына карыйлар иде. Алмас хан үзе дә Гөлбикәнең күзләренә туры карарга шикләнеп, аның маңгаеннан гына сөеп китә иде.

Матур Гөлбикәсе бармаклары белән атасының сакалларына кагылып, сөенеп торганда, Алмас хан балавыз кебек эри иде.

Гөлбикәнең үсүендәге һәрбер үзгәреше зур шатлык белән каршы алына иде. Аның беренче мәртәбә елмаюына багышланып, Алтын калада зур бәйрәм

ителде, шәһәрнең читендәге Изге түбәгә барып, теләү ясалды. Аннан Киң угълан тугаена барып, аш бирелде, кымыз эчелде, атлар чабыштыру, көрәштерү, җыр әйтү, курай уйнау, думбра чиртүләр булды.

Гөлбикәнең үз алдына утыра башлавы тагы шулай каршы алынды һәм аның «әттә, әннә»ләрне әйтә башлавы һәм беренче тешенең күренүе, аякка басып йөрергә тотынуы — барысы-барысы зур шәүкәтле туйлар, теләүләр белән каршы алынды.

Алмас ханның үскән саен Гөлбикәгә мәхәббәте арта гына бара иде. Гөлбикә һәрвакыт караучы хадимәләр белән уралып тора иде. Төнен дә яныннан китмичә, күзен йоммыйча аның тыныч йокысы күзәтелә иде. Көндезен дә шулай ук иде. Тик көндез ул күбрәк үз анасы һәм яшь аналары, сарай хатыннары кулыннан төшми, берөзлексез сөелә иде. Шулай Алмас хан йортында иң зур юаныч Гөлбикә булды.

Алмас ханның бер хатыны, бер кәнизәге дә мәхәббәтле анасы Ахактан көнләшми, тик нәүбәт җиткәндә аны күбрәк сөеп һәм иркәләп кенә калырга тырыша иде. Гөлбикә дә аларның берсен дә чит күрми, бөтен аналарын һәм хадимәләрне үз анасы кебек якын күрә иде.

Гөлбикә шат күңелле чакта, бөтен сарай шат рухлы була иде. Әгәр ул аз гына борчыла, кәефсезләнә башласа, аны караучылар кайгылана, чыдый алмыйча чәчләрен, толымнарын йолкып, егъларга тотыналар, бөтен йорт эче кайгыга бата.

Тиз үк илнең даручылары, имчеләре чакырыла, барлык җирдә теләүләр башлана, аның кәефе яхшылангач, тагы бәйрәм итеmenu, шатлык туйлары ясала иде.

Алмас ханның кызына мәхәббәте искиткеч иде. Аны үзенең алтын тәхетеннән, Алтын каласыннан артык сөя, бервакытта да аңардан аерылмаска тырыша, бер көнлек юл читкә, үз илен карарга чыкса да, аны үз яныннан калдырмый иде. Гөлбикә өчен үзенә башка, ике

тәгәрмәчле, курчак кебек итеп бизәгән арба ясаткан иде. Юлга чыкканда уңган, булдыклы хадимәләр Гөлбикәнең өстенә күләгә дә төшермиләр иде.

Гөлбикә үсте. Үскән саен матурая гына барды. Сигез-тугыз яшьләренә җиткәндә, аның көлтә кебек бөдрә кара чәче, бөтен аркасын каплап, биленнән үтә иде. Аның озын керфекләре һәм кара күзләренә үз атасы, анасы да текәп карый алмыйлар иде. Аның кызыл җиләк кебек пешеп торган иреннәре, балкып торган яңакларын күрергә, сөяргә муаффәкъ булган[1] сарай әһеле[2] үзен дөньяда бәхетле саный иде. Аның йөзенә илаһи серле нур сипкән кебек иде. Нинди үткен күзле күз дә аңар күтәрелеп карауга җиңелә, хәлсезләнә, караңгыдан кояшка каршы чыккан кебек була иде. Шуңа күрә илдә Гөлбикә тугрысында ул тәңреләрдән дөньяга килгән бала, имеш, дигән сүз дә бар иде.

Кеше-караның яман күзе тимәсен өчен, Гөлбикәнең матурлыгын нинди куәт белән булса да яшерергә һәм аны үзен читләргә күрсәтмәскә тырышыла иде. Алай да булса, аның матурлыгы бишегендә, ефәк төргәгендә чакта ук илнең бөтен җиренә таралды: җырчылар, уенчылар илнең иң читендәге, ерак җирләрендәге яланнарга, сәхрәләргә кадәр Гөлбикәне мактарга, күккә күтәрергә тотындылар һәм туйларда, уеннарда җырлану өчен ул яңа азык булды.

Кайсыбер үләнчеләр[3] мактауның чигеннән үтеп:

— Нинди теләүләр булса да, Алмас ханның баласы булмады. Инде Тәңре ханбикә итеп үз баласы Гөлбикәне багышлады,— дип җырлыйлар һәм Гөлбикәне Тәңре баласы[4] дип уйлыйлар иде.

---

[1] *Муаффәкъ булган* — ирешә алган.
[2] *Әһеле* — кешесе.
[3] *Үләнче* — җырчы.
[4] Болгарлар электә тәңреләрнең баласы булырга мөмкин, дип уйлаганнар (*Ш.Әхмәдиев*).

Матур кызы Гөлбикә Алмас ханның зур шатлыгы һәм юанычы булды. Ул аны кулына алып сөйгән чакта үзе дә бер гөнаһсыз балага әйләнә, үзенең Алмас патша икәнен бөтенләй оныта иде. Уенчык әйберләр урынына Гөлбикә алтын тәңкәләр очырта башлавын сизмичә дә кала иде.

Аны бер күргән кеше озакка кадәр аның сурәтен күңеленнән чыгара алмый иде. Инде онытты дигәндә, Гөлбикәнең талчыбыгы кебек матур, нәфис сыны, балкып торган йөзе, матур күзләре, дулкынланып торган чәчләре алдына килеп баса, шуннан соң ирексез: «Бу чыннан да Тәңре кызы булырга кирәк»,— дип уйлый иде.

Гөлбикә киенергә бик һәвәс, үзенә нинди кием килешкәнен бик сайлый белә иде. Аның башында мирза Угъланбәк кызларыныкына охшамаган, ак каурсыннар утыртып, чын ташлар белән бизәп бетергән калпак, аягында энҗе ташлар утырткан башмак, өстендә күбрәк вакыт алтын камәр[1] белән җиңел генә кыскан ал яисә саргылт ефәк күлмәк була иде.

Бу матур киемнәр Гөлбикәгә әләккәч, шундый матурлык туа иде. Гөлбикә ул әйберләрне матур итте микән, әллә алар Гөлбикәгә артыграк матурлык бирә алдылар микән? дигән уй үзеннән-үзе күңелгә килә иде.

Алмас хан да кызының киемне, бизәнүне сөйгәнен белгәнгә, кая гына, нинди генә җиргә барса да, күз төшәрлек матур, кыйбатлы нәрсәләрне аңар алып кайта, яисә аның үз кушуы буенча ала иде. Алмас ханга артыграк ярарга тырышкан чит йортлар белән алыш-биреш кылучы зур Болгар байлары башка патшалыкларда бер аерым ят, матур җиһаз әйбере күрсәләр, Гөлбикәгә багышлап алып кайталар һәм

[1] *Камәр* — билбау, пута.

ханны бүләклиләр иде. Бигрәк тә Багдад иле белән эш итә торган Тукбай мирзаның бүләкләре матур хан кызының күңеленә охшыйлар иде. Кайсы вакыт ул үзе Тукбайдан Багдад илен, андагы сарайларны, хан кызларын сораша иде. Тукбай исә оста итеп бар белгәнен бик тәмләп сөйли иде.

Гөлбикә уналты яшьләргә җитә. Атасы Алмас хан үзенең сакалындагы ак төкләре, маңгаендагы җыерчыклары арткан саен, Болгар иленең язмышы, Алтын каланың бәхете хакында уйлый, ләкин Гөлбикә үзе киләчәк белән баш ватмый, тик алтын, ефәк эчендә, ата-анасының һәм бөтен сарайның иркәсе булып, матур, күңелле көннәр генә уткәрә. Кайсы чакта үз тирәсенә Алтын каладагы угълан бәкләрнең кызларын җыеп, төрле кызыклар, тамашалар, уеннар, яисә илдәге атаклы җырчылар, уенчыларны чакыра. Кайсы чакта, бигрәк тә яз, җәйнең матур көннәрендә дус кызлары һәм бүз балалары белән бергә яшел үлән белән капланган зур тугайларда, Кара Идел буйларында туй уйнала.

Каладан читкә чыгарга булса, аның өчен иң ышанычлы һәм яхшы коралланган батыр сакчылар җибәрелә. Хадимәләргә генә ышанмаганга, әнкәсе Ахак та алардан калмый.

Гөлбикә үзенең сөйгән Ак юргасына атлана, аның юргасы уртача гәүдәле, көлтә койрыклы, зур матур күзле, киң маңгайлы, юаш кына ак бия. Гөлбикәгә кирәкмәгән көнне ул Кара Идел буенда, хан болынында утлап йөри, иркенлектә йөзә. Хан кызына кирәк көнне алып кайталар да берничә сәгатьләр аны бәйләп тоталар, бик һәйбәтләп юалар, койрыгын, ялын, маңгай чәчен үреп-тугып, мең төрле нәрсә белән бизәп, чубарлап бетерәләр. Алтын авызлыклы йөгән, алтын өзәнгеле һәм чын ташлар белән бизәлгән кызыл хәтфә ияр, киң ефәк күкрәкчә һәм билдәмәләр аның беренче зиннәтләре.

Гөлбикәнең чыккан җиренә бер кеше аның башыннан тотып, икенчеләре аны күтәреп атландырырга көтеп торалар. Сакчылар әллә кайчан аны көтәләр, аның чыгуына җирдән тупрак алып сәҗдә кылырга[1] хәзер торалар.

Гөлбикә, кыска гына көмешләнгән саплы камчыны уң кулына алып, тезгенне кулына алуга Ак юрга «Хан кызы матур Гөлбикәне кайда боерасыз?» дигән төсле, колакларын торгызып, башын җиңел генә бутап ала да юргаларга тотына, тезгенне катылаткан саен ул юргалавын көчәйтә бара. Гөлбикәнең «алтыным» дип тезгенне бушатуы белән Ак юрга туктарга җыена.

Гөлбикә курчак кебек матур Ак юргасы һәм озын каурсынлы камчат бүреге белән йөзләрчә кызлар арасында йөзек кашы кебек аерылып тора. Ул ат менеп йөрергә бик оста. Аның Ак юргасы үз гомерендә абыну-сөрлегүне дә белми. Шулай булса да, аның кызык ачарга чыгуы сарайга бер тынычсызлык сала. Алмас хан һәм ханбикәләр: «Әллә нинди гөнаһы шомлыгы туры килеп, Гөлбикә егылып төшеп имгәнә күрмәсен»,— дип теләктә генә торалар иде.

## II

... елда яз көне Гөлбикәгә унҗиде тулып, унсигезгә китте. Бу ел исәп-сынау буенча тыныч, матур, бай ел булырга кирәк иде, чөнки ул Куян елы дип атала иде. Ләкин алай булмады. Апрель үтте, май үтте, һәркөн диярлек җил-давыл. Аз гына көннәр ачылган була да, тагын көтмәгән җирдән кара болытлар чыгып, шәйтан туйлары, өермәләр күтәрелеп, җир йөзе коточкыч хәлгә әйләнә.

Сабан ашлыгын боз сугып китә, ул гына аз, илнең төрле җирләрендә үләт авыруы чыгып, кешеләр үлә,

[1] *Сәҗдә кылу* — табыну, олылау.

көтүләрдә терлекләр кырыла. Иң куркынычы болар түгел, бөтен ил үз кайгысы белән көрәшкәндә, ата угылыннан, бала атасыннан аерылган вакытта урыс кнәзе Болгар иленә сугыш-яу белән килә дигән хәбәр тарала. Ил тагын да зур кайгыга төшә. Болгар илендә үләт авыруының барлыгы гына урыс кнәзенең гайрәтен бастыра. Аны әүвәлге уеннан кайтара. Шулай булса да, Алмас хан бөтен рәхәтен ташлап, бердән, халыкның хәлен яхшыртырга, икенчедән, урыс чигенә көчле гаскәр җибәрергә тырыша.

Болгар иленең зур ышанычы Алмас хан гына: «Тук булырбыз, кызык яшәрбез, тик Тәңребез хан йортына саулык бирсен»,— ди. Ни эшләргә дә чара тапмагач, Алмас хан Алтын каланың бөтен халкын һәм илнең аксакалларын, укымышлыларын чакырып, хан тугаендагы Изге түбәгә чыгып, бик зур теләү ясый. Ничә меңнәр корбан чала. Бөтен көн буена барлык кеше шул җирдә гыйбадәт, догалар кылалар. Шуннан соң көннәр бераз матураеп, үлеләр азаеп торган төсле була. Ләкин озакка түгел, тагын һавалар начарланып, кеше, терлекләр үлүе күбәеп китә.

Алмас хан үзеннән бигрәк, Гөлбикәнең күңелсез язмышка очрамавын тели. Әлегә сарайда үзгәреш юк.

Бер дә беркөнне илнең иң зур руханиларыннан булган, бар гомерен гыйбадәттә, теләүдә үткәргән карт Изге ата шулай хәбәр бирә:

— Олуг ханымыз Алмас, синең Изге түбәгә чыгып, кызың Ханбикә тәңреләргә багышлап, теләү кылырга тиеш...— ди.

— Йә Тәңренең яраткан колы, илнең Изге атасы, минем үземнән сөекле балама тәңреләр өчен нәрсә чалырга кушасыз?

— Ханнарның ханы! Мин үзем өчен әйтмим, сине дә, илне дә ул гына коткара алачактыр. Гөлбикәнең Ак юргасын... тәңреләргә багышлап, шул Ак юрга чалынырга кирәк.

— Ак юрга Гөлбикәнең иң яраткан, иң сөйгән аты, аны чалдыру минем өчен кечкенә йомыш түгел. Изге ата, шулай да минем бер көтү малым шул Ак юрганы алмаштыра алмасмы икән?

— Юк, чалган җирдә Гөлбикә үзе дә булырга кирәк.

— Ул минем сүземне тыңлар. Шулай да аңар бик авыр булыр...

— Итен, тиресен нишләргә боерасыз?

— Ите шунда пешерелсен, Гөлбикә дә авыз итсен, ләкин тиресен юлда беренче күренүчеләргә аның үз кулы белән бирелсен, шулай дим, ул үзе тапшырсын.

Алмас хан, Гөлбикәсен янына чакырып, мәсьәлә хакында сөйли, кызының разый булачагын белгәч, бик шатлана.

— Балакаем, үзеңнең илең бит, барыбер үз кешеләрең, аларны коткару синең кулыңда. Инде шул авырлыкны өстеңә алып куандырасың, юкса...

— Сөекле атакай, мең Ак юргам булса, барысын да тәңреләргә багышлыйм, тик үземнең анда булуым гына бик читен, шулай да булырмын инде. Миңа барырга кирәк, дисең бит.

— Әйе, син калмаска тиеш, Изге ата шулай диде.

Аталган көнне Алмас хан һәм ханбикәләрнең һәммәсе дә, Гөлбикә белән бергә, Изге түбәгә чыгалар. Алтын каланың изге аталары, галимнәре, олуглары да чакырылалар. Ак юрганы җитәкләп киләләр. Алмас хан: «Нинди үзгәреш булыр икән»,— дип, әледән-әле кызының йөзенә карап ала. Гөлбикә, атасының, ханбикәләрнең кайгырачакларын белеп, бер дә йөзен бозмаска, шат булырга тырыша, тик артык мәртәбә Ак юргасының башыннан сөеп кала. Ни кушсалар, ул шуны кыла. Үзенә авыр булса да, бернәрсәдән дә баш тартмый.

Теләүләр була. Ак юрганың ите ашала. Инде тирене бирү өчен генә юлдан беренче килеп чыккан

кешеләрне көтәләр. Ул арада булмый, тугай буйлап салмак кына йөгертеп килгән берничә ат менгән кеше күренә. Ханның юлчабары ук кебек атыла да, ул юлчыларга каршы китә. Шунда ук әйләнеп килә дә юлчыларның Болгар кешеләре түгеллеге, чит илгизәрләр икәненнән хәбәр бирә. «Чит ил кешеләренә дә тирене бирергә ярыймы?» — ди Алмас хан.

— Бигрәк тә яхшы,— ди Изге ата.

Ул арада атка атланган ике илгизәр Изге түбәгә якынаялар. Болар Багдад иленнән килүче ике гарәп. Алар ханның кушуы буенча Изге түбәгә борылалар. Ерак ук җирдә атлардан төшеп, Хан янына җәяү киләләр. Якын ук килгәч, күкрәкләренә кулларын куеп, аз гына иелеп, Ханга сәлам бирәләр. Хан, башын иеп, аларга сәлам кайтара. Гарәп теле белүче Тукбай тылмач була. Гарәпләрнең башларында сөт кебек ак чалма, өсләрендә киң кара җөббәләр. Иярләрендә таккан каеш, чемоданнан башка бернәрсәләре дә юк.

Гарәпләрнең берсе Габдрахман, урта гына буйлы, ябык кына йөзле, кап-кара чәчле, кара кашлы, кара мыеклы кырык яшьләрдәге кеше. Иптәше Габдулла киң маңгайлы, зур шомырт кара күзле, кылыч борынлы, кара-тутлы, төз сынлы, гаять тә матур, егерме биш яшьлек егет. Хан боларның нишләп йөрүләрен Тукбайдан сората. Гарәпләр үзләренең тик Болгар илен, атаклы Алтын каланы, бигрәк Алмас ханны күрер өчен килгәнлекләрен сөйлиләр. Тукбай аларга Болгар иленең кай җирендә дә тыныч икәнен һәм үзенең гарәпләргә-мөселманнарга мәхәббәте зурлыгын аңлата. Гөлбикә дә күзенең кырыйлары белән генә аларны карап куйгалый. Ул үз кулы белән Ак юрганың тиресен биргәндә, тагы да матур егет Габдуллага бер мәртәбә күтәрелеп карый. Аның күңелендә «Нинди матур бүз бала» дигән уй яшен кебек ялтырап китә.

Шуннан соң гарәпләр, Алмас ханга һәм ханбикәләргә зур ихтирам күрсәтеп, Алтын калага юнәләләр. Тукбай мирза аларны кунакка чакырып кала.

Гарәпләрнең берсе бераз гына китүгә, Гөлбикәнең матурлыгына исе китеп: «Мәләк әл-раз»[1],— ди, икенчесе: «Хур әл-җәннәт»[2],— дип куя. Алмас ханның шундый садә мөгамәләсенә аларның исләре китә.

Теләү бетә. Алмас хан үзенең бикәләре белән сарайга кайтып китә. Вакыт кич булып бара, көн болытлы, кояшның барлыгы аз гына беленә.

Изге атаның әйтүе буенча эшләнгән Гөлбикә корбаныннан соң, көннәрнең яхшыруын, илдәге үлемнең, авыруларның кимүен һәркем чын ышаныч белән көтәргә керешә. Ләкин һичбер нәрсә җайга бармый. Ул гынамы, көтмәгәндә ачы кайгы сарайны чолгап ала. Теләүнең икенче көнендә Гөлбикә иртән вакытсыз уяна. Аның күз ачканын көтеп торган караучылар ни эшләргә белмиләр, куркуларыннан җаннары тәннәренә сыймый, йөзләренә үлек төсе керә. Гөлбикә эндәшми, тик күкрәгенә кадәр ал ефәк юрганын ачып, озын керфекле, чем-кара күзләре белән моң гына карап тора. Бу хәбәр Алмас хан, Ахак, ханбикәләр һәм бөтен сарайга яшен суккан кебек тәэсир итә. Алмас ханга инде бигрәк тә. Ул кызының түшәге янына килә, һичкемгә карамыйча, күзләрен бер җиргә тегәп торган Гөлбикәнең башын кулына ала да, чәченнән, маңгаеннан сөеп: «Балакаем, ни булды сиңа?» — ди. Башка бер сүз дә әйтә алмый.

— Атакаем, авырыйм, шулай да көчем юк... Тик кенә ятасым килә. Әйт, мине борчымасыннар,— ди Гөлбикә. Шунда ук бар кеше юк була. Тик атасы белән анасы Ахак кына калалар. Болар да сөйләш-

---

[1] *Мәләк әл-раз* — җир фәрештәсе (*Ш.Әхмәдиев*).
[2] *Хур әл-җәннәт* — оҗмах хуры (*Ш.Әхмәдиев*).

миләр. Тик бер-берсенә күңелсез генә карашып алалар. «Әгәр илдәге авыру ирешкән булса!» дигән агулы уй аларны борчый башлый. Хәзер үк бөтен даручылар, имчеләр чакырылалар. Хан кызына ни булганны сорый, ләкин болар ни әйтергә дә куркалар.

Бу хәбәр сарайдан чыгып, Алтын калага да таралып җитә. Бөтен кеше кайгыра, ил әрни, бу бәхетсезлекнең сәбәбен төшенә алмый. Халык Ак юрганы чалдырырга кушкан Изге атаны шелтәләргә тотына, ләкин Изге ата кайгырмый. «Болыт артында кояш бар, төн артында көн бар»,— ди. Ул Алмас ханга да кайгырмаска куша. «Тәңреләр безне сыныйлар, чөнки күбрәк рәхәт бирергә телиләр, чыдыйк!» — ди.

Көннәр, төннәр үтә. Гөлбикәнең кәефе төзәлми. Аның балкып торган ал йөзе, өзелгән чәчәк кебек сулыга, үзе авырая гына бара. Дарулар, киңәшләр ярдәм итмәгәч, каланың бөтен руханилары җыелып, сарай каршына киләләр һәм Гөлбикәгә багышлап яңадан теләү ясарга Изге түбәгә чыгып китәләр.

Изге түбәдә җиде ак дөя, җиде ак ат, җиде ак куй, җиде ак кәҗә, җиде сыер корбан чалалар. Ләкин авыруга шифа булмый.

Алмас ханның көннән-көн өмиде ераклашып, кайгысы чамадан аша. «Болгар иле, Алтын кала, минем тәхетем кем кулына калыр... үземнең картлыгым җитеп бара»,— ди. Ахак гыйбадәттән туктамый.

Сарай хатын-кызлары кайгыларыннан чәчләрен йолкып елыйлар. Дарудан дару, имнән им, теләүдән теләү калмагач, Алмас хан бөтен илгә: «Гөлбикәне савыктырган, исәнләндергән кеше минем киявем була!» — дип игълан кыла.

Ханның «Кем кызымны терелтсә, шул минем киявем булачак» дигән хәбәре көне-сәгате белән бөтен Болгар иленә таралып җитә. Анда гына калмый, чит җирләр, чит патшалыкларга да барып ирешә, тик бу

хәбәр Гөлбикәнең үзеннән генә яшерен тотыла, һичкемгә аның белән ул хакта сөйләргә ирек бирелми.

Илдәге тынычсызлык, кайгы-хәсрәт бер якта кала. Һәркемнең күңелендә, һәркемнең авызында: ханнар ханы булган Алмасның Гөлбикәсе, Тәңре кызы, кемнең бикәсе булыр, нинди белекле, нинди сөйгән кеше аның кызын терелтер... Искиткеч эш! Аның кияве безнең ханыбыз булачак, кем генә булыр соң? Әгәр Болгар кешесе булмаса, бер чит илнең хакиме булса ни була? Алмас хан җирнең асты-өскә килсә дә, ике сөйли торган кеше түгел. Ул тугры кеше, ул изге ханыбыз, аның сүзе бер генә: әйтте, бетте. Тәңреләргә мең теләк, тәңреләргә мең-мең теләк булыр иде, әгәр Болгар иленнән бер белекле бүз бала чыгып, Гөлбикәгә юлдаш булса...

Бу елгы кайгылар изде, тагын-тагын ниләр генә булыр инде. «Ах, ата-бабаларыбыз күрмәгән уттан чыккан Куян елы!» диләр иде. Илнең яшь егетләре, яшь кызлары көннәр-төннәр буена Гөлбикәнең булачак кияве хакында сөйлиләр, шул турыда җырлыйлар, думбралар чиртәләр. Атаклы җырчылар үзләренең җырларында бик матур, белекле Болгар егетен генә кияү итеп күрсәтәләр. Кайсылары аңа тиңдәш таба алмыйча, Гөлбикәгә тәңреләр үзләре кеше җибәрерләр, ул терелтер, ул каканыбызның[1] кияве булыр. Ул Алтын каланың да ханы булыр, диләр иде.

Яшьләр шулай җиңел генә уйласалар да, картлар, илнең аталары Болгар иленең киләчәк көннәре, язмышы хакында төплерәк уйлыйлар, баш ваталар. Җаннан артык Алмас ханыбыз да бу ут чыккан эшләр белән чәчләре агарып бетә инде, безгә ни сан, ул булып ул олуг кайгылар чигә, теләүдән теләү калмады,

---

[1] «Хан» дигән сүзне электә «какан», «каган» рәвешендә дә сөйләгәннәр (*Ш.Әхмәдиев*).

Гөлбикәнең иң сөекле юргасы да тәңреләргә багышланды. Бер үзгәреш юк. Әле боз, әле җил-давыл, ә тегендә кеше үлә, монда терлекләр кырыла. Гөлбикә, балакай, көннән-көн начарая бара. Йә инде, без бөтен йорт гөнаһлы икәнбез, аның ни гөнаһсы бар, дип, маңгайларын җыерып, авыр сулап куялар иде.

## III

Алмас ханның бөтен рәхәте, тынычлыгы бетә. Һәрвакыт Алтын каланың олуглары, илнең би башлыклары белән киңәшә, үләт булган җирләрдән кешеләрне башка җирләргә күчерттерми, ул яктан терлекләр кудыртылмый. Базар ясатмый. Һәр ел Алтын калада була торган бөтен дөньяның атаклы Болгар ярминкәсе дә кичектерелә, җыелып-җыелып теләүләр ясау, Изге түбәгә чыгулар да туктатыла. Алмас хан сараена читтән кеше китерелми һәм аннан тышка чыгарылмый, чыгарылса, яңадан җибәрелми. Үләт авыруын Алтын калага, бигрәк тә Алмас хан йортына кертмәс өчен төрле чаралар кылына. Элек Гөлбикәнең авыруы да шул ил авыруы дип куркылса да, озакка киткәч, үләт галәмәтләре дә булмагач, анарда башка авыру дип табыла. Шулай да Алмасның күп вакыты кызы янында үтә. Аны иркәли, юата, сөя. Терелсә, әллә нәрсә, нәрсәләр бирергә, ясарга вәгъдәләр бирә. Бер дә беркөнне иртән Алмас кызы янына керә. Көндәгечә, ул элек кызының маңгаеннан сөя. Аннан соң нечкә, хәлсез бармакларын үбеп, аның хәлен сораша башлый. Гөлбикә озын керфекләрен авыр гына күтәреп, чем-кара матур күзләре белән елмаеп кына атасына карый. Алмас шатлыгыннан балавыз кебек эреп китә. Ул тагын кызының йоп-йомшак, хәлсез бармакларын, ак беләкләрен сөя. «Балакай, ни әйтергә уйлыйсың, әйт, мең алтын үксезләргә булсын»,— ди.

Гөлбикә атасының киң маңгаена, җан елымлы күзләренә, чал сакалына, шатлык тулган йөзенә бер карый да нәрсәдер әйтергә тора. Алмас сүзләрен йотарга торган төсле булып кызына карый. Аның янына гына утыра.

— Атакай, мин сиңа бер төш сөйлимме? Син анакайларга да сөйләрсең,— ди Гөлбикә.

— Сөйлә, сөйлә, йөрәгем, сөйлә. Тәңреләргә мең теләк, сөйлә,— ди Алмас, үзе кызының кулларын җибәрмичә сөя.

— Атакай, син бүген миңа бик матур бүрек — калпак алып кайттың. Мин Ак юргам белән йөреп, өйгә кереп, тын алып тора идем. Анакай да шунда, имеш. Син минем башыма кидердең. Андый бүрекне мин беренче тапкыр күрәм әле. Аны сиңа Багдад иленнән Тукбай мирза алып кайткан, имеш. Ул бик матур иде, башка кия торган җире кулясуы чикле түгәрәк, эче ал ефәккә бетергән. Тышы сөт күк ак. Маңгае турысында ут күк яна торган кашы бар. Аның өстендә бизәкле-бизәкле киң озын каурсыннар бар. Бүрекнең өсте кызыл ефәккә бетереп, иң очта сары алтын чугы бар иде. Уянып китсәм — юк. Әле сине күргәч, шул төшем күңелемә килде.

— Балакаем, бәгырькәем, төшең бик матур, терелерсең. Исән булсаң, ул бүрекләрең булыр.

— Атакай, авыруым алга китми шул, төне буе сыкранып чыгам, үзең беләсең.

— Әйтмә инде, балакай, беләм дә ни генә эшлим соң? Мең баш төя, мең баш елкы[1] тәңреләргә teләү булсыннар.

Шуннан соң Гөлбикә, күзләрен төшереп, тагын хәлсезләнеп китә. Ул арада әнкәсе Ахак, Алмас каршына килеп, кызының сул ягына тора, аның йөзе

---

[1] *Елкы* — ат.

сулган, күзләре эчкә батып, үзенә бер төрле моң белән өметсез булып карыйлар. Аның өстендә садә генә күлмәк, башында ияк астыннан бәйләнгән ак яулык.

— Атасы, күптәнме, күзен ачканы бармы? — ди Ахак.

— Әле ул миңа төшен сөйләде, анасы, төше матур, имеш, мин аңар бик матур калпак алып кайткан-мын, имеш, ул калпакны Тукбай Багдад иленнән алып кайткан, терелергә булсын, тәңреләрнең иркендә бит,— ди Алмас.

— Балакай, балакай, терелсәң икән дә шул матур калпакларны киеп, барыбызны да ут әрнүеннән коткарсаң икән. Атасы, ул исән чагында да Тукбай бүләген ярата иде,— ди Ахак һәм кызының мендәр өстенә салган кулын алып үбә. Гөлбикә яңадан күзләрен ачып җибәрә.

## IV

Тукбай мирза Болгар иленең иң зур байларыннан. Ул гарәп, Византия[1] илләре белән бик яхшы алыш-биреш кыла. Болгар товарларын Багдад илләренә, Истанбулларга җибәрә. Аннан үз иленә төяп кайта. Аның бер баласы да юк, тик бер хатыны гына бар. Ул чиксез күркәм холыклы, гакыллы, тугры сүзле кеше. Алмас хан да аны ярата, үзенең иң ышанычлы, олуг киңәшчеләреннән саный.

Тукбай гарәп иле һәм мөселман дөньясы белән бик яхшы таныш. Аларның диннәре нәрсәдән гыйбарәт икәнен яхшылап аңлый. Мөселман дөньясындагы бер Аллага ышану һәм аңар кылынган пакь гыйбадәтләр, манаралары күккә калкып торган матур мәсҗедләр көннән-көн аның күңелен йомшарталар, көннән-көн

[1] *Византия* — грек, Юнан иле. Ул чактагы Истанбул яклары (*Ш.Әхмәдиев*).

ислам диненә мәхәббәтен арттыралар. Болгар илендәге төрле тәңреләргә ышанулар, аларга кылган теләүләр ислам дине белән үлчәп карагач бик түбән, бик кызыксыз булып калалар. Ул гарәп телен яхшы белгәнгә, Коръән хәдисләрдәге[1] чын, тугры сүзләрне дә аңлый. Ислам галимнәренең сүзләренә, киңәшләренә дә колак сала. Шулай итеп, аның күңелендә акрынлап «Чын Тәңре тик ислам Тәңресе, чын дин дә ислам дине» дигән иман үзеннән-үзе туа. Ләкин ни эшләмәк кирәк? Болгар иле ата-баба динендә. Тукбайның бөтен туганнары, дуслары һәм Алмас хан да шул диндәләр. Ачыктан-ачык динне алмаштырырга мөмкин түгел. Яисә яшерен гыйбадәт кылырга, яисә Болгар илен ташлап, гарәп иленә күчәргә кирәк була. Ләкин ул күчми, яшерен гыйбадәт кылырга уйлый. Ислам динең тоту өчен кирәк нәрсәләрне үгрәнә, үз өенең бер бүлмәсен чиксез матур итеп бизәп гыйбадәтханә (мәсҗед) ясый. Алтынлы айлар куя. Ефәк намазлыклар җәя. Матур итеп чалма урый. Йөзле энҗе тисбесен дә калдырмый. Коенып, тәһарәт алып, ефәк намазлыкны җәеп, киң җөббәне һәм чалманы киеп гыйбадәт кылырга тотынса, ул үзендә әллә нинди рәхәт, шатлык сизә. Гүя чын, олуг теләгенә ирешкән төсле була. Тукбай үзе генә мөселман булып калмый, хатынын да чын дингә күндерә. Шуннан соң икәү гыйбадәт кыла башлыйлар. Ата-баба теләүләренә ничек тә катнашмаска тырышалар. Тик Алмас ханнан һәм якыннардан куркып, өстән генә катышалар. Тукбай чын мөселман булып җитә. Ул инде үзенең тугры юлга кергәненә, изге дингә күчкәненә керсез, шиксез ышана. Бөтен Болгар иле, Алмас ханны шул мөкәтдәс дингә күчерәсе, үзе күк

[1] *Хәдис* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйтеп калдырган кыйммәтле сүзләре. Соңыннан аларны, Мөхәммәднең якыннары җыеп, китаплар итеп бастырып чыгарганнар.

бәхетле итәсе килә. Шуның өчен дә чит илдән килгән мөселманнар Тукбай өендә хөрмәт ителәләр иде. Илгизәр-мосафир мөселманның һәрберсе аның йортыннан аш күрмичә китми иде. Ләкин Тукбай үзенең мөселман икәнен ачык рәвештә алардан яшерә иде, тик үзенең исламга мәхәббәтен генә фаш кыла иде.

Гөлбикә Ак юргасының тиресен алган гарәпләр дә теләү янында Тукбай тарафыннан чакырылганнар иде. Алар да Тукбай йортында ачык йөз белән каршы алындылар.

Алмас ханның: «Кызымны кем терелтсә, шул минем киявем булыр»,— дигән хәбәре гарәп илгизәрләре Габдрахман белән Габдуллага да килеп Тукбай аркылы ирешге.

Бу гарәпләр үз илләренең галимнәреннән һәм яхшы табибларыннан иде. Бу хәбәр ирешүгә алар әллә без Ходайның үзенә тапшырып эшкә керешикме? дип, үзара озак киңәшләрдән соң, фикерләрен Тукбай мирзага әйтергә булдылар.

Тукбай аларның фикерләрен бик шатланып кабул итә һәм вакыт кичектермичә, хәбәрне Алмас ханга ирештерергә сүз бирә. «Әгәр боларның дарулары, киңәшләре Гөлбикәне терелтсә, Алмас ханның кияве мөселман була, бәлки, Алмас хан үзе дә мөселман булыр. Бәлки, бөтен Болгар иле шул изге дингә күчәр... Олуг Тәңрем, бер Аллам, шул мөселманнарга үзең генә ярдәм итсәнә, ярдәм итү синең иркеңдә бит»,— дип, Тукбай үз бүлмәсендә озын-озын гыйбадәт кылганнан соң, Алмас хан сараена юнәлә. Алмас хан белән Ахак Гөлбикә яныннан киткәннәр генә иде, сарай хадимнәре Тукбай мирзаның килүеннән хәбәр бирделәр. Бер сәгать элек кенә сөйләгән Гөлбикә төше Алмас белән Ахак күңелендә матур уй, өмет тудырган иде. Тукбайның килү хәбәре бигрәк тә аларга күңелле тәэсир итә. Тукбай керә,

Хан аны аерым зурлап каршы ала һәм иң дәрәҗәле урынга утырта.

— Ханнарның ханы, изге атабыз Алмас, сезнең колыгыз, аяк астындагы туфрагыгыз, бәхетсез Тукбай мирза бер киңәш белән килгән иде... Беләсез, сезнең кайгыгыз өчен бөтен ил ут йота. Гөлбикә авырый. Аның өчен бөтен ил авырый,— ди Тукбай.

— Тыңлыйк сүзегезне, киңәшегезне әйтегез, Тукбай мирза! — ди Хан.

— Тукбайны кичерегез. Сезнең өчен мең Тукбай Тәңрегә багышлансын. Җир өстендә тиңдәше булмаган Ханыбыз, теләү көнендә Алтын калага ике гарәп килгәне, аларга Ак юрганың тиресе бирелгәне күңелегездән чыкты микән?

— Беләм, хуш!

— Шул илгизәрләр сезне һәм бөтен илне ачы кайгыга төшергән Гөлбикә авыруын бетерергә боерык көтәләр. Кушсагыз, алар үзләренең олуг Тәңреләренә теләү кылып, эшкә тотынырлар.

— Минем ишегем аларга ачык булсын. Безнең тәңреләребездән ярдәм булмады. Изге көндә илгизәрләр эшкә керешсеннәр. Тукбай мирза, аягың җиңел булсын! — ди Алмас хан.

Тукбай мирза китүгә, Ахак, ханбикәләр Алмас ханнан нәрсә барын сорыйлар. Ул ачык йөз белән: «Тукбай мирзаның аягы җиңел булсын!» — ди дә башка бер сүз әйтми.

Тукбай, өенә кайтып, ханның ачык йөз белән зурлап каршы алганын бик шатланып хатынына сөйли һәм гарәпләргә ханның боерыгын әйтә. Гарәпләр бик нык уйга калалар. Бер куркалар, бер шатланалар.

Урманнарга, тугайларга барып, тын җирләрдә бер Аллага гыйбадәт, зарилык кылалар. Төрле чәчәкләрдән Гөлбикәгә дару ясыйлар. Тукбай мирза да аларга ярдәм итешә. Кирәк нәрсәләрне таба, алар өчен дога кыла.

Июньнең урталары. Көннәр кызыксыз, илдәге тынычсызлык арткaннан-арта бара. Көн җомга иде. Аллага гыйбадәт, пәйгамбәребезгә салават[1], изгеләр рухына йөз корбан, фәкыйрьләргә мең алтын нәзер[2] дип, Тукбай белән гарәпләр Алмас хан сараена юнәләләр. Боларны озату белән Тукбайның юмарт, йомшак күңелле хатыны үзенең хадим-хадимәләренә бүләкләр, садакалар тарата. Сәҗдәдән башын күтәрми, гыйбадәт кыла.

Алмас ханның сакчылары Тукбай белән гарәпләрне бик зурлап каршы алалар, бик түбәнчелек белән Хан сараена озаталар. Хан бәйрәм киемендә, гадәттән тыш уларак аягүрә басып чит ил кунакларын һәм Тукбайны каршы ала. Гарәпләр бик түбәнчелек белән Ханга сәлам бирәләр. Тукбай аңар кунакларны тәкъдим кыла. Алмас аларга: «Хуш килдегез, Тәңренең кунаклары, аягыгыз җиңел булсын»,— дип урын күрсәтә. Сарайдагы алтын, ефәккә, чын ташларга беткән матур, кыйммәтле җиһазлар гарәпләрнең күзләрен яндыра. Аларның күңелләрендә ирексез «И Ходаем, синең изге эшләрең шул сарайларда яңгырасалар икән, йа Рабби, безгә ярдәм ит!» дигән уй ирексез кайный башлый.

Авыру Гөлбикәгә гарәпләрнең киләчәге электән үк хәбәр ителә. Алмас хан аның янына гарәпләрне алып керә. Гөлбикә аркасына һәм култык асларына мендәр куйган көйгә утырып, аларны каршы ала.

Габдулла белән Габдрахман аның алдына килеп, тез чүгәләр. Гөлбикә аларга җиңел генә баш ия. Керфекләрен авыр гына күтәреп, кунаклар өстенә карау белән, киң маңгайлы, зур кара күзле, матур йөзле, кып-кызыл иренле егет Габдулла аның күзенә чалы-

---

[1] *Салават* — Мөхәммәд пәйгамбәрне олылый торган дога.

[2] *Нәзер* — алган эшең уңышлы чыксын өчен садака вәгъдә итеп кую.

ып китә. Башындагы кызыл фәскә ураган ак ефәк чалмасы аның йөзен тагын да нурландыра, яктырта төшкән төсле була. Гөлбикәнең йөзенә карау белән җаны ирен очына килгән төсле була. Аны дерелдәү, калтырау ала. Ул бер ут кебек яна, аннан соң кинәт йөзе су сипкән күк өшеп китә. Габдрахман салкын кан белән генә Гөлбикәгә карап тора. Тукбай тын алырга куркып, боларның артыннан Ханның сул ягында басып тора.

— Олуг Ханыбыз, кунаклар сездән бер кечкенә генә чынаяк сорыйлар,— ди Тукбай.

Хан җавап кайтармый. Ни әйткәнен, ни кушканын көтеп торган хадимә ишарә кылу белән чынаяк китереп бирә, гарәпләр алтын савытка утырткан озынча гына кечкенә чынаякка дару салып, Гөлбикәгә бирү өчен Ханга тәкъдим кылалар.

— Тукбай, кунакларга әйт син, алар үз куллары белән кызыма бирсеннәр, куллары җиңел булсын,— ди Алмас хан. Шуннан соң ул кызы Гөлбикәнең янына ук барып:

— Балакай, изге чурда[1] син кунакларның кулыннан шул әйберне эчеп җибәр әле.

Габдрахман бисмилляны ишетерлек итеп әйтә дә Гөлбикәгә даруны тәкъдим итә. Гөлбикә хадимәләрнең ярдәмнәре белән бераз урыныннан калкып, үз алдына гына карап даруны эчә. Шуннан соң гарәпләр үзләренең киңәшләрен әйтәләр. Кирәк даруларын тапшыралар да Хан сараеннан чыгып китәләр. Алар китү белән Ахак һәм башка ханбикәләр Алмас янына килеп җитәләр, сорашалар. Алмас Гөлбикәнең кулын сөя.

— Балакай, килүчеләрдән курыкмадыңмы? Алар бит Багдад иленең кунаклары. Беләсеңме, исеңдәме,

[1] *Чур* — чак, вакыт (*Ш.Әхмәдиев*).

беркөн алар безнең теләүгә килеп җиттеләр. Изге атаңның кушуы буенча син аларга Ак юргаңның тиресен бирдең,— ди Алмас.

— Беләм, атакаем, беләм. Алар Тукбай мирзаның яраннарымы?

— Юк, кунаклары, кунаклары да түгел, тик узгынчы илгизәрләр.

— Атакай, алар тиз китәрләрме? Яңадан киләләрме?

— Нигә, әллә куркасыңмы?

— Юк, курыкмыйм. Болай сорыйм. Кемнәр соң алар?

— Алар сине терелтергә уйлыйлар. Багдад иленең галимнәре бугай.

Ул арада Ахак, Алмаска ишарә кылып, Гөлбикәне күп сөйләтмәскә куша. Гөлбикә йомшарып, тагы хәлсезләнеп китә.

— Атасы, нигә син теләү көннәрен искә төшерәсең. Ул болай да әледән-әле үзенең Ак юргасын сагына, Изге атага ачулана. Барыбер файдага ашмады, нигә инде минем алтыным Ак юрганы тәңреләргә багышлады икән,— ди Ахак.

— Анасы, мин оныткамын, күңелемә дә килмәде, юкса бөтен ил Изге атаны тирги. Барысы да: «Алтын юрга кайгысы Гөлбикәгә төшкәндер, әй Изге ата»,— ди. Әгәр шул турыда Изге атага әйтсәм: «Тәңреләр сине сыныйлар, кыш артыннан җәй бар, төн артыннан көн бар... син чыда, син чыдарга тиеш, илнең мәхәббәте синең кулда...» — ди ул.

— Шулайдыр инде, тәңреләрнең яшерен эшләренә адәм баласы төшенеп җитә алмый торгандыр шул! — диләр ханбикәләр.

Көннәр үтә. Габдрахман белән Габдулла Гөлбикәне дарулыйлар. Бөтен Болгар иле, Алтын кала нинди нәтиҗәләр чыкканын көтеп торалар.

Гөлбикәнең хәле яхшылана икән. Ул хәзер төннәрне тыныч йоклый икән, ашый-эчә башлаган икән

хәбәре тиз үк илнең бөтен почмакларына таралып җитә һәм шулай да бит. Гарәпләр йөри башлау белән Гөлбикәнең сырхавы кими, кәефе яхшылана башлый. Сарайдан кайгы акрынлап күтәрелә. Анда Габдрахман белән Габдуллага гаять тә зур ихтирам күрсәтәләр. Килгәндә, чыкканда алар өстенә чәчәкләр, көмеш һәм алтын тәңкәләр сибәләр. Унҗиде көн дигәндә, Гөлбикә бөтенләй сәламәтләнеп җитә. Аның кеше йөрәгенә ук кебек кадала торган сихерле керфекләре астында чем-кара күзләре тагын ут кебек яна, бит алмалары тагын аллана башлый.

Алмас белән Ахак яңадан дөньяга туган кебек шатланалар, гүя аларның өстеннән авыр кара болыт күтәрелеп, бәхет кояшы чыккан төсле була. Сарайга җан керә, бәйрәм, туйлар башлана. Бер бу гына түгел, кинәттән һавалар яктырып китә, җил-давыл бетә. Елы яңгырлар явып, матур кояшлы көннәр була. Тугайларны, болыннарны яшел үләннәр каплый. Кырлардагы игеннәр терелеп, яңа тамыр җибәреп, яшәреп китәләр. Илнең бар җирендә базарлар, ярминкәләр башлана. Гөлбикәнең сәламәтләнгән хәбәрен ишетеп, илнең бөтен почмакларыннан зур аксакаллары Алмас ханга сәламгә киләләр. Алтын кала, Болгар иле зур кайгылардан котылып, шатлансалар да, Гөлбикәнең тәкъдире һаман да аларны борчый. Нәрсә соң ул? Ул Гөлбикәнең тәкъдире? «Терелтүчегә кызымны бирәм» дигән Алмас хан вәгъдәсе ни булып калачак? Гарәпләрнең берсе Ханның кияве булачакмы?

Алмас хан бу турыда киңәш өчен башлап илнең Изге атасын чакыра. Бу хәбәрне һәркем белә, тик Гөлбикә генә белми.

— Ни әйтәсез, Изге ата? Сез тәңреләрнең яшерен серләрен беләсез, минем сүзем бер: кызым Гөлбикәне гарәпләрнең берсенә бирергә бурычлымын. Аларның тәңреләре тырышты, кызым терелде, үзем терелдем, бөтен ханбикәләрем савыкты. Болгар иле тынычлан-

ды. Беләсең бит, теләүдән теләү калмады, тәңреләребез тик ачуларын гына безгә сиптеләр,— ди Алмас.

— Ханнарның ханы Алмас! Менә якты көннәр килеп җитте, ил мине каргады, Гөлбикә миңа үпкәләде. Менә сиңа шул Ак юрга өчен Олуг тәңре Багдад егетләрен җибәрде. Дөрес, безнең тәңреләр көчсезләр. Төн артыннан якты көн туды. Алмас ханым! Күңелең изге булсын, үзең уйлаганча эш кыл.

— Соң, Изге ата, тагын бер сүзем бар. Алар бит безнең диндә түгелләр. Ил ни әйтер соң?

— Син ханнарның ханы, аларның Тәңресе бөтен тәңреләрнең ханы. Син эшләгән эш бөтен Болгар каласына изге эш.

— Алай булгач, Изге ата, син терелтүче минем киявем булсын,— дип киңәш бирәсең.

— Үзең уйла. Сиңа, миңа, бөтен илгә бу көн шатлык биргән Олуг тәңрегә Гөлбикә кол була икән, булсын, ни була?

Алмас хан озатканда Изге атаның кулына берничә алтын тәңкә сала да тирән уйга бата. Озак кына уйлап торганнан соң күтәрелеп караса, ни күрсен: ишек төбендә Гөлбикә басып тора.

— Атакай, нигә болай уйда син, минем кергәнемне дә тоймыйча, каты уйга чумып, маңгайларыңны җыерып тора идең?

— Кил, балакаем, кил, синең терелү шатлыгыңны күргәч, миндә нинди генә кайгы булсын. Син бит безнең бәхетебез, син бөтен Алтын каланың, бөтен Болгар иленең бәхетесең. Кил, бер туйганчы үзеңне сөйим. Миңа бу көнне бирмәсләр дип курыккан идем. Илгизәрләрнең куллары җиңел булды. Аларның тәңреләре сиңа ярдәм иттеләр.

— Чыны да шулай, атакай. Багдад кунакларының беренче килүеннән үк, мин үземдә җиңеллек сизә башладым. Нигә соң, атакай, безнең тәңреләр ярдәм итмәделәр. Изге ата да яңлышты бугай.

— Чү, балам, алай димә. Әле генә Изге ата монда булды. Ул әйтә: «Безнең сөекле Гөлбикәбез бөтен илне шатлыкка чумырды. Аның Ак юргасы чалынмаса болай булмас иде»,— ди.

— Соң, атакай, үзең беләсең, мине бит шул гарәпләр терелттеләр.

— Шулай, алар. Ак юрганың тиресе кемгә бирелгән иде соң?

— Аларга. Атакай, син аларга зур бүләкләр бирерсең инде.

— Балакай, эш анда түгел әле. Мин синең киләчәгең тугрысында уйлап тора идем. Балакай, син белмәгән бик зур яшерен эш бар.

— Атакаем, ике күзем, миңа да әйт! Ул эшне дәү анам, кече аналарым беләләрме?

— Беләләр.

— Нигә соң, атакай, мин генә белмим?

— Син авыру идең, сиңа әйтергә ярамый иде.

— Инде әйт.

— Әйтермен, беләсең бит, балакай, синең авыруың мине, аналарыңны, Алтын каланы, бөтен Болгар илен зур кайгыга төшерде. Барыбызның да теләгебез сине терелтү булды. Теләүдән теләү, дарудан дару, имнән им калмады. Тик берсеннән дә файда чыкмады. Ни эшләргә дә белмәгәч...

— Атакай, нигә син кызарасың, нигә борчыласың, нигә барысын да тиз үк сөйләмисең? Нәрсәдер сине тыгызлый. Ни эшләргә белмәгәч, ни кылдың соң?

— Ике күзем, Гөлбикәм, мин сиңа кыска гына бер экият сөйлим әле: борын заманда бер зур хан булган. Ул әллә кая, бездән еракта, таулар, диңгезләр артында яшәгән, аның бөтен җире дошман кермәсен өчен биек таш коймалар белән әйләндерелгән. Байлыкта аның тиңдәше булмаган. Ничә ир баласы булса, барысы да үлә барган. Хан бик кайгырган. Көн уйлаган, төннәрен йокламаган, һаман да иленең, йортының язмышы туг-

рысында уйлаган. Аның бердәнбер кызы булган. Бер дә беркөнне ул да авырып киткән. Хан ни эшләргә дә белмәгән. Бөтен илнең укымышлыларын, имчеләрен җыйган. Тик кызы терелмәгән. Алай да булмагач, Хан: «Кызымны терелткән кеше минем киявем була»,— дип, илгә ярлык[1] тараткан.

Илдән кеше чыкмаган. Бер дә беркөнне Ханның көтүчесе булган бер егет килеп, файдалы киңәш биргән. Шуның сүзе, киңәше белән кыз терелеп киткән. Шуннан соң Хан тагын да зур уйга чумган. Үзенең сүзеннән чыкмыйча, кызын көтүчегә бирергәме, әллә сүзен кире алыргамы? Көн уйлаган, төн уйлаган, нишләргә дә белмәгән. Шуннан соң бу тугрыда кызына әйткән. Кызы атасына: «Атам, син илнең башы, синең сүзең чын булырга тиеш, син дә ялганласаң, бөтен ил синнән начар күчергеч алыр. Белеп булмый, бәлки, синең көтүчең изгеләрдәндер. Сүзең бер булсын, атам. Мине аңа багышла»,— дигән.

Бу сүзләрне әйткәндә, Гөлбикә атасының итәгенә таянып, күзләрен түбән төшереп, тырнакларына карап утыра иде. Сүздән туктау белән ул оялып кына атасына карый. Бераз тын булып тора. Гөлбикә атасына кайтарып бер сүз дә әйтми. Аның күз алдына матур Габдулла килеп баса. Алмас кызының йөзенә караңгылык, кайгы төсе кермәгәнен күреп, үзендә тынычлык сизә. Ул арада ачык, көләч йөз белән Ахак бүлмәгә керә. Алмас Гөлбикәнең башыннан сөя дә чыгып китә. Ахак белән Гөлбикә Алмас сөйләгән экиятне берәмләп чишәләр, юрыйлар, инде Гөлбикә өчен яшерен сер калмый. Озакламый сарай хадимәләренең иң башы Гөлбикәнең «Атакаем, синең сүзең бер булсын» дигән сөенеч хәбәрен ирештереп, Алмас ханнан бик зур бүләк ала.

---

[1] *Ярлык* — хәбәр, указ (*Ш.Әхмәдиев*).



## V

Алмас хан үзенең әйткән сүзе белән Гөлбикәне Габдуллага багышлый. Бу хәбәр элек Ханның якыннарына әйтелә. Аннан соң Тукбай мирза йортына берничә сарай кешесе барып ирештерә. Көне-сәгате белән бу хәбәр Алтын каланы, Болгар илен урап ала. Ханның бу уена каршы килүче булмый. Бәлки, ул бүз баланы тәңреләр җибәргәннәрдер. Бәлки, алар килмәсә, Гөлбикә генә түгел, бөтен илебез дә кырылып бетәр иде. Алмас ханыбыз яңлышмаска тиеш, диләр иде. Шулай итеп, ил бик зур туй гына көтә иде.

Тукбай мирза шатлыгыннан иге-чиге булмаган алтын-көмеш тәңкәләрне ярлыларга, үксезләргә тараттыра, хатыны белән гыйбадәттән башын күтәрми. Габдрахман, Габдуллалар белән мәңге туган, дус булып яшәргә ант итешә. Ул аларны хан балалары кебек киендерә. Аларның бөтен киемнәрен алтынга, ефәккә бетә. Үзенең һәм хатынының да күптән бирле ислам динендә икәнлекләрен дә мәгълүм итә. Шуннан соң арада һичбер яшерен сер калмый. Хан тарафыннан Гөлбикәнең Габдуллага багышлану хәбәрен китергән вәкилләр искиткеч зур хөрмәт белән каршы алыналар. Аларга кыйммәтле бүләкләр бирелә. Габдулла исеменнән Гөлбикәгә эче ал, түбәсе кызыл ефәктән булган таҗ җибәрелә. Таҗның маңгай өсте кул яссысы киңлегендә ак ефәккә энҗеләр тезеп, нәкъ маңгай тугрысына гына зур асылташ куела. Аның тирәсенә кара алтын белән «ля илаһе илләаллаһе Мөхәммәдер рәсүлулла» дип языла. Таҗның өсте озын, матур каурсыннар белән бизәлә.

Вәкилләр бу таҗны Хан кызына ирештерәләр. Гөлбикә бу таҗны күреп, хәйранга кала.

— Атакаем, бу бит минем төшемдә күргән бүрек, бер аермасы да юк,— ди.

Алмас ни әйтергә белми. Ул яныннан барысын да чыгарып, тик үзе генә кала. Аны тирән уй баса. «Монда безгә аңлашылмый торган нindидер яшерен эшләр бар. Тукбай, гарәпләр... Изге ата... Нигә Тукбай чит бер кунаклар өчен алтыннар түгә, ярты байлыгы торырлык бүрекне минем кызыма бүләк итә? Ул бүрекне кызым авыру чагында ук төшендә күрә. Нинди изге төшләр... Ник мин аңламыйм? Илем, алтын кызым Гөлбикә — барысы, барысы шул гарәп егетләренең теләүләре белән куркыныч эшләрдән котылдылар. Юкса безнең тәңреләребезнең көче беттеме? Әллә алар шул егетләрне безгә җибәрделәрме? Алай дисәң, аларның тәңреләре башка»,— ди Алмас хан. Шуннан соң ул киңәшкә тагын Изге атаны чакыра. Аңар һәммәсен сөйләп бирә.

— Башкасы тагын бер эш, әйт әле, Изге ата, бу төшне ничек аңларга кирәк?

— Мин сиңа күптән әйттем бугай, олуг ханыбыз Алмас, аларның тәңреләре безгә ярдәм иттеләр.

— Соң, безнекеләр?

— Алар көчсезләр!

Алмас Изге атаның бу сүзенә исе китә. Изге ата ап-ак сакалын кулы белән сыпырып, уйга чумып, түбән карап тора.

— Олуг ханыбыз Алмас! Актык көннәрем җитеп бара. Мин тугрылык өчен бернәрсәдән дә курыкмаска тиеш. Моңа кадәр синең өчен мин яшерен генә алар Тәңресенә коллык кылдым. Шуннан тәм, шуннан ямь таптым. Мин сиңа берчакны: төн артыннан көн булыр, Олуг тәңре безне сөендерер, дигән идем, инде аңларга кирәк.

Алмас хан белән Изге ата озак ук тын гына калалар. Алмасның күңеленә «бөтен илнең ышанган Изге атасы ата-бабалар юлын ташлый, башка тәңреләргә коллык итә» дигән уй килә.

— Изге ата, син моңа чикле дә тугры булдың, ил

сиңа ышанды, хәзер дә синең уең, синең теләгең чын булсын!

Изге атаның күзләреннән мөлдерәп яшь агарга тотына. Ул, тезләнеп, Алмас ханның аягын кочаклый.

— И олуг ханыбыз Алмас! Мин бу шатлыкны күреп үләрмен димәгән идем...

— И Изге ата, тор, уең изге, Алмас сиңа юлдаш!

Шуннан соң Алмас Тукбай мирзаны чакыра. Тукбай мирзага да үзенең ислам диненә мәхәббәте барлыгын һәм анда күчәргә теләгәнен сөйли. Хан тарафыннан елы, күңелле хәбәр ишеткәч, Тукбай Ханның аягына егылып, рәхмәтләр укый. «Барлык байлыгым шул юлда корбан булсын»,— ди.

Алмас хан үзенең сараендагы бөтен кешеләргә, Алтын каланың олугларына һәм илнең биләренә үзенең ислам диненә күчәргә теләгәнен белдерә. Ни өчен мөселман булганлыгын сөйли. Алмас хан, Изге ата һәм Тукбай мирза мөселман булгач, башкаларга ни кала, Алмас хан сүзенә, уена беркем дә каршы килми. Илнең тагын бер зур эше килеп чыга. Алмас хан гаять тә зур туйга хәзерләнә. Илнең төрле җирләренә юлчабарлар җибәрә. Бөтен Болгар илен туйга чакырып, һәрбер теләгән кешегә килергә боера. Илдәге көрәшчеләр, җырчылар, уенчылар һәм чапкын атларның берсе дә калмый. Туй булыр көннәрдә Алтын кала тирәсендәге тугайлар, болыннар кара болыт кебек кеше белән тула. Туйның урыны элекке теләү урыны Изге түбәдә була. Изге түбәгә чиксез матур итеп, алтын айлар утыртып, мөнбәрләр, Хан өчен тәхетләр ясала. Туй көнендә халык Изге түбәне каплап ала. Алмас хан үзенең кияве Габдулла, кызы Гөлбикә һәм ханбикәләре белән бергә килә. Болар күренүгә, олуглау тавышлары бөтен дөньяны яңгырата. Илнең олуглары боларның өсләренә алтын тәңкәләр сибәләр. Габдрахман, Изге ата, Тукбай мирза

һәм сарай кешеләре, Алтын каланың олуглары Хан артыннан киләләр. Алар өстенә дә алтын-көмеш тәңкәләр сибелә. Изге ата, Алмас ханның кушуы буенча, биек, матур мөнбәргә чыгып, ислам динен кабул итү тугрысында Алмас ханның фәрманы галиен[1] укый.

Изге ата мөнбәргә басу белән, барлык халык иелеп, аңар түбәнчелек күрсәтәләр. Ханның башында ак чалма, өстендә ак чапан.

Фәрман галине укыганда, Хан һәм олугларның һәммәсе аягүрә басып торалар.

Изге ата укып бетергәч, халык тын булып кала. Шуннан соң Алмас хан үзе мөнбәргә басып сөйли. Аны котлаган халык тавышы дөньяны яңгырата.

Туй башлана. Иң элек илнең кунаклары өчен корылган меңләп чатырларда яхшы итеп аш-су бирелә. Меңнәрчә сабалардан[2] кымыз тәкъдим ителә. Шуннан соң көннең-көн буена, төннең-төн буена берсе артыннан берсе төрле уеннар тезелеп китә. Уеннар, көрәш-чабышларда өстен чыккан кешеләргә зур бүләкләр бирелә. Бу туй, шул рәвешчә, ничә көннәргә сузыла.

Алмас хан, мөселман булуы белән, Алтын калага Габдрахман, Изге ата, һәм Тукбай күрсәтүе буенча, манаралары болытка җитеп торган гаять тә зиннәтле мәсҗедләр салдыра. Илгә дин-исламны өйрәтү өчен Багдад хәлифәлегенә[3] вәкилләр җибәреп, галимнәр чакырта. Аларны бик олуглап каршы ала.

Шулай итеп, берничә елның эчендә Алтын калада әллә никадәр мәсҗед һәм мәдрәсә була. Авылларга

---

[1] *Фәрманы гали* — бөек боерык.

[2] *Саба* — капчыкка охшатып, тире яки күннән эшләнгән савыт, аңа кымыз яки су салып йөрткәннәр.

[3] *Хәлифәлек* — ислам динендәге халыкларның берлеге, үзәге урнашкан мөселман дәүләте.

да дин таралып, Кара Идел, Кама, Ак Идел, Сура сулары буеннан азан тавышлары яңгырый башлый.

Тукбай мирза бар малын диярлек мәсҗедләргә, мәктәпләргә сарыф кыла. Илдә ислам дине нык ук урынлашып җиткәч, хатыны һәм Изге ата белән хаҗ сәфәренә чыгалар. Ләкин аларның берсе дә яңадан Алтын калага әйләнеп кайта алмый.

Алмас хан шул вакыйгадан биш ел соң үлә. Ахак озак кына гомер итә. Габдулла белән Гөлбикә чын мәхәббәт белән рәхәт гомер итәләр. Болгар илендә Алмас хан кебек хөкем сөрәләр. Габдрахман аларның якын дуслары була.

Шулай да Гөлбикә үзенең Ак юргасын сагынып-сагынып куя. Күп вакыт ул үзенең сөеклесе Габдулладан: «Ике күзем, син минем Ак юргамның тиресен нишләттең?» — дияргә уйлый, тик һаман сорый алмый кала иде.

*1915*





# Ике төрле тормыш

## I

Кышның урталары... Көннәр бик салкын. Күк йөзе күренми. Барлык җир оешып бергә туңган төсле. Бүрәнәләр, ташлар ярылып, шартлап китәләр. Зәһәр салкын җил ялкын кебек куырып ала. Кырдагы юлчы атлар, берничә адым барган саен туктап, тын алалар. Чаналарның шыгырдаулары ерак җирләргә ишетелә. Юлчыларга толып, җылы бүрек, шарф, калын киез итекләрнең дә җылылары җитми. Әллә кайдан салкын җил кереп, йөрәккә барып кадалган төсле була. «Нинди салкын, мондый каты зәһәрле суыкны ата-бабабыз да күрмәгәндер»,— диләр.

Йорттагы хайваннар үзләренең ояларыннан чыгарга да куркалар. Күгәрченнәр сарайларның, печәнлекләрнең кыекларына ясалган ояларыннан кузгалмыйча, бергә укмашып, борыннарын канат асларыннан чыгарырга да куркып торалар. Тавыклар, әтәчләр, казлар, үрдәкләр канатларыннан тотканчы яннарына кеше барганны да белмиләр. Һәммәсе, һәммәсе яшеренгән, һәммәсе җылы эзли. Башка вакыт аяк

тавышына да кабаланып-кабаланып өрә торган этләр үзләренең ояларына яисә салам асларына кереп югалганнар, тавыш-гауга булса да, аларның хәбәрләре дә юк. Кайвакыт бик хәйләкәр эт кенә, урыныннан кузгалмыйча, «хау, хау, хау» ди дә яңадан сеңеп китә.

## II

Җомга көн иде. Хәйрулла бабай иртә үк уянып, ертылып, тишелеп беткән кырык ямау юрганын башыннан ачуга, аның күзләре укмашып-укмашып бозланган тәрәзәсенә төште. «Йа Ходай, бигрәк салкын икән, бетмәс-төкәнмәс зәһәр суыклар булыр икән. Инде кайдан утын, йомычка табып, өйне җылытыйм, кайдан нәрсә табып, баламны туклandырыйм»,— дигән хәсрәтле уйлар аны суыктан да бигрәк, өшетеп һәм тундырып җибәрә. Бер кызыннан калган җиде яшьлек ятим ир бала, бөгәрләнеп, бернәрсә белмичә йоклый. Хәйрулла бабай хәленнән килгән кадәр утын яру белән көнен үткәрә. Соңгы каты салкыннардан куркып тора-тора, аның актык тиеннәре дә беткән иде. Тик кичкә кадәр баласына тукланырлык ике чокыр сөт, бер кадак кара икмәк кенә бар иде.

Ул торып калтырый-калтырый аягына чабата-оек һәм өстенә иске бишмәт киеп, муенына карчыгыннан калган иске шәлен урап, эш эзләргә чыгып китә.

## III

Бала, йокысыннан уянып, курка-курка гына үз өстеннән бишмәт сәләмәләрен күтәреп караса, бабасы янында юк. Ул: «Бабаем эшкә киткән, ахры»,— дип, өй эченә карана башлый. Тиз генә почмактан балтаны карагач, бабасының эшкә киткәненә бер дә шиге калмый. Шуннан соң ул битен юып, бер чокыр сөт салып һәм бер телем икмәкне ала да ашарга утыра. Никадәр бишмәт, юрганнарга төренсә дә, өйдәге

салкыннан аның арык битендәге йомшак йоннарына кадәр үрә тора һәм нечкә, ябык бармаклары дер-дер калтырый иде.

Бала үз карынын туклandыргач, бар кебек нәрсәсенә урала да урам өстендәге тәрәзә янына килеп утыра. Ул урамны карар өчен тырнап, өреп ничаклы тәрәзәнең бозын эретергә, кечкенә күз ясарга тырышса да, булдыра алмыйдыр. Аның өрүеннән, аның тын җибәрүеннән ачылган тәрәзә күзе шунда ук өр-яңадан туңа бара. Үтеп киткән һәрбер кеше аңа бөкрәеп, балтасын биленә куеп, өйгә кайтып килгән үз бабасы төсле күренә иде. Менә баланың бәхетенә каршы ишек төбендә песи тавышы ишетелде. Ул тиз генә ишекне ачып, аны өйгә кертә.

Песи дә өшеп, туңып беткән иде. Бала аңа аз гына сөт белән кара икмәк чылатып ашарга бирә. Песи йотлыга-йотлыга биргәнне ашый бара. Шуннан соң өйгә бераз хәят кергән төсле була. Ятим бала бер җепнең очына чук бәйли дә кунак песи белән уйнарга тотына, бабасы кайтканчы аны үз яныннан җибәрми.

## IV

Хәйрулла бабай анда сугылды, монда сугылды. Һичбер җирдә эш таба алмады. Тик базардагы бер хатынның алган әйберләрен өенә илтеп кенә ун тиен акча тапты. Салкыннан аның сакал-мыеклары боз булып каткан, кашларында да бозлар салынып-салынып торалар иде. Аның балтасы каты суыктан көмеш кебек агарган, тигән җирне чеметеп, өзеп ала иде. Ул шулай йөри-йөри җомганың үткәнен дә сизми калды. «Әй Алла, атнасына бер килгән җомга көнне дә мәчеткә барып булмый. Карт көнеңдә дә тынычлап гыйбадәт кылырга юк. Бу фәкыйрьлекне!.. Дошманыңа язма»,— дип, бер капкадан икенче капкага кереп йөри иде, кинәттән бер зур байның

йортына аның күзе төште. Әгәр эш булмаса, садака сорарга да уйлап, ишек төбенә барды. «Бездә ярырга утын юк, бабай» дигән тавыш аның өметен кисте. Шуннан соң ул бик сукранган тавыш белән: «Эш табып булмый, байлар садакалардан рәхим итмәсләр микән?» — дип кычкырды. Ләкин аңа каршы җавап бирүче булмады. Шул арада һәйбәт атка утырган, зур төлке толыпка күмелгән йорт хуҗасы кайтып, бер сүз дә әйтмичә, өенә кереп китте. Өшегән, туңган Хәйрулла бабайның сүзе аның колагына да кермичә калды. Калын шәлләргә уранган, йон күлмәкләр, җылы туннар кигән хуҗа хатыны да, чак-чак кына тынын алып, читтән кайтып, өенә кереп китте. Картның суыктан аяклары бөгелә, үзе бөрешә.

Шул арада ишектән байның ун яшьлек кызы килеп чыга. Ул асрау белән каядыр китеп бара. Ишек төбендә калтыранып торган, сакал-мыек, кашлары бозланган бабайны күрүгә ул тукталып кала:

— Бабай, ни эшләп торасың? — дип сорый.

— Эш таба алмадым. Байлар садакадан рәхим итмәсләрме икән, өйдә утыным юк, ашарга юк, бер ятим балам бар, ул да өшеп, туңып беткәндер инде,— ди бабай.

Кыз бала бабайны шулкадәр кызгана, аның күзенә яшьләре килеп тәрәлә. Ул муфтасыннан егерме тиен акча алып бабайга биргәнен тоймый да кала. Асрауның:

— Әниең ачуланыр, хәерчегә шулай күп бирәләрмени? — дигәне аның колагына да керми. Алай гынамы, ул асрауны калдыра да өйгә чабып кереп китә.

— Әнкәй, ишек төбендә бер бабай туңып, өшеп садака көтә,— ди.

Анасының:

— Андый хәерчеләр җомга көн күп була инде, барысына да биреп бетерә алмассың,— дигән сүзенә каршы ул:

— Әни, ул хәерче түгел, балтасы да билендә. Мин аны кызганам. Безнең калган аш бар бит, аңа бирик, ул кереп ашасын, бераз җылынып та алыр иде,— ди.

Әнкәсе өзелеп-өзелеп сораган кызының теләгенә каршы килә алмый:

— Алайса, бар, керсен! — ди.

Кыз баланың:

— Бабай, әйдә кер, бераз җылынып чыгарсың,— дигән тавышы Хәйрулла бабайны җәһәннәм газабыннан коткарган төсле булды. Ул: «Балакай, яхшы булмас бит, аягымда чабата»,— дип, шома идәннән тая-тая ашханә ишегеннән кереп китте.

Җылы ашханә аңа җәннәт төсле күренде. Аның туңган бармаклары бик озакка кадәр кашыкны авызына китерә алмыйча йөдәп беттеләр. Кыз бала картның ашаганын карап, һәрбер капканы саен рәхмәтләр укыганын ишетеп тора һәм бик кызгана иде...

Ашап бетергәч, асраулар күрмиме икән дип, якягына каранды да бер кисәк пешкән ит белән зур гына телем икмәкне тиз генә бер кәгазьгә төреп: «Ятим балаңа бирерсең»,— дип, бабайның куенына тыкты. Чыкканда, этләр тимәсен дип, бабайны капкага чаклы озатып калды.

*1915*



---

Хикәя «Ак юл»да «Алла кешесе» исеме белән басылган, соңыннан автор хикәянең исемен «Ике төрле тормыш» дип үзгәрткән.

# Байлык хакында

*(Толстойдан)*

Хуҗа, аның хатыны һәм алты яшьлек ир бала балконда чәй эчеп утыралар. Шунда, якында гына балалар уйнап йөриләр. Яшь хәерче аларның янына килә.

Хуҗа (*хәерчегә*). Нәрсә кирәк?

Хәерче (*башын ия*). Билгеле инде, рәхим итегез лә! Эшсезмен, ялангач, ашаганым да юк... Калада булдым, инде өемә таба кайтып барам. Шәһәр фәкыйрь кешегә шәфкатьсез икән, ярдәм итеңез лә!

Хуҗа. Син нидән фәкыйрьсең?

Хәерче. Билгеле инде, нәрсәдән — юклык!

Хуҗа. Сиңа эшләү кирәк иде. Менә фәкыйрь булмас идең.

Хәерче. Бик эшләр идем дә бит, эш юк әле. Кайдан да эш табар хәл юк.

Хуҗа. Нигә соң башкалар эшлиләр, син эш таба алмыйсың.

Хәерче. Ышаныгыз инде, бик рәхәтләнеп эшләр идем, ни эшлим соң, алмыйлар. Бай, икенче көн бернәрсә дә ашаганым юк, зинһар, шәфкать итегез лә!

Хуҗа (*хатынына таба карап, акча янчыгын актара*). Миндә кәгазь акчалар гына, синдә вак юкмы?

Хуҗа хатыны (*ир балага карап*). Бар әле, акыллым, әнә тегеннән акча янчыгын китер! (*Бала анасын ишетми, күзен алмыйча хәерчегә карап тора.*)

Хуҗа хатыны. Балакаем, нигә ишетмисең? (*Баланың кулыннан тота.*)

Бала. Нәрсә, әнкәй? (*Анасы нәрсә кирәгене яңадан әйткәч, бала акча алырга йөгереп китә.*)

Хуҗа. Хәзер булыр, бераз көт. (*Хәерче бер читкә китә, хуҗа хатынына карап.*) Гаҗәп инде, шундый эшсез йөрүчеләрнең исәбе-хисабы юк.

Хуҗа хатыны. Әгәр ач булса, бигрәк аяныч инде. Башка патшалыкларда эшсез кешеләр йөз меңләп икән. Мин шул хакта укыган идем... Тагын чәй эчмисеңме?

Хуҗа. Яса, ләкин сыеграк булсын.

Хәерче йөткергәли, болардан күзен алмыйча тора. Бала акча янчыгын анасына китереп бирә дә хәерчене әзли. Аңа текәлеп карап тора.

Хуҗа (*янчыгыннан ун тиенне алып*). Әй син, менә сиңа!

Хәерче (*бик түбәнчелек белән көмешне ала*). Рәхмәт, Алла разый булсын, бичарага ярдәм иткән өчен Ходa сезгә өмет итмәгән җирдән бирсен!

Хуҗа. Мин сезне шуның өчен кызганам: сез эшләмисез, эшләсәгез фәкыйрь, мохтаҗ булмас идегез, эшләгән кеше бервакытта да фәкыйрь булмый.

Хәерче (*көмешне алып китә*). Дөрес, эштән фәкыйрь булмассың, әмма аркаң чыгар.

Бала. Әти, ул нәрсә диде?

Хуҗа. Нәрсә дисен, үзенең тозсыз, мәгънәсез мәкален әйтеп китте. Имеш, эш эшләп фәкыйрь булмассың, әмма аркаң чыгар.

Бала. Ни дигән сүз ул, әти?

Хуҗа. Гүя эштән аркаң гына чыгадыр, әмма эштән баеп булмый.

Бала. Бу дөрес түгел, әти.

Хуҗа. Әлбәттә, дөрес түгел. Менә шулай эшләмичә йөргән кешеләр һәрвакыт фәкыйрьләр, эшләгән кешеләр һәрвакыт бай булалар.

Бала. Соң, әти, без бай бит, үзебез эшләмибез, нидән соң алай?

Хуҗа хатыны (*көлә*). Син әтиеңнең эшләмәгәнен кайдан беләсең?

Бала. Мин белмим, ләкин без бик бай. Шулай булгач, әтигә нинди күп эшләргә кирәк, соң ул шулай күп эшлимени?

Х у җ а. Эш белән эшнең аермасы бар. Минем эшем үзенә башка, аны һәркем эшләрлек түгел.

Б а л а. Синең эшең нинди соң?

Х у җ а. Минем эшем — сезне укыту, ашату, киендерү.

Б а л а. Аның да шулай ук бит. Нигә соң ул болай кызганыч, мескен йөри. Без менә ничек.

Х у җ а. Алай күпне белергә ярамый. (*Көлә.*) Кара син аны, тумыштан «Халык сөюче».

Х у җ а  х а т ы н ы. Бер мәкаль бар, «Һәрбер гакылсыз меңләп хәким җавап бирә алмаслык сөальләр бирәдер» дигәннәр. Ләкин һәрбер гакылсыз урынына «һәрбер бала» дип әйтергә кирәк иде.

*1915*

## Җен теле

Мин әле яңа гына мәктәпкә йөри башлаган идем. Шулай да иҗек китабы — «Иман шарты»[1] астын-өстен таный алмаслык дәрәҗәдә каралырга өлгергән иде. Үктябрь аеның урталары булса кирәк, минем эти кинәт авырып китте.

Ул башы әйләнүдән зарланса да, күп тә үтмәде, саташа башлады. Саклап тормасаң, төнлә тора да, йә мәсҗедкә, йә мәктәпкә, йә туры зиярәтләр өстенә китә башлый иде. Аның авыруына төрле сәбәпләр күрсәтәләр иде. Берсе әйтә: «Салкын тигәндер, салкын тисә, кеше саташа»,— ди. Икенчесе: «Салкын тиюдән кеше саташмый, кичен зәхмәтле җил кагылгандыр»,— ди. Өченчесе: «Зәхмәтле җилнеке алай булмый, ул бервакыт нәзер әйткәндер, инде шул нәзере тота торгандыр, ул нәзерен төгәлләргә оныткандыр»,— ди. Дүртенчесе: «Бу, асла, нәзернеке түгел, мөгаен, әйләндереп салганга туры килгәндер, юкса болай булмас»,— ди. Әле болай гына калмый, кем генә килмәсен, әйтмәсен — һәммәсеннән үзенә бер төрле фикер ишетәсең. Шул киңәшләр буенча ни эшләргә дә белмәгәч, этине мунчалыйлар. Кызган ташның буына утырталар, им-том кылалар, түгәрәк «Ясин» аркылы чыгаралар, тәрилкәгә язган зәгъфран суы эчерәләр, кырык Ясин чыгарталар, тозга, суга өшкертеп эчерәләр, мәтрүшкә булары җибәрәләр. Дөресе генә, нинди әби нәрсә белә, нәрсә куша — һәммәсе эшкә кертелә. Ләкин боларның берсе дә авыруга файда итми...

Алай да, болай да булмагач, җен шаукымы кайтара торган кеше эзләргә тотыналар. Каядыр бер җен шәһәрендә булып кайткан «Курай суфи» бар, имеш. Аның өшкерүеннән үлмәскә булса, сырхау терелмичә

[1] *«Иман шарты»* — иске мәктәп-мәдрәсәләрдә балаларга иң беренче бирелә торган дәреслек, төрле дини догалардан тора.

калмый, имеш. Менә аның артыннан да җибәрәләр. Ул да килеп җитә. Ни күзебез күрсен: зур гәүдәле, озын, салынкы кашлы, ямьсез чырайлы, коточкыч бер суфи. Менә әллә нәрсәләр укып, өшкерергә тотына. Без куркып өйдән чыгып качабыз. Ул өшкерә дә өшкерә. Әти йокласа да, йә саташырга тотынса да, этинең өстенә өшкерә, йокламаса, тозга, суга өшкерә. Һәр өшкергән саен чынаяктагы су төбенә садакага көмеш тәңкә салырга куша...

Беркөнне эти кич алдыннан ук изелеп йокыга китте. Ул арада безгә сырхауның хәлен белергә кергән кешеләр «Курай суфи»дан сораша башладылар:

— Тәхсир[1] хәзрәт, сезне инде җен шәһәренә барган, дип, менә сөйлиләр бит, мөселман, кяфер җеннәре дә бар, имеш, ул ничек була инде,— ди бер карт. Мин суфи ни сөйләр инде дип текәлеп карап торам.

— Бар, бабай, бар, менә мин үзем күрдем. Ул чакта әле минем күзләрем исән иде, үзем дә бик яшь идем,— ди «Курай суфи». Бәлки, үзегез дә белә торгансыздыр мәшһүр Габделҗәббар мәдрәсәсен, хәзрәт үзе мәрхүм инде. Бервакыт мин шуннан укып, авылга кайтканда, адашып киткәнмен. Миңа бер дә борылмыйча, бер урман аркылы чыгарга кушканнар иде. Урманга кергәч, минем баш әйләнеп китте дә, кая барырга да белмичә киттем дә киттем. Барам, барам, көн барам, төн барам, кошлар очкан тавыш та ишетелми. Үзем яшь кенә, куркып җыларга тотынам. Тагы китәм. Менә бер урман аланына килеп чыксам, бер арбалы ат үлән ашап йөри. Мин шатлыгымнан җыларга да, көләргә дә белмим: Аллага шөкер, котылдым! дим. Ат янына барсам, ерак та түгел генә җирдән бер кара гына сакаллы, матур гына йөзле кеше килә... «Әссәламе галәйкем, абзый, исәнме?» — дим. Ул эндәшми.

---

[1] *Тәхсир* — дин кешеләрен олылап әйтү сүзе.

Миңа таба күтәрелеп тә карамый, тик үз эшендә була. «Абзый, исәнме? Кайсы авылныкы буласың?» — дип кычкырам, янына ук барам. Бер сүз дә җавап бирми, үзе бит янымда ук тора. Ул ара да булмады, атына атланды да китеп тә барды. «Абзый, абзый, мине дә утырт, мин адаштым!» — дип кычкырам, бер сүз дә юк. Алай да булмагач, ни булса, шул булыр, дим дә арбага барып та утырам. Мин утыруга, ат авырсынып китә дә кеше әйләнеп карый. Мин әйтәм: «Мине куып төшерә инде, җаным бугазымда гына тора». Үзе минем өстемә карый, ләкин ачуланмый да, көлми дә. «Ник мин әйтәм, бу бер сүз дә эндәшми. Ах, мин әйтәм, бу, мөгаен, җендер, тик менә күрә генә алмый торгандыр, кая гына алып барыр, кая гына илтеп ыргытыр инде». Ул кайгырам, ул хафаланам, төшеп калсаң да кая барасың?!

Бара-бара бер зур суның янына килеп җиттек. Мин инде атына су эчерә торгандыр, ахры, дип уйлыйм... Ул ара да булмады, без суның аргы ягына чыкканбыз. Зур су артыбызда ук калган. Хәзер белдем: чыннан да, бу җен икән, дим. Белгән барлык догаларымны укырга тотынам. Ни генә эшләргә белмим, югалды, дим, газиз башым.

Озак та үтмәде, бер ап-ак шәһәргә килеп җиттек. Хикмәти Хода, нәрсәгә генә карама, ак таштан салынган, җелтерәп тора. Күтәрелебрәк карасам, ни күзем күрсен — мәсҗед.

Ул шәһәрнең иң матур өеннән дә матур. Аның ак манарасы, озын шәм кебек, болытка җитеп торган төсле мәсҗедне күргәч, бераз тын ала төштем. Бу мөселман җеннәренең шәһәре икән, дим.

Бер матур гына йортка барып төштек. Безгә каршы чыктылар. Өйлә вакыты иде. Мине күрүче дә юк. Ишек төбендә бер матур кыз тәһарәт алып утыра. Мөлдерәп торган ак йөзле, кара кашлы, кара чәчле, зифа буйлы. Ни генә әйтеп мактасаң да аз инде, адәм

баласыннан һич тә андый кеше була торган түгел. Минем исем китте. Шаккатып карап тордым.

Янә бер карт тәһарәт алды да, сөт кебек ак чалмасын, ак чапанын киеп, мәсҗедкә китте. Күтәрелеп мәсҗедкә карыйм. Анда бер кеше тора. Ахрысы, азан әйтә торгандыр. Тик тавышы миңа ишетелми. Мин дә, тәһарәтләнеп, намазга киттем.

Һәммәсе намазны безнеңчә укыйлар. «Болар да имам Әгъзам мәзһәбендәләр икән»[1] дим үз-үземә. Мулла михрабка кереп, сөннәтен укыды, камәт[2] төште, тик миңа ишетелмәде. Мулла фарыз[3] укыта башлады. Менә гаҗәп имамның[4] сүзләре, тәгъбирләре адәм тавышы кебек ишетелә. Фарыздан соң, сәлам биргәндә, мулла көлде дә җибәрде. Башкалар күрми, имам күрә. Ни гаҗәп бу тагын?! Намаздан соң имам минем белән сәлам биреп күреште. «Мин адәм баласы бит, сине таныдым»,— ди. Минем шатлыгымнан йөрәгем ярыла язды. Сораша башладым:

— Мине бала чагымда мөселман җеннәре алып киткәннәр. Укытып имам иттеләр. Чөнки алар үз араларыннан имам куймыйлар, адәмне алалар икән, ди. Мин: «Әйдә, туган, минем белән кит, бергә качыйк, сине дә сизмәсләр бит?» — дим.

— Юк шул, булмый инде, мине күрәләр, беләләр. Качарга ярамый. Инде үзем дә качмыйм, гомер итеп үләрмен инде. Алла теләсә, сиңа юл күрсәтеп озатырмын... сиңа шуны әйтәм: син җеннәргә кагылма, аларны тотма, чөнки алар адәм кагылса, чирлиләр... Әйдә, хәзергә бездә кунак бул! — ди.

---

[1] *Имам Әгъзам мәзһәбендәләр* — Мөхәммәд пәйгамбәр тарафдарлары, ягъни сөнниләр мәзһәбеннән.

[2] *Камәт* — намазга керешү алдыннан аягүрә басып кычкырып укыла торган дога.

[3] *Фарыз* — намазның һичшиксез укылырга тиешле өлеше.

[4] *Имам* — мөселманнарның мәчеттә бергәләп намаз укуына җитәкчелек итүче, намазны алып баручы дин кешесе.

Муллада ашыйм-эчәм дә, кайткан өемә барам. Матур кыз да йортта йөри. Мин капкадан кереп, аңар таба барам. Белерме икән дип, юри барып кулыннан тотам. Бисмилля әйтеп тотсам, чирләмәс эле, дим. Хикмәти Хода, кулымда аның кулы бар төсле дә түгел, гүя бернәрсә дә юк. Кыз үзе минем яннан китә алмый, куркынып карап торган төсле. Гүя мин шәүлә тоттым.

Бер көн үтә, ике көн үтә, шулай итеп, атналар да үтә, кыз авырый башлый, йөзе саргая, тышка да чыкмый, тик ятып кына тора. Бөтен өйләре зур хәсрәткә төштеләр. Мин муллага ни булганын ачык әйттем. Ул: «Ярый, мин кайтарырмын, сырхавы бетәр»,— дигәч кенә тынычланам, юкса бик кызгана идем. Шуннан соң мулла миңа китәрә кушты. «Мин алып кайткан кешеләргә әйтермен, алар илтеп куярлар. Син шул җирдән кыйблага таба кит тә кит»,— диде... Мин шул мулладан җен телен өйрәндем. Җен шаукымын кайтарыр өчен дә җен телен белү кирәк икән...

Китәр вакыт җитте. Миңа шул атны, шул арбаны җигәләр. Шул ук кеше атка атлана, һәммәсе чыгып, минем утырган арбага карыйлар. Ахрысы, мулла барысын сөйләгәндер, кызны да җитәкләп чыгаралар. Мулла дога кыла. Минем белән актык күрешүдә ул бик җылады. «Хуш инде, мәңге күрешә алмыйбыз, саулык белән кайтып җит, туганнарыңны күр!» — ди.

Шуннан соң без киттек. Алып кайтучы кеше мине нәкъ әүвәлге урынга китерде. Мин төшеп, кыйблага таба киттем, киттем. Бәхетем бар икән, бер авылга килеп чыктым. Аннан сорашып, үз илемә кайтып җиттем. Озак та тормады, күзләрем сукырайды. Бәлки, теге матур кызның рәнҗүе минем сукыраюыма сәбәп булгандыр, ди.

Аны тыңлаучы халыкның: «Суфи, җен теленең сүзләре безнекенә охшыймы?» — дип соравына: «Юк,

охшамый, лэкин тормышлары һәм эшләре безнеке төсле үк: анда да кояш, йолдызлар, ай, су, урманнар, таулар, кырлар бар. Халыкның барысы бергә эшли, бергә яши, тук тора, халык байлык белән ярлыга бүленми, ач һәм ялангач торган бер кеше дә анда мин күрмәдем.

Җен сүзләреннән берничәсе болай: «Кәлсәфәнә буш, бәлбә юш, мәлһун һуш». Шул сүзләрне тыңлаган халык җеннәр тормышы адәмнеке төсле һәм теле үзгә икәнен белеп калалар. Әти бик каты саташа башлый. Без барыбыз да куркынып киттек.

*1915*



## Коръән тәэсире

Гомәр... ул гарәп иленең атаклы кешесе иде. Аның шөһрәте кара көч белән түгел иде. Аның гаскәре дә, сакчысы да юк иде. Шулай да аның һәрбер сүзе канун[1] иде. Аның әйткән сүзенә, биргән киңәшенә һичкем каршы килми иде. Чөнки ул гаять тә тугры сүзле, гадел хөкемле кеше иде.

Гомәр үзенә мал җыймый иде. Тик аның яланда йөри торган бер көтү куе, җиде дөясе генә бар иде. Ул хезмәтче тотмый, кол асрамый, бар нәрсәсен үзе эшли, яландагы куй көтүен дә һәм дөяләрен үз балалары карыйлар иде.

Гомәр бик динле иде. Ул ата-бабасының ышанган нәрсәләрен бик изге саный[2], гыйбадәттән бик нык ләззәт таба һәм руханиларны да бик зурлый иде.

---

[1] *Канун* — закон.

[2] Монда гарәпләрнең, исламны кабул иткәнче, мәҗүсилек динендә булулары, айга, кояшка һәм башка төрле сыннарга Тәңре дип табынулары, гыйбадәт кылулары турында сүз бара.

Көннәрнең берендә Мәккә шәһәреннән: «Кораеш кабиләсендә һашим нәселеннән булган Мөхәммәд исемле бер ятим бала ата-баба диненә буйсынмаенча, үзенә яңа бер дин чыгара, шәһәрдә тынычсызлык... Аның сүзенә ышанучы кешеләр көннән-көн арта бара»,— дигән хәбәр генә Гомәрне тынычсызлый башлый. Ул иленең олугларын җыеп киңәшергә тотына. «Мәккә — безнең иң мөкатдәс, иң зур шәһәребез. Әгәр анда тынычсызлык бетмәсә, тиздән безнең илгә дә килеп керер»,— ди ул.

Озак үтми, «Мөхәммәдкә буйсынган кешеләр, ата-баба диненнән чыгучылар бу калада да бар, имеш» дигән хәбәр йөри башлый. Илнең тынычлыгын сөюче Гомәрнең борчылуы чиктән ашып, Мәккәгә үзе барып, илгә фетнә чыгаручы ятим, фәкыйрь Мөхәммәднең башын кисәргә уйлый.

Гомәр үз кабиләсенең, үз иленең йөрәкле, батыр егетләрен җыя һәм гакыллы киңәшләрен ала да Мәккәгә китә. Ул үзенең җиде дөясенә дә кешеләр атландыра. Гомәр, комлы яланнардан үтеп, Мәккә кырыена килеп чыга. Кояш түбән төшеп бара. Нәкъ икенде вакыты. Көн җылы, һава ләтыйф. Аз гына җилгә күтәрелеп китә торган комнар да хәрәкәтсез, матур кояшка каршы алтын төсле җемелдәп торалар. Гомәрнең кунар өчен күзәтеп килгән урынында бер кешенең зур гына куй көтүе утлап йөри иде. Бу җир бик матур иде. Киң яфраклы, шәм кебек төз хөрмә агачлары, ширбәт кебек тәмле, көмеш кебек саф чишмәне уратып алганнар иде. Аларның күләгәсенә килеп кергән кәрван иркенләп сулый һәм хәл җыя иде. Шулай ук чишмәнең салкын суы да эсседән әлсерәп, йөдәп, сусап килгән мосафирларга һәм хайваннарга яңа рух, хәят бирә иде.

Гомәр үзенең юлдашлары белән шул урынга килеп туктаганда, бер көтүче, төшлек ягына карап, кычкырып Коръән укый иде. Ул янына килгән

йөзләрчә дөнья тавышлары ишетмәгән төсле, дөньясын онытып укый иде. Аңардан ерак та түгел җирдә куйлар, кичке һаваның яхшылыгыннан файдаланып, утлап йөриләр иде. Аларның җоннары батып бара торган кояшка каршы җем-җем итеп торалар иде. Үләнгә, суга бай урынны сизгән төсле дөяләр дә зур-зур атлап көтүче янына килеп җитәләр. Бу вакыт көтүче яшел үләннең өстенә үзенең киемен җәеп, намаз укып утыра. Аның алдына гына карап, кулын төшереп, Мәккәгә карап торуы никадәр кешенең килгәнен дә сизмичә чын күңелдән нәрсәдер укуы Гомәрне уйга калдырды. Шуннан соң ул: «Йә фәкыйрь, йә мескен, ни эшлисең?» — диде. Аңар көтүче җавап бирмәде. «Мин бит Гомәр, нигә син миңа җавап бирмисең, әллә мәҗнүнмесең[1], әллә, бичара, телең юкмы?» — диде. Ул ләкин һаман җавап бирмәде.

Көтүче һаман укуында булды, шуннан соң Гомәр үзенең киңәшчеләренә: «Бу да Мөхәммәднең აздырган кешесе түгел микән, мин шулай дип уйлыйм, юкса ни эшли ул, нигә җавап бирми?» — диде. Аның шулай әйтүе белән бер гайрәтле гарәп егете кылычын кыныннан суырып алды да «Башын кисимме?» дигән төсле Гомәргә карады. Гомәр: «Бу бичараның башын кисүдән кемгә дә файда юк»,— диде.

Гыйбадәт бетте.

Көтүче урыныннан торып, Гомәргә сәлам бирде. Аның йөзендә аз гына да курку, каушау әсәре юк иде. «Изге сәфәр иленең олугсы, Гомәр, нигә син башымны кисәргә ирек бирмәдең. Мин нинди бәхетле булыр идем. Бер Алла, җирне, күкне яраткан Аллам миңа җәннәт бирер иде»,— диде. Гомәр бу сүзләрне аңламады, тик фәкыйрь көтүченең мондый батырчылык белән әйтүенә генә хәйран калып торды, шуннан соң ул:

[1] *Мәҗнүн* — юләр, тиле.

— Әйт әле, йә фәкыйрь, йә мескен, син кем, ни эшлисең? — диде.

— Мин мөселман, мин бер Алланың колы, мин беркемнән дә курыкмыйм, тик бер Алладан куркам. Мөхәммәд әл-Әмин[1] безнең рәсүлебез. Мин хәзер бер Аллама гыйбадәт кылдым.

— Йә мескен, синдә гаеп түгел, сине аздыручыны, синең башыңны кисәргә кынысыннан чыккан кылыч Мөхәммәднең башын кисәр.

— Мөхәммәд әл-Әминнең аягына тигән ташлар эреп китә. Корыган хөрмә агачлары аның карашыннан яфрак ярып җибәрәләр, гомердә суы булмаган ташлар арасыннан чишмәләр чыга. Күктәге болытлар аңар күләгә булалар, чылбырдагы этләр аны күргәч, җиргә сеңәләр. Шулай булгач, сезнең кылыч ничек итеп аның башын кисәр икән — күрербез. Әгәр сез кояшны, айны, йолдызларны, бөтен адәмнәрне, хайваннарны, кошларны яраткан бер Алладан көчле булсагыз Мөхәммәд әл-Әминнең башын кисәрсез,— диде көтүче.

Гомәр барлык юлдашчысын шул җирдә калдыра да Мәккәгә тик үзе генә юнәлә.

Көтүченең сүзләре аңар тәэсир итми, аның Мөхәммәдкә ачуы артканнан-арта бара. Мәккәнең беренче йортыннан шәһәрнең хәлене сорашарга уйлый. Инде кояш күптән баткан, караңгылык төшкән иде. Гомәр капкадан кереп, ишек төбенә барганда, өй эчендә бер хатын кычкырып Коръән укый иде. Гомәрнең күңелендә «Бу хатын да шул азгын Мөхәммәднең диненә кергән, ахры» дигән уй туса да, Коръәннең матур, тәмле сүзләре, тирән мәгънәләре аңар шулкадәр тәэсир иттеләр ки, ул укыганны бүлмәде, хатынның тавышын туктаганчы тыңлап торды.

---

[1] *Әл-Әмин* — Мөхәммәд пәйгамбәрне олуглап әйтә торган исемнәрнең берсе.

— Ни эшлисең, азгын хатын, ата-баба диненнән чыктыгызмыни, фәкыйрь азгын Мөхәммәд сезнең барыгызны юлдан яздырды, хәзер башыгызны кисәрмен,— ди Гомәр.

— Миңа кадәр үз кызыңның башын кис! — ди хатын.

— Үз кызым, ул, ул да шулай азганмы, ул да минем диннән чыкканмы?

Гомәрнең ачуыннан җаны тәненә сыймыйча кызы янына китә. Ул ишектән тотыйм дигәндә, гаять тә моңлы, матур тавыш белән укыган Коръән тавышы ишетелә. Йөрәге никадәр сикерсә дә, Гомәр кызының укыганын бүлмичә тыңлап тора.

Гомәрнең көтмәгәннән килеп керүе кызын гаҗәпләндерә. Ул шатланырга да, кайгырырга да белми. Чөнки Гомәрнең йөзендә ачу, кайгы күренеп тора иде. Ләкин ул баш кисү түгел, кызының күңеле калырлык каты сүз дә әйтә алмады. Тик: «Кызым, нәрсә укый идең?» — диде. Кызының куркынычбрак: «Алланың Мөхәммәд әл-Әмин аркылы безгә җибәргән аятьләрен[1] укый идем»,— диюенә каршы бер сүз дә җавап кайтармады. Аның күңелендә моңлы, мәгънәле аятьләр яңгырап торган төсле иде. Шулай да ул «Мөхәммәднең башын кисү фарыз!» дигән уеннан кайтмаган иде. Шул кичне Мәккәнең олугларын күрүе тагын да аның бу фикерен ныгыттылар.

Бу вакыт Мәккәдә Мөхәммәд гамның[2] дошманнары гаять күп иде. Зур нәселләрнең һәммәсе диярлек аңар каршы торалар иде. Гомәргә алар: «Әлегә Мәккәнең хәерчеләре, көтүчеләре, диваналары гына аның диненә чыгалар. Ләкин куркыныч бар. Әгәр хәзер каршы төшмәсәк, Мөхәммәд куәт алыр»,— диләр иде. Гомәр бик шатланып: «Мөхәммәднең башын үзем кисәм»,— диде.

---

[1] *Аять* — Коръәндәге аерым җөмләләр.

[2] *Гам* — Мөхәммәд пәйгамбәрне олылап әйтү сүзе.

Гомәр кан кызулыгы белән Мөхәммәд гамны үтерүне үз өстенә алса да, эшкә керешергә вакыт җитә башлагач, ул үзендә һичбер вакыт сизмәгән куркыну, каушау хисе кыла башлады. Бердән, көтүченең: «Ай-һай, сезнең кылычыгыз аның башын кисә алыр микән, күрербез»,— диюе, икенчедән, «Нигә соң моңар кадәр Мәккәнең кешеләре аны тотып үлтермәгәннәр» дигән уй Гомәрнең гайрәтен суындыра баралар иде.

Ләкин ни кылмак кирәк, эш беткән. Гомәр Мәккәнең олуглары алдында ант иткән, Мөхәммәдне үтерергә булды... «Соңыннан куркып, сүзенә хыянәт итте» дигән хәбәрне ничек күтәрмәк кирәк. Йә вәгъдәне урынына җиткерергә, яисә катиле нәфес[1] кылырга. Ышанычлы, тугры сүзле атаклы Гомәргә икенең берсене эшләргә кирәк иде. Ул менә Мөхәммәд галәйһи әс-сәламнең[2] намаздан чыкканын көтеп тора.

Мәккә дошманнары Мөхәммәд галәйһи әс-сәлам үлгән хәбәрен ишетеп, бәйрәм итәргә көтәләр. Гомәрнең үткен кылычы кынысыннан ялт итеп чыгарга хәзер тора. Ләкин сәгать, минутлар якынайган саен, Гомәрдә яшерен курку, каушау артканнан-арта бара. Аның күз алдында утлар чәчелгән төсле була. Ул үзенең кайда торганын да белми башлый. Гүя Мәккә бөтенләй күчкән, өйләрнең асты-өскә килгән кебек була. Мөхәммәд галәйһи әс-сәламнең башмак тавышлары ишетелә. Гомәрнең кулы калтырый, кылычка якын да бармый. Ул арада булмый, Мөхәммәд галәйһи әс-сәлам мәсҗедтән чыгып, ачык, көләч йөз белән: «Һа, Гомәр дус килгән. Мин сине бүген көткән идем. Дине исламга көч булсын!» — ди. Гомәр күтәрелеп

---

[1] *Катиле нәфес* — үз-үзеңне үтерү.

[2] *Галәйһи әс-сәлам* — Мөхәммәд пәйгамбәрне олылап әйтү сүзе.

караганда, Мөхәммәд галәйһи әс-сәламне нур каплап алган төсле була. Ул тезләнә, Мөхәммәд галәйһи әс-сәламнең башмакларына йөзен куя. «Йә Мөхәммәд, мине гафу ит!» — ди. Мөхәммәд галәйһи әс-сәлам: «Йа гакыллы, тугры Гомәр, алай димә, мин синең туганың, дустың гына. Миңа баш имә, күкне, җирне, сине, мине яраткан бер Тәңрене генә олугла!» — дип, Гомәрнең кулыннан ала. Гомәр, кылычын читкә ташлап, үксеп-үксеп елый башлый.

*1916*





# Үткен кылыч

Борын-борын заманда Искәндәр атлы бер падишаһ баласы бар иде. Аның бала вакыты ата-ана иркәсендә бик кызык, бәхетле булып үтте. Анасы аңар илдә тиңдәше булмаган матур, кыйммәтле киемнәр тектерә. Аны иң нечкә ефәкләрдән эшләнгән төргәкләрдә генә йөретә һәм иң тәмле, татлы ашлар, эчемлекләр белән генә сыйлый, тәрбияли иде. Атасы җирнең төрле якларыннан зур галимнәр чакырып, аны укыта иде. «Бервакыт угылым Искәндәр дә падишаһ булыр. Әгәр яхшы тәрбияләсәм, ул илебездә булган падишаһларның иң артыклары булыр»,— дия иде.

Ундүрт яшьтә инде Искәндәр үзенең бөтен иптәшләреннән кызу чаба, җәянең угын барысыннан да ерак җибәрә һәм төз тидерә иде, алай гына да түгел, Искәндәр үзенең турылыгы, гакыллылыгы белән һәркемне үзенә кол итә иде. Шуның өчен бөтен илдәге кешеләр аны сөеп:

— Безнең ханзадәбез Искәндәрнең көннәре һәрвакыт кояшлы булсын, һәрвакыт аның алдында чәчәкләр чәчәк атып, былбыллар сайрап торсыннар һәм аның бөтен көннәре тик бәйрәм генә булсын,— диләр иде.

Ләкин Искәндәрнең атасы Ильяс кешенең тормышында тик бәйрәм булуның файдасызлыгын белә иде. Ул кешегә, бигрәк тә падишаһларга үзләренең өсләренә төшкән вазифаларын үтәү өчен бик нык эшләргә кирәкне белә иде.

Бервакыт угылы Искәндәр белән күңел ачып йөргән вакытта, ул әйтте: «Балакаем, һәрбер эш — матур гамәлдер. Бөтен кешеләр, падишаһлар да һәрвакыт эшләргә тиешләр. Дәрәҗәгә менәргә, бәхетле булырга теләгән кеше иренмәскә, берөзлексез эшләргә тиеш».

Бервакыт алар чәчәкләргә күмелгән елга буеннан үтеп баралар иде. Аларның бер якларында тау күренеп тора иде. Падишаһ үзенең сүзләрен бүлде дә нәкъ тауның башында торган кечкенә генә өйне күрсәтте. Ул җирдә бөтен илгә атаклы тимерче Бәһрәм тора иде. Балалар, яшь егетләр аңардан һөнәр өйрәнәләр иде. Бу заманда тимерчелек эше таралган, тимерчеләр арасында бик гакыллы кешеләр дә булгалый иде.

— Угылым! Мин сине Бәһрәмгә тимерчелеккә укытырга җибәрергә телим,— диде падишаһ.

Искәндәр тау башындагы кечкенә тимерче өенә килеп урынлашты. Ул хәзер әүвәлге хәтфә, ефәк кием урынына каты бишмәт, күн алъяпкыч һәм авыр башмаклар кия башлады. Инде әүвәлдәге мамык мендәр, йомшак юрганнар да юк иде. Тик баш астына салырга киндер эчендә салам төргәк, өскә көндезге бишмәт кенә иде. Аның ашавы да башка эшчеләр белән бергә иде. Шулай булса да, Искәндәр үзен бик бәхетле саный иде. Һәркөн ул яңадан-яңа әйберләргә өйрәнә, белмәгән

нәрсәсен яратып, тиз белергә тырыша иде. Күп үтмәде, ул нечкә, җиңел чылбыр да ясый башлады.

Бәһрәм, кич, эштән туктагач, борынгы заманның падишаһлары, Искәндәр бабаларының сугышлары хакында экиятләр сөйли иде. Шулвакыт Искәндәрнең дә дәрте күтәрелә, каны кыза, бабалары кебек зур эшләр күрсәтәсе килә иде. Бервакыт тимерче Бәһрәм бик борчылып, кайгырып, өйгә — шәкертләре янына кайтты.

— Беләсезме, шәкертләрем, нинди зур кайгы, дошманыбыз булган күрше падишаһның тимерчесе Җанбу бер кием ясаган. Аны нинди кылыч та кисәрлек түгел икән. Ул миңа хат җибәргән. «Әгәр минем һөнәремә каршы син бер һөнәр чыгара алмасаң, мин сине җиңгән булам. Син минем колым, мин синең хуҗаң, остазың булырмын»,— дигән. Мин аның киемен кисеп чыгарырлык кылыч ясарга тырыштым, ләкин булдыра алмадым. Арагыздан кем миңа ярдәм итәр?

Искәндәрнең дәрте кузгалды, остазы Бәһрәмгә ярдәм итәсе килде.

— Бәлки, минем сәгатем килеп җиткәндер,— диде ул үз-үзенә. Бәлки, бабаларым шикелле зур эш кылырга миңа язгандыр.

Шәкертләр бер сүз әйтмәделәр, тик берсенә-берсе карашып башларын гына селектеләр. Рәт Искәндәргә килеп җитте.

— Сиңа кирәк булган кылычны мин үзем коярмын,— диде. Шәкертләр көлеп, аны мыскыллый башладылар. Тимерче уйга батты: «Бәлки, ул эшләр дә. Ул падишаһ баласы. Моңарчы да ул зур һөнәрләр күрсәтте. Әгәр шундый батырланып алган эшен булдыра алмаса, мин аны, әлбәттә, тәүбә иттерермен».

Искәндәр эшкә кереште. Җиде көн, җиде төн бер тоташ эшләде, бер кая чыкмады. Чүкеч тавышлары бер минут булсын, туктап тормады. Искәндәр, сиге-

зенче көнне кулына бер кылыч тотып, тимерче бинасыннан чыкты. Бәһрәм кылычның йөзен күреп шатланды:

— Хәзер инде бу кылычның үткенлеген сынап карыйк,— диде. Шәкертләр йон кебек нечкә бер ефәк еп алдылар да якындагы елгага киттеләр. Тимерче кылычны алды да суда йөзгән епкә чапты. Еп икегә өзелеп китте, кисәкләре үз алларына агып киттеләр.

— Яхшы икән... Әгәр сабы да шундый нык булса, Җанбуның киемен кисәрбез,— диде. Искәндәр бер сүз әйтмичә, кылычны алды да сындыргалап ташлады. Тагын эшкә керешә. Өч көн, өч төн ул эшләде. Тимерче алачыгыннан ялкыннар өзлексез чыгып торды. Чүкеч тавышы бер дә тукталмады. Дүртенче көнне чыгып, ул янә Бәһрәмгә кылыч бирде:

— Инде сынап карагыз, остазым, үткенлеге ничек икән? — диде. Алар суга йон туп ташладылар. Бәһрәм агып килгән туп килеп менәрлек итеп кылычны суга тыгып, йөзен тышка каратып куйды. Шәкертләр туп йөзгәнне карап торалар иде. Туп агып килде, кылычның йөзенә кагылу белән кыл икегә ярылып китте. Ике ярты туп үз алларына агып киттеләр. Искәндәр яңадан кылычны алды да вак кисәкләргә сындыргалап бетерде. Шуннан соң ул янына беркемне дә җибәрмичә, тоташтан җиде атна эшләде. Шул вакыт эчендә ул саргаеп, ябыгып бетте. Җиде атна үтүгә, баш өстенә күтәреп, ялтырап торган кылыч алып чыкты.

— Менә,— ди,— сезгә кылыч!

Бәһрәм кылычны алды. Сабыннан тоту белән ул уйга калды. Берни әйтергә дә белмичә, еракка карап торды. Искәндәр кылычны тартып алды да зур тимер төндәккә[1] чапты. Төндәк икегә ярылып китте.

---

[1] *Төндәк* — түмәр.

Кылычның йөзе ачылган, ялтыраган төсле генә булды. Шуннан соң алар унлап сарыкның йонын агып торган суга ташладылар. Кылыч йон тубын, йон ебен ничек җиңел киссә, шулай ук бу төргәк йоннарны да кисеп чыгарды.

— Менә, ичмасам, бу эш! — диде тимерче Бәһрәм,— хәзер инде кемнең остарак икәнен дошманым Җанбу белер. Мин адәмнәрнең иң белекле һәм һөнәрлеләреннән саналырмын. Әмма ул инде минем колым булыр.

Илнең төрле якларына юлчабарлар җибәреп, ике тимерче арасында көрәш булачагын белдерделәр.

Көрәш көнендә ике падишаһлыкның чигенә — тау өстенә искиткеч күп кешеләр җыелды. Падишаһлар үз кешеләре, үз якыннары белән чикнең ике ягына урынлаштылар. Җанбу яклары шат иделәр. Алар үзләренең дөньяда тиңдәше булмаган тимерче Җанбуның өстен чыгуына ышаналар иде. Чөнки Җанбу алдында Бәһрәм уймак кебек кенә иде.

Ильяс падишаһ сабыр, гакыллы ханбикәсе, үзенең яраннары белән ни булачагын куркып көтә иде. Бәһрәм янында Искәндәр һәм башка шәкертләр дә торалар иде.

Җанбу сынар өчен эшләнгән киемендә, акрын гына атлап, тау битләвенә менде дә, кулын-кулга кушырып, ташка утырды. Аның артыннан: «Яшәсен безнең батырыбыз Җанбу», «Яшәсен дөньяда тиңдәше булмаган һөнәрчебез!» — дип кычкырдылар. Җанбу читтән караганда адәмгә охшамый, бер кибән төсле тора иде. Шуннан соң Бәһрәм дә кылычын кулга алып, акрын гына тау битләвенә менеп, Җанбу каршына барып туктады. Җанбу, Бәһрәмне күргәч, кычкырып көлеп җибәрде: «Менә бер курчак алдыма килеп басты»,— диде. Читтә карап торучы Җанбу патшасы һәм кешеләре дә, бу көрәшне уенга гына санап, Бәһрәмнән көләләр иде. Ильяс падишаһ тыныч, салкын кан белән тора иде. Ул әйтә иде:

— Гыйлем кара көчтән куәтлерәк булырга тиеш. Гакылы, һөнәре бар кеше нинди зур пәһлеван белән дә көрәшергә җөрьәт[1] итә ала. Шулай булгач, балам Искәндәр, син курыкма, иптәшләреңә дә шулай әйт, Бәһрәм җиңәр, без бәйрәм итәрбез,— диде.

Халык ике батырдан күзен алмый иде. Бәһрәм Җанбуга карады да:

— Көлмә, мактанма, Җанбу, әлегә иртәрәк, син миңа чабарга ирек бир, шуннан яхшысы булмас,— диде. Җанбу урыныннан да кузгалмады, кычкырып:

— Чабып кара! — диде.

Бәһрәм, кылычын югары күтәреп, бер мәртәбә селтәнде. Җанбуның башы өстеннән яшен яшьнәгән төсле булды. Ул уңнан сулга бер мәртәбә кылычны тартып җибәрде, кызган тимерне суга салган төсле чыш итеп китте. Башка бернәрсә булмады. Җанбу урынында һич кузгалмыйча, әүвәлгечә утырып торды. Тик аның йөзе генә бераз агарып китте.

— Син, Җанбу, берәр нәрсә сизәсеңме? — диде Бәһрәм.

— Кызган тимер кагылган төсле генә булды, башка бернәрсә дә юк.

— Селкен, Җанбу, кузгал урыныңнан!

Җанбу кузгалды, шунда ук аның биленнән югаргы ягы текә таудан тәгәрәп, елгага барып төште. Гәүдәсенең калган ягы тау өстендә кузгалмыйча калды. Моны күргәч, Җанбу яклары куркынышып качарга тотындылар.

Батыр яклары, урра кычкырып, Бәһрәм янына җыелдылар. Аны батыр калуы белән котларга тотындылар. Падишаһ Ильяс һәм ханбикә аңар бүләкләр бирделәр. Искәндәр бер сүз әйтмичә карап торды. Халык Бәһрәмне мактый, аның һөнәре ха-

---

[1] *Җөрьәт* — батырчылык.

кында тамашага калып сөйли. Искәндәр тимерче алачыгында төннәр йокламыйча кылыч ясавы хакында уйлый.

Ул илнең исен китәрерлек бер зур эш эшләргә теләгән иде. Хәзер аның ата-анасы һәм бөтен ил Бәһрәмне мактыйлар. Кылыч Искәндәрнеке. Аның хакында бер сүз әйтүче дә юк. Искәндәрнең эче поша башлады. Тирә-ягына каранды. Бер генә кеше дә падишаһ каршына килеп:

— Падишаһым, солтаным! Җанбуны кискән кылычны синең угылың ясады бит. Бу көнге шатлык, бәйрәмебез аның һөнәре аркасында булды,— дип, бер сүз дә әйтмәде. Искәндәр, күп уйлаганнан соң, үзенә-үзе:

— Мин кылыч ясадым, мин бабаларның баласы булырлык гаҗәп бер эш эшләдем. Миңа шул җитә, аның өчен теләсәләр кемне мактасыннар, минем өчен барыбер... шулай да...

*(«Пәһлеван хикәяләреннән»)*
*1917*





# Язмыш

Борын заманда Кечек Азияне биләп торган Крез атлы патша бар иде. Аның үзе тора торган шәһәре Сарда иде. Бу падишаһның байлыгы шул заманда данлыклы булган Иран, Мисыр, Юнан[1] илләрендә дә бик макталып сөйләнә иде. Крезның мәрмәрдән салынган күз чагылырлык матур сарайлары, сарай эчендәге зиннәт, җиһазлары читтән килгән падишаһларны да хәйран калдыра иде. Сарай шәһәрнең читендә, калку җиргә салынганга, аның кояшка каршы ялтыраган алтын төсле түбәләре бик ерак җирләрдән күренә иде. Ул сарайның тирә-ягы бакча иде. Ул бакчаларда мең төрле җимеш агачлары бар. Мең төрле кошлар һәм хайваннар асрала иде. Крез сарае матур биналары, бакчалары, күлләре, кошлары, хайваннары белән данлыклы булса да, аның бигрәк артык макталып сөйләнүе икенче нәрсәдән

[1] *Юнан* — Греция.

иде. Сарайның хәзинәсендә иге-чиге булмаган алтын-көмеш, энҗе-җәүһәрләр иде. Бу маллар йөз еллар буенча шул илдән һәм башка илләрдән талап җыелган иде. Крез үзе бик залим,ерткыч падишаһ булмаса да, аның аталары, бабалары бик комсыз, усал падишаһлар иде.

Алар үзләренә мал-байлык җыяр өчен бернәрсәне дә кызганмыйлар иде. Үз илләрен талап та, нәфес басылмаса, күрше илләр белән сугышалар, искәртмәстән аларны басып, барлык малларын талап кайталар иде. Җиңгән җирләрендә картларны үтереп бетерәләр, яшь ирләрне, егетләрне, балаларны һәм хатын-кызларны коллыкка алалар иде. Крез падишаһ сугышмый иде. Тик үзенең матур сараенда берсеннән-берсе матур, гүзәл булган йөзләрчә җарияләре[1] белән хозур кыла иде. Ул инде үзен дөньяда иң зур, иң бай, иң бәхетле падишаһ дип уйлый иде. Аның сарай җарияләре арасында Крезның атасы вакытында талап алынган Иран падишаһларының кызы да бар иде. Иран падишаһларының Лидия падишаһларына никадәр ачулары килсә дә, үзләрендә җитәрлек көч булмаганга, аларга сугыш ача алмыйлар иде. Шулай да алар һәрвакыт хәзерләнеп, берәр җае туры килсә, үч алуны беренче бурычлары дип беләләр иде. Үч алу җиңел түгел иде, бай, данлыклы падишаһ булганга, Лидия падишаһларының дуслары күп иде. Һәр елны төрле җирләрдән төрле бүләкләр белән аларга кунакка килгән падишаһлар, ханнарның исәбе булмый иде. Крез патша үзен мактап, күккә күтәреп язучы шагыйрьләрне дә, гыйлем ияләрен, хәкимнәрне[2] ярата иде. Ул, үзенең илендәге һәм башка җирләрдәге зур, данлыклы галимнәрне, хәкимнәрне чакыртып, сөхбәтләр дә ясый[3] иде. Кемне генә чакырма-

[1] *Җария* — кол кыз.
[2] *Хәким* — акыл иясе.
[3] *Сөхбәт ясый* — сөйләшә.



сын, кем белән генә сөйләшмәсен, һәркем аны дөньяның бәхетлеләреннән саный иде. Аның заманында Юнан илендә бик данлыклы хәким бар иде. Бу хәким дөньяда бер кешене дә зур, олуг, түбән күрми иде. Һәркемне бертигез ярата, бертигез сөя иде. Аның мәҗлесе падишаһларга, зур байларга һәм таш ватучы, җир казучы, иген чәчүче фәкыйрьләргә дә бертөсле була иде. Ул әйтә иде: «Үткән көн турысында әйтеп була, иртәгә кемнең ничек булуы хакында бер сүз дә әйтеп булмый. Кешенең байлыгы тышында түгел, сарайлар, алтыннар, ефәкләр бәхет бирә алмый, бәхет исә кешенең күңелендә, йөрәгендә»,— дия иде. Ул үзе йортлар салдырмый, атлар асрамый, артык киемнәр дә тектерми иде. Аның салкыннан, яңгырдан ышыкланырлык кына өе, тәнен капларлык кына киеме бар иде. Җылы вакытларда өстенә озын җилән киеп, яланаяк йөри иде. Ул үзе кайда хәким булса, шунда барып укый һәм үз белгәнен бер дә туктамый кешегә укыта иде. Бервакыт Лидия патшасы Крез Юнан хәкимен алырга җибәрде. Хәким килде. Крезның гадәте шул иде: ул һәрбер кунакка үзенең сараен, бакчаларын, күлләрен һәм хәзинәдәге байлыгын күрсәтә иде. Хәзинәсендәге байлыгын күргәч, һәркем: «Йа патшаларның патшасы Крез, дөньяда синнән бәхетле кеше бар микән? Әйтерсең җир Тәңресе!» — диләр иде.

Крез иң элек хәкимне матур җиһаз эчендә алтын савытларда кунак итте. Берсеннән-берсе матур җарияләр Крезның яныннан бер дә калмыйлар иде. Төрле кыйммәтле ташлар утыртып ясалган Крезның башындагы таҗы гына бер илне сатып алырлык иде. Хәким бар нәрсәгә салкын кан белән торды. Дөньяда тиңдәшләре, охшашлары булмаган матур җарияләрне һәм сарай зиннәтен, җиһазны күреп тә ул: «Машаллаһ, байлыгың зур, бәхетле икәнсең»,— димәде.

Шунда Крез хәкимгә бакчаларын, күлләрен, хәзи-

нәдәге байлыгын күрсәтергә тотынды. Бакчаларда хөрмәләр, инҗирләр, йөземнәр, башка мең төрле җимешләр пешеп, яныш, ботак күтәрә алмаслык булып торалар иде. Күлләрнең дә исәбе юк иде. Дөньядагы барлык кош, балык шул күлләрне бизиләр иде. Хәким бу күлләрне, бакчаларны бик яратып карады. Аның күрмәгән кошлары, күрмәгән балыклары, күрмәгән агачлары әле күп иде. Ул матур кошларны, адәм башы кебек зур чәчәкләрне күреп: «Ай-һай, матурлар икән»,— дия иде.

Крез үзенең хәзинәсен күрсәтте. Ул сары алтыннар белән тулы капчык, савытларга кулын тыгып җибәрә иде. Дөрестән дә, өелеп яткан алтыннарның исәбе юк иде. Шундагы алтын-җәүһәрне күргән кеше, хәйранга калып, бөтенләй сихерләнә иде. Крез шул хәзинәне күрсәткәндә, әледән-әле хәкимнең күзләренә карый, ни әйтер икән, дип чыдамсыз көтә иде. Ләкин хәким бер генә сүз дә әйтми иде. Эш беткәч, иң ахырдан падишаһ түзә алмады: «Йә хәким, исем китә, ничек син бу байлыкны, бу дәүләтне күреп тә, «Падишаһ, гомерең бигрәк бәхетле икән» дип әйтмәдегез»,— диде. Шуңар җавап биреп, хәким әйтте:

— Син бу тормышыңнан үзеңне бәхетле саный идеңме? — диде.

— Әйтергә дә юк, миннән бәхетле кеше бармы? — диде Крез.

— Ярый. Бүгенгә чикле гомерең бәхетле үткән, моннан соң? — диде хәким.

— Әлбәттә, мин шул бәхет эчендә үләчәкмен, кемнең соң минем бәхетемне тартып алырга көче җитәр? — диде падишаһ.

— Ярый, син шул бәхет эчендә үлсәң, мин, Лидия патшасы бәхетле гомер итте, дип әйтермен, әлегә бер сүз дә әйтә алмыйм,— диде хәким.

Шуннан соң берничә еллар үтеп китте. Крез һаман шул үзенең кәеф-сафасында үткәрә иде. Бервакыт

Иранда фәүкылгадә[1] гакыллы, гайрәтле һәм сугыш сөюче Кир атлы падишаһ тәхеткә утырып, үзе янына бик зур көчләр кушып, иске ачу белән Лидия патшасын тар-мар итәргә хәзерләнә иде.

Күп вакыт үтмәде, Кирның сатраблары (командаднары) зур көч белән Лидия җиренә басып керделәр. Каршы торган вак көчләрне җиңеп, күбесен алдап, Крезның үз шәһәре булган Сарданы да алдылар. Сарай да таланды. Барлык хәзинәсе алынды. Иран патшасының туганы булган Крез җариясе коткарылды. Крез, үзе богауланып, барлык зур кешеләре белән Кир каршысына җибәрелде.

Иран патшасы Крезның якыннарын астырды, кистерде. Үзен катырак җәзалау өчен, дар агачы янына китереп, ничек үтерү хакында сатраблары белән киңәшә башлады. Шулвакыт Юнан хәкименең сүзе Крезның күңеленә төште дә елап җибәрде. Кир бу елауның сәбәбен сорады. Крез хәким белән булган сөхбәтен сөйләп бирде. Шул сүзләрне ишеткәч, Крезны астырырга торган Кир агарып урынына барып утырды. Ул бераз уйга калып, җиргә текәлеп торганнан соң, үз-үзенә: «Бөтен дөнья байлыгы кулында булган Крез шул язмышка очрады. Соң мин... минем гомерем ничек булыр. Менә язмыш!» — диде дә кычкырып: «Крезның богауларын алыгыз. Аны азат итегез. Минем белән бергә булсын!» — диде.

*1917*



[1] *Фәүкылгадә* — гадәттән тыш.

# *Эчтәлек*


Төзүчедән ........ 5
Ай алдады ........ 9
Мөгаллим ........ 16
Сандугач ........ 22
Йолдыз бала (*Оскар Уайльдтан*) ........ 28
Канатлы тай ........ 50
Кечкенә Мук хакында хикәя (*Вильгелм Гауфтан*) ........ 65
Хан кызы ........ 85
Ике төрле тормыш ........ 126
Байлык хакында (*Толстойдан*) ........ 131
Җен теле ........ 134
Корьән тәэсире ........ 140
Үткен кылыч ........ 147
Язмыш ........ 154



Литературное издание для детей

*Ахмадеев Шагит Гимадетдинович*

**Судьба**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 6.05.2003. Форматы 60×90 1/16.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,00+форз. 0,25. Шартлы буяу-оттиск 21,50. Нәшер-хисап табагы 6,57+форз. 0,39. Тираж 2000. Заказ Я-233.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.